# Күңел — өермә

Гөлназ Шәйхи

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-4
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ш91

**Шәйхиева Г.Ф.**

Ш91 Күңел — дәрья: Публицистика / Гөлназ Шәйхи. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 174 б.

ISBN 5–298–03955–3

Китапта сәясәтчеләр, әдәбият-сәнгать өлкәсендә шөһрәт казанган йолдызлар белән әңгәмәләр тупланган.

ISBN 5-298-03955-3
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Шәйхиева Г.Ф., 2006

# *Әңгәмәләшү — кешелекнең зур байлыгы*

*Кешеләр белән сөйләшә, әңгәмә кора белү сәләте һәркемгә дә бирелмәгән. Журналистикада әңгәмәләшү аерым урын алып тора, дип әйтер идем. Кешеләр белән аралаша белүне иң зур байлык дип тә әйтәләр. Чынлап та, әңгәмә корганда, тиешле җавапны дөрес сорау биреп кенә алырга мөмкин. Ә менә ул сорауны ничек, ни рәвешле бирергә? Биредә инде журналистның белеме-хәбәрдарлыгы да, итагатьлелеге дә, эчке мәдәнияте дә зур роль уйный. Әңгәмәдәшеңне үпкәләтерлек булмасмы, укучыларны кызыксындырган сорауларга җавап алып булырмы? Белмим, Гөлназ ничек уйлый торгандыр, ләкин аның эчке әзерлеген мин үзем белән әңгәмә корган вакытта аңладым. Кыска гына сораулар белән әңгәмәдәшенең күңел катламнарын ача белә Гөлназ. Аның бу китабында сәясәтчеләр, әдәбият-сәнгать өлкәсендә дан казанган йолдызлар белән әңгәмәләре урын алган. Вакытында алар газета-журнал битләрендә дә басылып чыкканнар. Андый шәхесләргә игътибар беркайчан да кимеми. Шуңа күрә әлеге китапны укучылар кызыксынып укырлар дигән өметем зур.*

*Танылган җырчыларыбыз Хәния Фәрхи, Хәмдүнә Тимергалиева, Фердинанд Сәләхов, Зөһрә Сәхәбиева һәм башкалар белән әңгәмәләр кергән бу китапка. Алар Гөлназга эч серләрен дә сөйлиләр, тормыш вакыйгаларын да аңлаталар, кайгы-хәсрәтләре белән дә уртаклашалар. Әңгәмәләрне укыйсың да, күңел серләрен ачтыра торган ачкычы бар, ахры, Гөлназның, дип уйлыйсың. Без Гөлназ Шәйхи геройларының кичерешләрен үзебезнеке итеп кабул итәбез. Аларның хис-тойгыларына теләктәшлек белдерәбез, талантлары, акыллары белән зур үрләргә ирешүләренә инанабыз. Болар, — әңгәмә кора белүне зур байлык дип санаган очракта, — шул байлык белән уртаклаша белү сәләтеннән дә тора, минемчә.*

*Татар милләтендә халкыбызны кызыксындырган шәхесләр бихисап. Алга таба да Гөлназ Шәйхи үз укучыларын милләтебезнең йолдызлары белән, яңадан-яңа шәхесләр, талантлар белән радио дулкыннарында да, матбугатта да таныштырып әле дигән өметтә калам.*

*Уңышлар сиңа, каләмдәшем Гөлназ!*

***Нәзифә Кәримова, язучы,***
***«Азатлык» радиосы хәбәрчесе***

# «Серләремне каеннарга сөйли идем...»



*Хәния Фәрхи — популяр эстрада җырчысы, «Бәйрәм» ансамбленең хуҗабикәсе. Башкортстанның Тәтешле районы Салаюа авылыннан. Туган елы — Күсе елы, йолдызлыгы — Игезәкләр. Яраткан төсе — яшел төс, ризыгы — балык һәм зәйтүн җимеше, чәчәге — умырзая. Күңеленә хуш килгән шөгыле — җырлау, балык тоту, аучылык һәм атта йөрү.*

*Яраткан җырчыбызның уй-фикерләрен белү, тагын да якыннан танышу максатыннан, мин аңа берничә сорау белән мөрәҗәгать иттем.*

**— Тәрҗемәи хәлең, сәнгатькә ничек килүең турында әйтеп үтсәң иде.**

— Мин табигатьнең иң матур, иң гүзәл урынында урнашкан бәләкәй генә авылда туганмын. Авы-

лыбыз тирәли урман. Андагы агачларның талгын җирдә тирбәлеп моңсу гына биюләре миндә, миндә генә түгел (без гаиләдә алты бала), һәммәбез күңелендә сәнгатькә мәхәббәт бөреләнүгә ярдәм иткәндер. Әтиебез өздереп тальян гармунда уйный, ә без аңа кушылып җырлый идек. Иң бәләкәе булганга, мине күбрәк җырлаталар. Әтиебез гармунда уйнарга барыбызны да өйрәтте. Балачакта, үзем генә урман эченә кереп, ялгыз калып җырларга-моңланырга ярата идем.

— **Соңгы вакытта үзең җырлар да иҗат итә башладың. Белүемчә, музыкаль белемең юк. Бу синә комачау итмиме?**

— Бик комачаулый. Шулай да театр училищесында алган белемнәр ярдәмгә килә. Язган көйләремне нотага төшермим. Башта күңелдә йөртәм, аннан, гармунда уйнап, магнитофонга яздырам.

— **Җырлап тамак туймый, дисәләр дә, җыр — синең төп хезмәтең, бар керемең шул җырдан. Гаиләсен тәэмин итү, сәхнәгә, кеше арасына чыгарга юньле кием юнәтү өчен, артист бүген күпме хезмәт хакы алырга тиеш?**

— Бүгенге көн таләпләре буенча уртача 2 миллион сум кирәк.

— **Хәния, җырларыңны тыңлаган саен, үткән тормышың өчен үкенәсең сыман тоела миңа.**

— Юк, үкенмим, беркайчан да. Кайгыларым да, шатлыкларым да — барысы да үземнеке. Берсен дә кешегә бирәсем килми.

— **Моннан берничә ел элек штат кыскару сәбәпле театрдан эштән киткән артистлар арасында син дә бар идең... Ә менә бүген концертларың аншлаг белән бара. Бу үзе генә дә яулап алынган бәхет турында сөйли түгелме?**

— Кая гына барсак та, тамашачы безне тулы зал белән каршы ала. Әгәр дә безне халкыбыз ятатып кабул итә икән, моннан да зуррак бәхет юктыр артист өчен. Бәхетле, бик бәхетле мин бүгенге көндә.

— **Тормышта алдыңа нинди максат куйган идең һәм шуңа ирештем дип уйлыйсыңмы?**

— Алай максатым юк иде югын. Шундый югарылыкка күтәрелә алганмын икән, җырларымны тамашачым кабул итә алган икән, хәзер шушы биеклектән төшмәү минем максат. Тормышымның шундый борылыш алуы өчен язмышыма, халкыма рәхмәт.

**— Кызыңның артист булуын телисеңме?**

— Бик. Артист була алу — олы бәхет ул.

**— Хәния, җырыңны үзең радиога барып яздырганчы, башка кеше магнитофонга яздырырга өлгерә һәм «Бәйрәм» ансамбле кассетасын сата да башлый. Синең хезмәтең белән акча эшли. Моңа ничек карыйсың?**

— Әйе, моның өчен хәзер закон бар. Ләкин минем аның артыннан йөрергә вакытым юк. Мин ул эш белән йөрсәм, яңа җырлар тумый калыр иде. Тагын бу мәсьәләнең икенче ягы да бар. Радиога барыш яздыру күп вакыт сорый. Гастрольләрдә күп йөрү сәбәпле, моңа вакытыбыз җитеп бетми. Әлеге кассеталар минем җырларымны халыкка җиткерергә ярдәм итәләр. Шулай да Нефтекамскидагы бер студия, җырларымны кассетага яздырыш сату өчен, минем белән килешү төзеде.

**— Популяр җырчыбыз Газинур Фарукшин Хәния Фәрхи фонында тоныкланып арткы планда калмыймы?**

— Мин алай дип уйламыйм. Моны тамашачы үзе хәл итәргә тиеш.

**— Дусларың күпме?**

— Ифрат күп. Сабый баладан алыш зур түрәләргә кадәр.

**— Синең торак мәсьәләсе хәл ителдеме?**

— Аллага шөкер. Фатир алдык, күчендек. Бик рәхәтләнеп яшибез.

**— Бәйрәмнәрне кайда, кемнәр белән үткәрергә яратасың?**

— Кайда гына булсам да, күңелемә ошаган кешеләр белән бергә үткәрәм.

**— Үзеңне эшлекле хатын дип саныйсыңмы?**

— Минем табигатем Игезәкләр йолдызлыгында тасвирланганча. Кызып китсәм, бик эшлекле. Күп

кешеләрне үз артымнан ияртәм. Ялкаулана да алам. Шулай да үземне эшлекле хатын дип саныйм.

**— Узып киткән 1993 ел кайсы ягы белән истәлекле булды?**

— Кайгы белән шатлык бергә йөри, диләр. Кайгыларым да, шатлыкларым да күп булды, һәм шуларны уртаклашырлык дусларым артты. Тагын безнең өчен зур вакыйга — телевизион конкурста җыручылар исемлегенә керү. 1994 елга планнарыбыз зурдан. Тагын да матуррак җырлар иҗат итү. Себер, Урал якларына гастрольгә барып, яңа тамашачылар табу.

*«Татарстан хәбәрләре» газетасы*
*1994 ел, апрель*

# «Мин һаман авыл кызы...»



*Бүгенге кунагыбыз — Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты, Татарстанның атказанган артисты, Муса Җәлил исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Зөлфирә Зарипова. Ул — моңлы тавышлы, затлы кыяфәтле, талантлы шәхес. Аның репертуарында берничә дистә роль исәпләнә. Нурсолтан, Зифа, Миңлекамал, «Ахырзаман»дагы Ана бүре образларын театр сөючеләр югары бәяләде. Зөлфирә ханым — тормышта гади, мөлаем хатын-кыз. Ике улы бар. Буш вакытларында рәсем ясарга, улларына тәмле-тәмле ашлар пешерергә, бакчада эшләргә, кунакка йөрергә ярата. Тагын бер уңай сыйфаты бар аның: ул*

*кешеләр белән бик күп һәм теләп аралаша. Репетиция вакыты булуга карамастан, безнең сорауларга да җавап бирергә вакыт тапты.*

**— Зөлфирә ханым, Сезнең балачак иленә сәяхәт ясыйк әле.**

— Балачак... Бик артта калды шул инде ул еллар. Бала чагым Әтнә районы Бәрәскә авылында үтте. Миңа 40 көн тулганда — әнием, 5 яшьтә әтием вафат булган. Үги әни тәрбиясендә үстем мин. Ләкин үги әни дип һич тә атыйсым килми аны. Бик мәрхәмәтле, яхшы күңелле хатын иде ул минем әни.

Кечкенә вакытта бик шук идем. 1 нче Май бәйрәмнәрендә, яңгыр теләп, су сибеп уйнаган вакытларда малайларны, кызларны оештырып йөри идем. Сабый вакытларны искә алсаң, сөйләр әйберләр күп инде ул.

**— Ни өчен театр артисты һөнәрен сайладыгыз? Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Фуат Әбүбәкеровның шундый сүзләре бар: «Әгәр Зөлфирә җырчы булырга укыса, ул иң нык балкучы йолдызларның берсе булыр иде». Сезнең тавышыгыз йөрәккә үтеп керә. Ни өчен җырчы булып китмәдегез?**

— 15 яшемдә, Мәскәүгә укырга җибәрергә яшьләр җыялар икән дигән хәбәр ишетеп, филармониягә килгән идем, җырлатып карадылар. «Сеңлем, син яшьрәк әле, берничә елдан килерсең», — диделәр. Мин синнән җырчы чыкмас дип әйткәннәрдер дип уйладым да авылга кире кайтып киттем. Әмма артист буласы килү теләге көчле булгандыр, күрәсең, яңадан Казанга килдем һәм театр училищесына укырга кердем.

**— Сез — данлыклы Камал театры артисты. Их, менә шуның кебек уйнарга иде, дип күздә тоткан артистыгыз бармы?**

— Элегрәк булгандыр да инде. Хәзер юк. Кешене кабатлау кирәк әйбер түгел. Кеше индивидуаль булып калырга тиеш. Шулай булса гына ул үзен тормышта таба ала.

**— Сез тормышта да артистмы?**

— Нәрсә дип әйтергә? Төрле чаклар була инде. Кайчак артистланырга да туры килә. Шулай да мине туры кеше диләр.

**— Кешенең төрле вакыты була: эшкә кулы ятмаган чаклары да, кәефе төшкән мизгелләре дә. Ә менә артистның сәхнәгә чыгасы килмәгән чагы буламы икән?**

— Ничек булмасын, була инде ул. Әмма сәхнәгә чыгып синең уйнавыңны карарга килгән тамашачыны күргәч, шул роль эчендә генә яши башлыйсың. Бөтен кайгы-борчуларың юкка чыга.

**— Зөлфирә ханым, Сезне сәясәт кызыксындырамы?**

— Минем илдә бара торган сугышларга күңелем әрни. Күпме яшь егетләребезнең гомере киселә! Ә сәясәткә килгәндә, аңа белер-белмәс катнашып булмый, һәм мин аны хатын-кыз эше дип санамыйм да.

**— Әхсән Баянов әсәре буенча куелган телевизион спектакльдә Сез башкарган Асылбикә образын театр сөючеләр бик яратты. «Зәңгәр кыңгыраулар» җыры да халык арасында бик популярлашып китте.**

— Халык бу җырны образ белән бергә кабул итте бит. Әгәр аерым гына җырласам... Белмим инде... Шулай да җырымны халык кабул иткән икән, мин моңа куанам гына.

**— Туган якларга әйләнеп кайтыйк әле. Сез үзегезне Әтнәнеке дип саныйсызмы?**

— Әтнәм — минем туган ягым. Тәпи атлаган җирем. Әтнә белән горурланам мин. Шәһәрдә яшәсәм дә, барыбер Бәрәскә кызы булып калам. Мин һаман авыл кызы.

**— Зөлфирә ханым, якташларыгызга нинди теләкләрегез бар?**

— Сәламәт булсыннар. Сәламәтлек булса, бары да булыр. Тыныч тормышта яшәсеннәр.

**— Иҗади уңышлар Сезгә. Әңгәмәгез өчен рәхмәт.**

*«Әтнә таңы» газетасы*
*1996 ел, сентябрь*

# «Үземне әтнәле дип саныйм...»



*Әтнә районы үзенең тырыш, эшчән, булдыклы кешеләре белән дан тота. Шушы җирдә туып үскән яисә тамырлары белән Әтнә туфрагына бәйләнгән танылган шәхесләребез күп. Алар белән очрашканда, горурланып: «Бу бит безнеке!» — дип куям. Шулар арасында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең тарих институты директоры, Татарстан Республикасы Президентының сәяси мәсьәләләр буенча киңәшчесе Рафаэль Сибгат улы Хәкимов та бар. Рафаэль Сибгатович — тыныч холыклы, һәр сүзен уйлап сөйләшә торган кеше. Аның белән аралашу, әңгәмә кору үзе бер рәхәт.*

**— Рафаэль Сибгатович, иң элек үзегезне газета укучыларыбыз белән якыннанрак таныштырып китсәгез иде.**

— Әтием Күлле Кименеке. Әнием Азнакай районы Әгерҗе авылыннан. Мин үзем Казанда туып үстем. КДУны тәмамлагач, шунда җиде ел укытучы булып эшләдем. Аннан соң Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтына күчтем.

**— Сез тарих бүлеген тәмамладыгызмы?**

— Юк, мин физика факультетында укыдым. Шулай да мине фәлсәфә фәне күбрәк кызыксындырды. Мәдәният институтында да шул фәнне укыттым. Кафедра мөдире булып эшләдем. Проректор булдым. Үзгәртеп корулар башлангач, 1986 елда обкомга күчтем. Ул елларда Татар иҗтимагый үзәге эшендә дә катнашып йөрдем әле. Ә 1991 елдан мин — Президент киңәшчесе.

**— Рафаэль Сибгатович, Президент киңәшчесе булу — бик зур җаваплылык сорый торган хезмәт. Сез ничек шул дәрәҗәгә күтәрелә алдыгыз?**

— Фәлсәфә белән ныклап шөгыльләнә башлагач, күп мәкаләләр яздым, күп кенә комиссияләр эшендә катнаштым. Суверенитет кабул иткәндә дә, Декларация эшләгәндә дә катнаштым. Шул вакытта, мөгаен, Президент күргәндер. Минем фикерем белән аның фикере туры килгәндер, ахры. Мин Президент аппаратына күчкәндә, киңәшче дигән урын-штат юк иде әле. Президент та яңа гына сайланган, аппараты да төзелеп кенә килә. Ә бүген инде киңәшче чыннан да зур кеше.

**— Шул вакыттан бирле тагын нинди мөһим эшләрдә катнашырга туры килде?**

— Тормышым бик активлашты. Күп җирләрдә булдым, күп нәрсәләр күрдем. Зарланырлык түгел. Россия белән Шартнамә төзегәндә дә катнаштым. Чечняда булдым. Россия Конституциясен кабул иткәндә, делегация составында идем. Без аны ташлап киттек.

**— Ни өчен?**

— Чөнки бу Конституция безгә каршы, ул Россияне дә җимерәчәк иде. Безнең уйлар дөреслеккә туры килде.

**— Рафаэль Сибгатович, хәзерге көндә Сез — ТР Фәннәр академиясенең тарих институты директоры. Үзегез радиофизик булырга укыгансыз. Тормыш дулкыннары Сезне сәясәткә алып кереп киткән. Сез КДУның физика бүлегенә теләп кергән идегезме?**

— Ул вакытта физик һөнәре модада иде. Фәлсәфә факультеты юк иде. Кая барырга? Кечкенәдән тимер-томыр эшләре белән шөгыльләнә идек. Шул юлдан киттем. Ләкин, шагыйрь гаиләсендә туып үскәнгәдер инде, фәлсәфә, сәясәт, милли тормыш белән кызыксына башладым. Һәм язмышым шул якка борылды да куйды. Мәскәү университетында ике ел стажировка уздым. Бу өлкәдә белемем җитәрлек.

**— Рафаэль Сибгатович, Әтнә ягы Сезгә кай ягы белән якын?**

— Әтнә — минем туган ягым. «Кайсы яктан?» — дип сорасалар, горурланып: «Мин Әтнә ягыннан», — дим. Үземне әтнәле дип саныйм. Кимегә кайтканда, авылга кайтам, дип сөйлим. Тамырларым шуннан бит.

**— Гаиләгез белән дә танышыйк инде.**

— Хатыным үзбәк милләтеннән. Ташкентта туып үскән. Консерваториядә шәрык музыкасын укыта. Кызым Камиләгә ун яшь. Мәктәптә укый.

**— Кызыгыз татар телен беләме?**

— Кызым тугач та әйттем: «Бала ана телен белергә тиеш». Камилә татарча да, үзбәкчә дә, рус телендә дә яхшы сөйләшә.

**— Татар халык шагыйре Сибгат Хәким гаиләсендә үскән егеткә «бу — шагыйрь малае» дип караучылар булдымы?**

— Әйе, әле дә очрашуларда: «Сез шигырь язасызмы, яздыгызмы?» — дип сорыйлар. Кайбер вакытларда Сибгат Хәкимович дип дәшәләр.

**— Ә Сез шигырь язасызмы соң?**

— Юк.

**— Әтиегез язган шигырьләрне укып бара идегезме?**

— Әлбәттә. Соңгы елларда әле мин әтинең «секретаре» булып та эшләдем. Язмаларын машинкада бастым. Мәкаләләрен тәрҗемә иттем.

**— Без Сибгат Хәкимне туган авылында — Күлле Кимедә җирләрсез дип уйлаган идек.**

— Әйе, андый уй булды. Хәсән Туфан белән рәттән күмсәгез иде дигән фикер дә әйткән иде әти.

Алар бик якын дуслар. Соңгы елларда һәр көнне очрашып, сөйләшеп туймыйлар иде. Шуңа этине Казанда җирләдек.

**— Күлле Кимегә еш кайтасызмы?**

— Бик еш түгел. Елына ике-өч тапкыр кайтыла.

**— Рафаэль Сибгатович, Сезнең яраткан ризыгыгыз бармы?**

— Татар егете бит мин. Халкыбызның барлык милли ашларын яратып ашыйм.

**— Ә иң ятратканы?**

— Гөбәдия.

**— Районлашларыгызга теләкләрегез дә бардыр.**

— Күп районнарда булам. Кайдадыр нефть чыга, кайдадыр заводлар күп, кайдадыр урманнар, елгалар. Әтнәдә андый байлык юк. Җире дә мактанырлык түгел. Әмма аның уңган, тырыш, эшчән, һәрьяктан сәләтле халкы, булдыклы җитәкчеләре бар. Авыллары нык. Яңа елда районлашларыма сәламәтлек, күңел тынычлыгы, бәхетле тормыш телим. Районыбыз республикада алдынгылар рәтендә. Киләчәктә дә аның шул югарылыкта калуына шигем юк.

**— Әңгәмәгез өчен рәхмәт. Сезгә дә яңа елда авыр, җаваплы эшегездә уңышлар телим.**

*«Әтнә таңы» газетасы*
*2000 ел, гыйнвар*



*Казан арты. Әтнә төбәге. Республикабызга бик күп танылган шәхесләр биргән як ул. Кая гына барып чыксам да, анда якташларымны очратам. Аларның зур үрләр яулап, хөрмәтле кешеләргә әйләнүләрен, шул ук вакытта гади һәм тыйнак булып калуларын күреп, күңел сөенә. «Әтнә таңы» газетасында хезмәтләре белән инде күпләргә таныш әтнәлеләр белән еш кына очрашып торабыз. Берәр җаваплы урынга яңа җитәкче билгеләнсә, Әтнәнеке түгел микән дип, тизрәк аның биографиясе белән танышасы килә. Татарстан Республикасы эчке эшләр министры итеп якташыбыз Әсхәт Әхмәт улы Сәфәровның билгеләнүен район халкы горурланып каршы алды. Вакыт агышын туктатып булмый. Генерал-майор Әсхәт Әхмәт улының министр бу-*

*лып эшли башлавына да бер ел вакыт узып киткән. Тәртип саклау органнарында үзгәрешләр дә сизелә. Ләкин бүген сүзебез эш турында түгел. Газетаның «Безнекеләр» кунакханәсендә Әсхәт Сәфәров белән якташ, әтнәле буларак, гади генә сөйләшик әле.*

*Әсхәт Үгез елында, Үлчәү йолдызлыгында туган. «Алар — түземле, чыдам, аз сүзле кешеләр. Үзләренә ышаныч уяталар. Зур физик көчкә ияләр. Җәмгыятьтә аларны илтифатлы, ачык йөзле, шат күңелле булганнары өчен яраталар. Бу йолдызлыкта туганнар — менә дигән адвокатлар, журналистлар, дипломатлар» диелә йолдызнамәдә. Бу сүзләр безнең бүгенге кунагыбызга да тәңгәл килә дип әйтсәм, ялгышмам. Әлеге сыйфатларга тагын шуны өстисем килә: ул гади, тыйнак һәм шул ук вакытта таләпчән дә.*

**— Әсхәт Әхмәтович, әйдәгез, бергәләп туган авылыгызны, әти-әниегезне искә төшерик әле.**

— Мин Әтнә районының Яңа Шимбер авылында туганмын. Әтием Әхмәт — озак еллар колхоз рәисе булып эшләгән кеше. Хәзер гүр иясе инде. Әтиемнең әтисе Сәфәргали бабай — авыл советының беренче рәисе, ярлыларга ярдәм күрсәтү оешмасы рәисе булган. Әнием Нәкыя — укытучы. Чыгышы белән Сарманнан. Бөек Ватан сугышы ветераны. Бүгенге көндә Казанда яши. Ул башта Түбән Көек мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытты. Аннан соң гаиләбез белән Күлле Киме мәктәбенә күчеп киттек. Бу вакытта миңа биш яшь иде.

**— Беренче сыйныфка Сез алайса Күлле Киме мәктәбенә бардыгыз?**

— Юк шул, мин беренче сыйныфка Мари республикасының Горелово авылындагы мәктәпкә бардым.

**— Ни өчен?**

— Әтинең ул чакта әйткән сүзе истә. «Улым, син татар телен болай да яхшы беләсең. Дөнья бу, рус телен дә ныклап өйрән», — дигән иде ул. Һәм мине күрше рус авылына укырга бирделәр. Башлангыч сыйныфны да, сигезьеллык мәктәпне дә мин рус

телендә тәмамладым. Беренче укытучым Мария Михайловна Гранатова бүген дә исән-сау. Мин аңа рәхмәтлемен.

**— Татар авылында, татар гаиләсендә туып үскән малайга рус телендә белем алу җиңел булмагандыр?**

— Башта бик авыр булды. Бер сүз дә аңламый идек. Мин анда дустым Ленар Әхмәтшин белән бергә йөреп укыдым, аннан өйрәндек.

**— Авыл аралары якын түгел. Төрле вакыт була, пычрагы, бураны, яңгыры дигәндәй.**

— Көн дә җәяү бара, җәяү кайта идек. Буранлы көннәрдә ат белән илтәләр, ат белән алырга киләләр. Ә 9–10 нчы сыйныфларны Күлле Кимедә тәмамладым.

**— Һәм Сез үзегезгә юрист һөнәрен сайладыгыз.**

— Әйе, КДУның юридик факультетына укырга кердем. Дүрт имтихан тапшырдык. Шуларның дүртесен дә «5»легә бирдем һәм студент булдым.

**— Әсхәт Әхмәтович, әйдәгез, гомернең иң гүзәл мизгеле булган студент елларын искә төшерик инде.**

— Беренче курста укыганда ук оператив комсомол отрядында эшләдем, өч ай Чаллыда милиционер булып йөрергә дә туры килде. Ә практиканы мин Казан шәһәренең Совет районында уздым. Университетны тәмамлагач, әлеге районга тикшерүче итеп эшкә чакырдылар. Бу 1983 ел иде. Өч ел ярым шунда эшләдем. Комсомол оешмасы секретаре булып тордым.

**— «Казан шәһәренең яхшы тикшерүчесе» дигән Мактау тактасында Сезнең фоторәсем дә торган.**

— Әйе. Шуларны искә алыштыр инде, мине Министрлар Советы каршында төзелгән административ органга өлкән референт итеп чакырдылар. Анда дүрт ел эшләдем.

**— Президент Аппаратында кайчан эшли башладыгыз?**

— 1991 елның июнендә Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәрипович Шәймиев Президент ярдәмчесе итеп эшкә чакырды. 1992 елда Президент иминлеген тәэмин итү структурасына эшкә килдем. 1998 елга кадәр шул структурада эшләдем.

**— Менә Сез бер ел инде Татарстан Республикасы эчке эшләр министры. Әлеге тәкъдимне ничек кабул иттегез?**

— Ничек эшләрмен, алып бара алырмынмы дип куркып калу булды. Карарны авырлык белән кабул иттем. Шулай да бу эшкә әзер идем.

**— Әсхәт Әхмәтович, туган авылыгызга еш кайтасызмы?**

— Елга бер тапкыр, зиярәт кылырга. Әтием шунда күмелгән. Сәфәровлар нәселе һәммәсе дә Яңа Шимбердә.

**— Хәзер Сезнең гаиләгез белән танышыр вакыт җитте сыман.**

— Хатыным — Луиза Вилсуровна. Студент елларында таныштык. Ул университетның ВМК факультетында укый иде. Өйләнештек. Ике кызыбыз туды — Диана белән Элина. Икесе дә Казанның 39 нчы мәктәбендә укыйлар. Җиңү проспектында өч бүлмәле фатирда матур гына яшәп ятабыз.

**— Һәркемнең күңеленә хуш килә торган ризыгы була...**

— Мин ризыкка талымсыз. Нәрсә пешерсәләр, шуны ашыйм.

**— Әсхәт Әхмәтович, Сезнең турыда, якташларына ярдәм кулы сузарга һәрвакыт әзер, дип әйткәннәрен ишеткәнем бар.**

— Әти: «Улым, кулыңнан килсә, булыша алсаң, һәркемгә ярдәм ит», — дия иде. Бу сүзләр минем гел исемдә.

**— Сез автомобиль спорты белән шөгыльләнәсез. Спортның тагын нинди төрләре белән мавыгасыз?**

— Ял иткәндә, теннис уйнарга яратам. Ләкин соңгы елларда автомобиль спортына да, зур тенниска да вакытым җитми.

**— Әсхәт Әхмәтович, якташларыгызга Сезнең теләкләрегез.**

— Безнең район — республикабызда алдынгы районнарның берсе. Авылларга газ кертелгән, юллар салынган. Бездә уңган, эшчән, тырыш халык яши. Аларга тыныч, имин тормыш, саулык-сәламәтлек телим. Бәхетле яшәсеннәр.

*«Әтнә таңы» газетасы*
*2000 ел, июль*

# «Бер-беребезнең кадерен белеп яшәргә язсын...»



*Бөтенсоюз эстрада җырлары конкурсы дипломанты, Башкортстанның атказанган артисты Идрис Кәлимуллинны кемнәрдер театр артисты, кемнәрдер җырчы буларак беләләр. Әйе, һәм театр, һәм җыр сәнгатендә танылу алган шәхес ул Идрис.*

*Идрис Кәлимуллин 1989 елда Башкортстанның Яшьләр театрына эшкә килә. Аннан — «Нур» театры. Ул башкарган рольләргә күз салсак, алар арасында И.Юзеевның «Кыр казлары артыннан» спектаклендә Малик, Ә.Фәйзи һәм Т.Гыйззәт иҗат ит-*

*кән «Башмагым» спектаклендә Галимҗан, Г.Исхакыйның «Зөләйха» спектаклендә Сәлимҗан, Шекспирның «Ромео һәм Джульетта» спектаклендә Ромео кебек образлар бар. Бүгенге көндә Идрис Кәлимуллин — «Сәйяр» эстрада театрының сәнгать җитәкчесе. Театрда эшләгән дәвердә музыкаль образлар тудырган милләттәшебез тамашачы каршында үзен җырчы буларак та күрсәтә. «Сәйяр»дә ул күбрәк җыр сәнгатенә игътибар бирә. Идрис башкаруында радиотапшыруларда еш яңгырый торган «Кайларда сез, татар угланнары?» дигән җыр дөньяга сибелгән татар халкының гимнына әверелде дип әйтсәм, һич ялгышу булмас дип уйлыйм. Сәнгатебез күгендә кабынган тагын бер йолдыз белән, әйдәгез, якыннанрак танышыйк әле. Чыгышы белән кайсы яклардан икән ул?*

— Башкортстанның Илеш районындагы Шәммәт авылында, Сөн елгасы буенда туып үстем. Илеш районы белән Татарстанның Актаныш районы күршеләр. Сөндә су кереп, ике республиканың баласы булып дөньяга килүемә бик шатмын.

**— Алайса, син шагыйрь Роберт Миңнуллин белән бер авылдан?**

— Әйе. Роберт Миңнуллин минем өчен туган да, шагыйрь дә, абый да, дәүләт эшлеклесе дә. Безнең карт әтиләребез бертуган.

**— Идрис, син театр дөньясына ничек кереп киттең?**

— Мин Уфа сәнгать институтының актерлар бүлеген тәмамладым һәм республикада 1989 елда яңа гына ачылган Яшьләр театрына юллама белән эшкә җибәрелдем. Анда театр сәнгатендәге беренче адымнарымны атладым. Бик күп милләттәшләребезнең хыялы булган «Нур» татар дәүләт театры ачылды. Аның җитәкчеләре — күренекле режиссер Байрас Ибраһимов белән директоры Мәҗит Мөдәррисов — мине шунда эшкә чакырдылар.

**— Һәм сине казанлылар беренче мәртәбә нәкъ менә «Нур» театрының башкалабызда узган гастрольләрендә күрде дә инде.**

— Беренче гастрольләребез тарихи гастрольләр булды. Казан — безнең изге мәркәзебез, иҗади мәркәзебез. Имтиханны без Г.Камал театры сәхнәсендә ташшырдык. Данлыклы сәхнәдә Казан тамашачысы, зур артистлар каршында чыгыш ясау безгә этәргеч бирде. Башкортстан Яшьләр театрыннан «Нур» театрына килү, анда үз ана телемдә уйнау, сәнгатебезне үстерү минем өчен икеләтә җаваплы чор булды. 17 ел эчендә күп кенә образлар иҗат ителде. Нык ярдәм иткән танылган шәхесләргә: Олег Ханов, Габдулла Гыйләҗев, Сәвия Сираева, Әхтәм Габдрахманов кебек сәхнә осталарына рәхмәтлемен.

**— «Нур»да эшләү дәверендә йөрәккә үтеп керерлек, истә калырлык рольләр булдымы?**

— «Нур» театрында беренче спектакль итеп Илдар Юзеевның «Кыр казлары артыннан» драмасын сайлаганнар. Төп рольне башкарырга тиешле артист театрдан киткән. Элегрәк романтик, лирик рольләр уйнаган актер булсам да, режиссер миңа Малик ролен тәкъдим итте. Алда иҗат иткән образларыма капма-каршы образ. Социаль герой. Җиң сызганып, җаным-тәнем белән эшкә керештем. Әткәйнең прототибын күз алдында тоттым. Тәнкыйтьчеләр югары бәя бирде. Малик ролен минем иң уңышлы ролем дип санадылар. Бу миңа алдагы эшемдә этәргеч булды.

**— Идрис, иҗат дәрте белән янып йөргәндә, нишләп театрдан киттең?**

— Тормыш катлаулы бит ул. Театрда аңлашылмаучылык килеп чыкты. Шул вакытта мин генә түгел, бик талантлы иҗатташларым да китте театрдан. Буш яланда үзе генә калып, җылы бирерлек хезмәттәшләре булмаса, актер нинди генә талантлы булса да эшли алмый.

**— Идрис, әңгәмәбезне дәвам итеп, иҗатыңның икенче ягына тукталыйк. Ул — җыр дөньясы. Бала чактан ук җырчы булырмын дигән теләгең бар идеме?**

— Мин үземне белгәннән бирле җырлыйм. Әткәй, дуслары белән җыелган саен, мине өстәлгә бастырып җырлата иде.

**— Нинди җыр башкарганыңны хәтерлисеңме?**

— «Иреннәрең кызыл чия, күзләрең зәңгәр төймә» дигән сүзләр бар иде ул җырда. Аннан әткәй бәләкәй генә гармун алып бирде. Соңыннан баянга күчтем. Кечкенә чакта кызык бит, ике туган энем белән өйдән өйгә кереп җырлап йөрибез. Безгә конфет, прәннек бирәләр. Үзенә күрә бер стимул. Әткәйнең хыялы мине артист итү иде. Аның мине музыка мәктәбенә бирәсе килде. Ә әнкәйнең үз яныннан җибәрәсе килми. Шулай да 5 нче сыйныфка мине район мәктәбенә бирделәр. Баян сыйныфында укыдым. Бәйрәмнәрдә гармунда уйнап җырлый идем. Укытучыларым: «Идрис, сиңа сәнгать институтына барырга кирәк, син артист булырга тиеш», — диделәр, һәм мин бу тәкъдимне кабул иттем.

**— Идрис, җырчыны халык арасында таныту өчен бер җыр булырга тиеш. Сине Идрис Кәлимуллин итеп таныткан җыр нинди җыр ул?**

— Талантлы композиторыбыз Рим Хәсәнов иҗат иткән «Кайларда сез, татар угланнары?» дигән җырны Татарстанда да, Башкортстанда да яратып кабул иттеләр. Аның сүзләрен Марис Назиров язган. Җыр өч ел җырланса, аны «иске» диләр. Ә инде бу җырның гомере озын булды. Мин авторларга рәхмәтлемен.

Лирик планга килгәндә, мине Татарстан тамашачысы Рим Хәсәновның Риза Шәфи сүзләренә язган «Чияләрең чәчәк атканда» дип аталган җыры аша беләдер дип уйлыйм.

**— Син хәзер — «Сәйяр» эстрада җыр театрының җитәкчесе. Бу театр нинди эшләр башкара?**

— Бүгенге сәхнә бер юнәлештә генә эшләүне кабул итми. Актер буларак, эстрада дөньясына керү авыр булды дип әйтмәс идем. Сәхнә кануннары бар җирдә дә бер үк. Без халык таләп иткән сәнгатьне үзебезнең күзлектән чыгып һәм сәхнә кануннарына таянып, төрле юнәлештә эшләргә тырышабыз. Театральләштерелгән тамашалар уздырабыз. Хәзерге көндә зур программа әзерләү белән мәшгульбез.

Ноябрь-декабрь айларында татарстанлылар безнең спектакль-концертларыбызны күрә алачаклар. Классик әсәрләребезгә яңа сулыш биреп, аны эстрада аша тамашачыга җиткерү максатында эш итәбез.

**— Татар дөньясы белән элемтәң ничек?**

— Күптән түгел Тверьдә булып, милләттәшләребез белән очраштык. Мәскәүдә яшәүче татарлар белән элемтәләребез ныклы. Киләчәккә дә планнарыбыз бар. Себер якларыннан, Ленинград өлкәсеннән чакыру алдык. Алла боерса, безне әле алда матур очрашулар көтә.

**— Идрис, «Татар иле» газетасын укучыларга, милләттәшләребезгә теләкләрең дә бардыр.**

— Хөрмәтле милләттәшләрем, дөньяның төрле почмакларына сибелсәк тә, без бер сулыш, бер максат белән яшәргә тиешбез. Алла боерса, яшәрбез дә. Безнең җырларыбыз, иҗатыбыз сезне аз гына булса да сөендерә, җылыта икән, бу — безнең өчен зур бәхет. Кайда гына булсак та, милләтебез исән-сау яшәсен. Горурланып, җиргә нык басып, шушы фани дөньяда бер-беребезнең кадерен белеп яшәргә язсын.

*«Татар иле» газетасы*
*2000 ел, октябрь*

# «Тавышым — үзе байлык...»



*Татар җыры, аның үткәне, бүгенгесе турында фикерләрен белү максатыннан халкыбызның яраткан җырчысы, Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык, Россиянең атказанган артисты Вафирә Гыйззәтуллинага мөрәҗәгать иттем.*

**— Яңа гасырга аяк бастык. Ничек уйлыйсыз, Вафирә ханым, татар эстрадасы өченче меңьеллыкка нинди уңышлар белән керә?**

— Соңгы ун ел эчендә интервьюлар күп бирдем, чыгышлар да күп ясадым. Милләт турында уйласаң,

татар халкын яшәтәсең, дөньяны матурлыйсың килсә, бу сорауга битараф калып булмый. Минем фикерем шундый: бүгенге көндә татар эстрадасы юк ул. Татар җыры турында уйласам, йөрәгем елый. Көн дә Камал театры яныннан узып йөрим. Бик озак вакыт зур итеп «Татар җыры — 2000» дип язылган афиша эленеп торды, тик безне, урта буын җырчыларын дип әйтик инде, әлеге концертка чакырган кеше булмады. Югыйсә карт-коры түгелбез бит әле, ни генә дисәләр дә, узган гасырның төп җырчылары идек. Мин үземне 35 ел буе классик сәнгатьне тартып баручы дип саныйм. Оялып әйтмим. Сүзләремне халкым да дөрес аңлар. XXI гасыр мәдәният, сәнгать, әдәбият гасыры булачак дип әйтәләр. Бу чыннан да шулай булсын иде. Ничек кенә булмасын, яңа меңьеллыкка кергәндә, алдымда шундый бер яктылык күрдем. 15 ноябрь көнне Зур концерт залында концертым булды. 35 ел иҗат итү дәверемнең бөтен максаты Рөстәм Яхинны зурлап сәхнәгә менгерү иде. Хыялым, ниһаять, тормышка ашты.

Миңа: «Яхин — синең хоббиең инде ул», — диләр. Юк, Рөстәм Яхин —минем бөтен иҗатым. Элек тә әйткәнем бар, тагын кабатлыйм, музыка әсәрләребез Яхин әсәрләре дәрәҗәсенә күтәрелсә, татар халкы үзен милләт буларак саклап калачак.

**— Бүгенге җыр сәнгатенең нигезен кемнәр тәшкил итә дип саныйсыз?**

— Профессиональ күзлектән караганда, четерекле дә, авыр да, куркыныч та сорау бу. Зәйнәп белән Зөфәр, Алла боерса, беркөн килеп классикага да игътибар итәрләр дип уйлыйм. Габделфәткә дә зур өметләр баглыйм. Газета чыгарам дип, җыр сәнгатен оныта күрмәсен. Илсур Сафинны үстерергә кирәк. Нуриәхмәт Мөхәммәтҗанның да тавышы бар. Алсу Хисамиеваның киләчәге өметле. Музыка училищесының татар бүлегендә, консерваториядә дә бар берничә талант. Тәмле әйбер күп булмый ул! Әмма унбишләп башкаручыны бик рәхәтләнеп саный алам. Алда телгә алынган җырчыларны башкалардан өстенрәк куям икән, алар инде Вафирә апаларының йөзенә кызыллык китерергә тиеш түгелләр. Диапазон-

нары киң. Сәнгатькә баштанаяк чумарга, эзләнергә, Рөстәм Үтәй оркестры белән дә, симфоник оркестр белән дә җырларга кирәк.

**— Халык җырларның сүзе гел бертөрле дип зарлана.**

— Дөрес әйтәләр. Күбесенчә сүзе генә түгел, көе дә юк аларның. Чит ил җырларының көйләрен алалар да шуңа сүз өстиләр. Рус эстрадасы хәзер «старые песни в новом исполнении» дип талпына. Безгә дә элеккеге җырларыбызны барларга кирәк.

Профессионаллар һәм үзешчәннәр язган җырлар бар. Үзешчәннәр язган җырлар начар димим. Алар арасында бик тә матурлары бар. Тыңлыйсың да канатланып китәсең. Ләкин истә калмыйлар бит. Заһит Хәбибуллинның «Сагыну»ын, Исмай Шәмсетдиновның «Кызарып кояш баткан чакта»сын, Рөстәм Яхинның «Китмә, сандугач»ын онытып кара син?! Җәүдәт Фәйзинең «Урман кызы»н мәңгелек җыры ни дисең?! Ачылып бетмәгән композиторыбыз Мансур Мозаффаров бар әле безнең. Мин әйтеп узган җырчылар, шушы бөек шәхесләребезнең әсәрләрен яңартып, кабат сәхнәгә менгерерләр дип ышанам.

Үзешчән композиторлар да язсын. Аларның җырлары да яңгырасын. Ул җырлар акны карадан аеру өчен дә кирәк.

**— Сез атап киткән композиторларның юлын дәвам иттерүчеләр бармы бүген?**

— XXI гасыр хатын-кызлар гасыры булыр дип фараз итәләр. Коръәндә дә шулай язылган. Луиза Батыр-Болгари, Резеда Ахиярова, Мәсгудә Шәмсетдинова, Луиза Хәйретдиноваларга өметем зур. Ир-ат композиторларны бөтенләй белмим диярлек. Муса Маликовны, әлбәттә, үстерергә кирәк. Тагын да алга китеп карасак, дирижерларыбыз да юк бит безнең. Симфоник оркестрыбызның дирижеры Фоат Мансуровны алмаштырырлык кешене кем атый ала? Талантларны халык арасыннан табарга кирәк. Шул уңайдан фестивальләр уздырыр идем мин. Дөрес, аның өчен акча кирәк. Хәзерге заман җырчылары моны оештыра алыр иде. Мәсәлән, «Микрофонсыз җырчылар» бәйгесе үткәрергә мөмкин. Кем микро-

фонсыз җырлый ала? Оркестр беләнме, рояль беләнме? Менә кайда күренер иде талантлар.

**— Вафирә ханым, хәзерге заман җырчыларында акча бар дигән фикер уздырдыгыз.**

— Әйе. Дөрестән дә шулай. Ә мин байлык артыннан кумадым. Минем тавышым — үзе байлык. Ходай биргәнгә шөкер итеп яшим.

**— Вафирә ханым, инде әңгәмәбезгә нокта куяр алдыннан «Акчарлак» газетасына әйтәсе уй-фикерләрегезне дә беләсебез килә.**

— Мин XX гасырда яшәдем. Бөтен теләгем, хыялым җыр сәнгатен яктырта торган газета яки журнал булдыру иде. Җыр — зур байлык. Милләтне ул саклады. Классик җыр сәнгатенең нигезен тәшкил иткән Азат Аббасов, Нәҗия Теркулова, Мөнирә Булатова, Җәвәһирә Сәләхова, Рәисә Билаловалар бүгенге көндә исән-сау, Аллага шөкер. Алар белән дә очрашып, укучыларга фикерләрен җиткерсәгез иде.

Мин Кабан күле буенда йөрергә, акчарлакларны күзәтергә яратам. Ике акчарлагым да бар. Алар хәзер мине таныйлар, кулдан ашарга да курыкмыйлар. «Акчарлак» та курыкмыйча гел алга омтылсын. Уңышлар аңа!

*«Акчарлак» газетасы*
*2001 ел, гыйнвар*

# Мәхәббәтнең сере нәрсәдә?



*Кешелек дөньясы белән бергә туган мәңгелек сорау: «Нәрсә ул мәхәббәт? Бармы ул?» Җирдә яшәү дәверендә һәркем бу сорауга үз җавабын табарга, аны үзенчә аңлатырга тырыша. Мин дә, шул сорауга җавап тапмаммы дип, 51 ел бергә гомер иткән, ике бала үстереп, аларга югары белем биргән, олы юлга озаткан Рәмзия апа һәм Шәүкәт абый Биктимеровларга юл тоттым. Үз кызларыдай якын итеп каршы алдылар алар мине. Әңгәмәбез яшьлек, мәхәббәт турындагы сөйләшүдән башланды.*

*Адәм баласы, олыгайгач, көннәрен үткәннәрне искә алып, яшьлеген сагынып уздыра икән. Беренче мәхәббәткә килсәк, ул — табигатьнең сере, аның тууын, ничек барлыкка килүен аңлатып та булмый. Меңнәр арасыннан берәүне ярата башлыйсың һәм башканы күрмисең. Әйтерсең зур җиһанда Син дә Ул гына.*

**— Шәүкәт абый, сер булмаса, Сезнең беренче мәхәббәтегез кем иде?**

— Сүземне ерактанрак башлыйм әле. Сугыштан соң, Казан театр училищесы студентлар җыя икән дигән хәбәрне ишеткәч, мин дә — 16 яшьлек малай — үземне сынап карарга булдым. Мәктәптә укыганда, спектакльләрдә катнаша идем. Аннан соң нәселебездә артист та бар бит. Галимә Ибраһимова минем туганнан туган апам. Шулай итеп, киттем Казанга. Имтихан бирдем. Кабул иттеләр. Иртәгә укырга килерсең дип озаттылар. Ул вакытта училищеның үз бинасы юк әле. Бер мәктәптә генә укыйлар. Икенче көнне килдем, йөрим кая барырга белмичә. Шул вакыт, минем аптырап йөргәнне күреп, бер кыз: «Кемне эзлисез?» — дип сорады. «Мин — театр училищесы студенты, укырга килдем», — дим. Ул бер бүлмәнең ишеген ачты да: «Рәхим итегез», — дип, мине эчкә уздырды. Керсәм, анда инде дәрес бара. Ишек ачып кертүче кыз Рәмзия исемле булып чыкты. Ул мине сәнгать дөньясына гына кертеп җибәрмәде, күңеленең биген ачып, йөрәге түренә дә уздырды, минем беренче мәхәббәтем һәм гомерлек юлдашым булды.

*Безне тәмле чәе белән сыйлап, Шәүкәт абый белән сөйләшүебезне дәшми генә тыңлап утыручы Рәмзия апага карыйм.*

**— Рәмзия апа, ә Сез Шәүкәт абыйны беренче күрүдән үк ошаттыгызмы?**

— Юк инде, юк... Үзе сары, үзе сипкелле, буе кечкенә... Ул әле малай гына дип, Шәүкәтне укырга да алырга теләмиләр ул вакытта. «Бу бик талантлы малайга охшаган. Киләчәктә үсәчәк ул, менә күрерсез», — дип, Кәшифә апа Тумашева тәкъдиме белән генә кабул итәләр аны училищега.

*Менә шулай бер төркем егет һәм кызлар театр сәнгате серләрен өйрәнергә, белем эстәргә керешәләр. Бергәләп репетицияләр ясыйлар, биергә, җырларга йөриләр. Артистлык осталыгына сту-*

*дентларны Шириаздан Сарымсаков, ә сәхнә теленнән Хәсән Туфанның хатыны Луиза Салиәскәрова укыта. Тамакның ач, киемнең начар булуы комачауламый аларга.*

*Шәүкәт абый, моннан 55 ел элек булган вакыйгаларны искә төшереп, хәтерен яңарта.*

— Дүрт ел шулай бергә укыдык. Дәрестә бер-береңә карап утырасың бит, күрәм, Рәмзия миңа көннән-көн күбрәк ошый бара. Үзе дә миңа битараф түгел шикелле. Ул театр янында гына тора иде. Өенә дә озатып куйгалыйм. Хәзерге сыман түгел инде ул вакытта. Урамда үбешеп торулар юк, кая ул, кулга-кул тотынышып барырга да кыймыйсың. Йөри торгач, мин Рәмзиягә чын-чынлап гашыйк булдым.

— Яшь чак бит, арттан йөрүче егетләр дә булмады түгел, — дип сүзгә кушыла Рәмзия апа. — Шулар арасында Шәүкәт кай ягы беләндер үзенә тартты шул. Шаян иде, тавышы матур иде. Иң мөһиме, ул мине хөрмәт итә белде. Беренче күрүдән ошатмасам да, дүрт ел уку дәверендә үзем дә Шәүкәтне чын күңелемнән ярата башладым.

**— Аннан аңлаштыгыз да гаилә корып җибәргә булдыгыз инде...**

— Бу 1949 ел иде. Училищены тәмамлагач, икебезне ике якка җибәрмәсеннәр өчен эшләдек бу эшне. Хәер, диплом алганда, безнең группаның ярты-сы парлы иде инде. Мәрьям белән Айрат Арслановлар өйләнештеләр, Госман Әхмәтҗанов та үзенең Кадриясен тапты. Рәис Сафиуллин да гаилә корды. Без дә бервакыт шулай хәзерге Кремль урамы буйлап барабыз. Загс бинасын күрдек тә, әйдә языйлышабыз, дидек. Керсәк, бер ханым утыра. «Без языйлышырга килдек», — дибез. «Паспортыгыз бармы?» — ди бу. Ул чакта әле уйлар өчен вакыт та бирелми, шаһитлар да кирәкми иде. Ике паспортка да язды, шалт итеп мөһер сукты. Шуннан кулыбызга языйлышу турында кечкенә генә таныклык бирде. Унҗиде сум акча түләдек. Сугыштан соң аз акча түгел иде ул. Аны әтидән алып тордым. Аның Казанга килгән чагы иде. «Әти, унҗиде сум акча би-

реп тор әле», — дим. Өйләнергә дип әйтергә батырчылык итмәдем инде. Безнең планнарны шулай итеп әти-әниләр дә белми калды. Үзебез дә бу эшнең ахырын уйламадык. Кайда торырбыз, нәрсә ашарбыз, нәрсә киярбез? Әлегә бер түбә астында яши алмаячагыбызны гына беләбез. Әти-әниләргә дә белгертмәдек бит. Шулай да, Рәмзияләргә барып, әтисеннән кызны сорадым. «Ярар, ярар», — диде ул. Башка сүз әйтмәде. Безгә бу вакытта 20 яшь иде.

**— Шуннан соң ниләр булды, сөйләгез инде.**

— Загстан чыккач та, Рәмзия өенә кайтып китте, ә мин — вокзалга, вагон бушатырга. Әлеге дә баягы акча җитми. Артистның хезмәт хакы бик аз иде ул вакытта. Тагын нәрсә булсын, бетте шуның белән. Туй да, никах та юк. Менә уйлап йөрим әле. Рәмзия белән хәзер 51 ел бергә яшибез. «Үлгәнче, әйдә, никахлашыйк. Ходай каршына барганда, «незаконный» булабыз бит», — дим.

1950 елда минем армиягә китәр вакытым җитте, әмма мине бронь биреп калдырдылар. Тик моңа сөенергә дә, көенергә дә белгән юк. Чөнки театрның хәле яхшы түгел. Акча түләмиләр. Рәмзиягә әйтәм: «Армиягә китәм дә офицер булам. Бәлки, яхшырак яши башларбыз», — дим.

**— Бу вакытта Сез бергә тора башлаган идегезме?**

— Юк. Безнең арада берни булмаган әле. Кул тотышудан узганыбыз юк. Рәмзия мине озатырга вокзалга төште. Әле дә күз алдымда — бер пакет кызыл алма күтәргән. Шунда мин Рәмзиягә әйтәм: «Кыз булып каласың. Кайтканда да шулай каршыласаң, без гомергә бергә булырбыз», — дим. Армиядә 4 ел хезмәт иткәннән соң, офицер буласым килми иде инде. Сүзендә торды Рәмзия, мине көтте, каршы алды. Армиядән туры аларга кайттым.

**— Театрда Сезнең өйләнешкән икәнлегегезне беләләр идеме?**

— Гел бергә аралашып йөргән дуслар белә иде. Беренче кичне иң якын дустыбыз Госманнарда кундык. Рәмзиянең әтисе — бабай әйтә: «Әлегә то-

рыр җирегез юк, бездә яшәрсез инде», — ди. Шулай итеп, 12 квадрат метрлы бүлмәдә алты кеше янында җиденче булып бабайларда яши башладым. Алар театр ишегалдындагы йортта торалар иде. Хәзер ул йортта бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшевның музее. Салих абый өстәге катта яши, без — аста. Мин аның белән еш кына театрда очрашам. Шундый зур кешегә кул биреп күрешергә дә уңайсыз сыман тоела. Фәрештә кебек күрә идек без аны. Бармакларыннан да моң тамадыр сыман. Шулай беркөн бакчада кәефсез генә утырам. Яныма Салих абый килде. «Нәрсә булды, ник боектың?» — ди. Пропискам юклыгын, шуның аркасында хезмәт хакымны ала алмаганлыгымны сөйләп күрсәттем. «Минем фатирга кер пропискага, мәйдан җитәрлек», — диде ул. Шушы көннән соң Рәмзияләрдә яшәдем, ә пропискада Салих абыйларда тордым. Мин Салих абыйны һәрчак хөрмәт белән искә төшерәм. Ул чакта мин театрда гади бер малай идем әле. Әмма Салих абый минем хәлемә керде. Ул үлгәнче, пропискада аңарда тордым. 1956 елда үземә фатир бирделәр. Бу вакытта кызыбызга ике яшь иде. Композитор Әнвәр Бакировтан калган ике бүлмәле иске фатирга күчендек. Рәмзия, ишекне ачып кергәч: «Миңа башка берни дә кирәк түгел», — дигән иде. Яши-яши биш фатир алмаштырдык менә.

**— Рәмзия апа, Сез дә артист бит. Нишләп театрдан киттегез? Әллә Шәүкәт абый эшләмәскә куштымы?**

— Һич юк. Ул вакытта мин университетның тарих факультетында читтән торып укый идем. Сессия килеп җитте. Ул вакыттагы театр җитәкчесе Малафиев янына кереп, имтиханнарга барырга рөхсәт сорадым. Гастрольләр сезоны да җиткән иде. «Синең рольләрне кем башкара? Икесенең берсен сайла: театр яки уку», — дигәч, ике дә уйламый гариза яздым да киттем театрдан. Шириаздан абый: «Зур хата ясыйсың, ашыкма әле», — дисә дә: «Юк, китәм инде, Шәүкәт эшләгәч, шул җитәр», — дидем.

— Рәмзия үзе теләп китте театрдан, — дип сөйләшүгә кушылды Шәүкәт абый. — Ул чакта театрда май аенда сезон ябыла да, гастрольгә Ташкент, Алма-Ата якларына чыгып китә идек. Бишәр ай йөреп кайтабыз. Икәүләп чыгып китсәң, балаларны кем карый? Шулай итеп, мин театрда эшләсен дип, Рәмзия сайлаган һөнәрен үзгәртергә булды.

**— Рәмзия апа, мөгаен, ялгышмагандыр дип уйлыйм. Өйдә уңган-булган хатыны бар мәшәкатьне үз өстенә алмаса, Шәүкәт Биктимеровны СССРның халык артисты итеп күрә алыр идекме икән әле?! Шәүкәт абый шулай итеп бик еш гастрольләргә чыгып киткән, ә Сез, Рәмзия апа, гел өйдә, гел балалар белән. Хыянәт турындагы яман уй күңелегезгә кермичә генә булмагандыр...**

— Без бер-беребезгә ышана идек. Шуңадырмы, андый уй гомумән уйланылмады. Берәр җиргә китсә, Шәүкәттән көн саен хат килә. Әти, аның хатларын күргәч: «Кызым, кияү сине бик ярата, ахры», — дип әйтә иде.

*Шәүкәт абыйдан килгән һәрбер хатны, һәрбер открытканы Рәмзия апа кадерләп саклаган. 1966 елда Әстерханнан язган бер хатын миңа да укырга рөхсәт итте.*

*«Икраны да, балыкны да яшереп кенә саталар, кыйбат һәм юк.*

*Сиңа 12 сумга шарф алдым, шерсть, ак төстә, киң, озын, ошармы-юкмы.*

*Кайтканда, берәр ящик помидор алырга уйлыйм. 1 килограммы 1 сум. Гастроль бик туйдыра. Кайтасы килә. Сине һәм балаларны бик сагындым. Әле синнән хат булмаса, Астраханьнан Москвага очып, аннан Казанга кайтмакчы булып тора идем. Хәзер тынычландым. Бик каты борчылган идем шул. Вакытың булганда, миңа кыска гына булса да хат язып тор, үзеңнең укуың турында да. Мин гел уйлап, көтеп торам. Бер дә борчылма, кулыңда диплом бар инде, үзеңне сакла.*

*Кайткач, телефоннан сөйләшербез әле. Башка хәбәрләр юк. Күзләреңнән, битеңнән үбеп, үзеңне бик каты яратучы тугрылыклы ирең.*

*7/VII.66 ел.»*

— Артистлар арасында хыянәт күбрәк дигән сүзне ешрак ишетергә туры килә, — ди Шәүкәт абый. — Моның белән һич кенә дә килешмим. Гомерләрен чын сәнгатькә багышлаучылар арасында, үзләренә тиң пар табыш, яшьлектә кавышкан ярлары белән картаючылар аз түгел. Теләсә нинди гаиләдә бер-береңне аңлый белү мәҗбүри. Көнчелек аркасында гауга чыкса, бу инде чын, тулы гаилә була алмый. Гаиләдә мәхәббәт булса, анда хыянәткә, юкбар сүзләргә урын калмаячак.

**— Хәзер, инде ярты гасырдан артык бергә яшәгәч, әйтә аласызмы, Шәүкәт абый, Рәмзия апа Сезне кай ягы белән үзенә тартты икән?**

— Менә шуны аңлатып булмый да инде. Мәхәббәтнең бөтен сере дә сүзләр белән аңлатып булмаудадыр. Яраткан кешеңне ни өчен яратканыңны беркайчан белмисең. Илле бер ел буе бергә яшәп, Рәмзиядә мин көн саен китапның яңа битен ачкан кебек яңалык ачам. Тормыш булгач, төрле вакыт була. Әмма бер-береңне гафу итә, кичерә белергә, яманлыкка караганда яхшылыкны күбрәк күрергә өйрәнергә кирәк. Аллага шөкер, матур яшәдек. Бер-беребезне саклый да, яклый да белдек.

— Кадеремне дә белде, хөрмәт тә итте. Көнләшү, хыянәтләр безгә ят иде. Балаларыбызны үстереп, икесенә дә югары белем бирдек. Хәзер оныкларыбыз өчен шатланабыз. Бу тормышта Шәүкәт белән очраштырганы, кавыштырганы өчен мин язмышка мең мәртәбә рәхмәтле, — дип өстәде Рәмзия апа.

*Яшь чагында, мәхәббәт рольләрен иҗат итеп, бик күп кызларны үзенә гашыйк иткән, Ленин кебек тарихи шәхесләрне сәхнәгә менгезгән, татар театры тарихында мәңге югалмас Әлмәндәр образын*

*иҗат иткән һәм үзенә гомерлек юлдаш итеп сайлаган Рәмзиясенә тугры калган СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров бүген җор телле, гади, мөлаем, дүрт оныгы булган бабаң инде.*

*Ничек каршы алган булсалар, нәкъ шулай итеп озатып та калдылар. «Озак яшәгез, пар канатыгыз каерылмасын. Табыныгыз һәрчак мул булсын!» дигән теләктә саубуллаштым мин алар белән.*

*«Акчарлак» газетасы*
*2001 ел, февраль*

## «Фамилиям — Шәмиева...»



**— Венера! Газетабызның беренче санында без «Венера фамилиясен һәм хыянәтне кире кага» дип язган идек. Әйдә, иң элек синең фамилияңә тукталыйк. Нигә Шәймиева фамилиясеннән күчәргә булдың әле?**

— Шәймиева фамилиясен миңа үз вакытында Габделфәт абый бирде. Бу минем сәхнә имиджым да булып китте. Хәзер инде урамда барганда таныш: «Син бит теге җырчы кыз, Шәймиевның оныгымы әле?» — дип сораучылар да бар. Чынлыкта минем

фамилиям — Шәмиева. Берничә ел элек Камал театрында узган бер концертта катнаштым. Ул кичәгә Президентыбыз да килде. Соңыннан әлеге концертны телевизордан берничә тапкыр кабатлап күрсәттеләр. Һәм кирәк бит — шунда мин җырлап бетергәч, экранда Шәймиевның кул чабып утыруын күрсәтәләр. Кемнәргәдер мине Шәймиевның туганы дип санарга бик әйбәт җирлек булды бу. Менә шуңа да, халык буталмасын, Шәймиев аркасында гына җырлап йөри икән дип әйтмәсеннәр өчен, үз фамилиямдә калырга телим мин.

**— Газетада анонс басылгач: «Венера кияүгә чыгамы әллә?» — дип кызыксынучылар да күп булды.**

— Кияүгә чыгу турында уйларга иртәрәк әле миңа, җыр дөньясында беренче адымнарымны гына атлыйм. Күп баскычлар үтәсем бар.

**— Венера, инде хыянәт турында сөйләшик. Сорау шул исемдәге җыр белән бәйле.**

— Безнең халык ничек күрсә, шулай кабул итәргә өйрәнгән. «Хыянәт» җырыннан соң да төрле сүзләр китте. Юкка гына җырламыйлардыр, араларында нәрсәдер бардыр, дип әйтүчеләрне дә ишетергә туры килде. Клип дөнья күргәч — бигрәк тә. Әгәр дә тамашачыны ышандыра алганбыз икән, бу безнең уңышыбыздыр дип уйлыйм. Димәк, без максатыбызга ирешкәнбез.

**— Хыянәт — бик күпләрнең җанына, бәгъренә тигән проблема ул. «Хыянәт» җырын башкарырга курыкмадыңмы?**

— Бу җырдан соң халык арасында «чыш-пыш-лар» башланасын без алдан ук сизгән идек. Шуңа да әниләргә әлеге җыр турында бер сүз дә әйтмәдем. Әзерләнеп беткәч кенә ишеттеләр. Куркып калдылар. Ләкин соңыннан моның образ гына икәнлеген аңладылар. Ә тамашачы, алдан ук әйткәнемчә, төрлечә кабул итте.

**— Яшерен-батырын түгел, авыл халкы артист һөнәрен җитди эшкә, төпле һөнәргә санамый. Ә синең җырчы булып китүеңә эти-әниең нәрсә диделәр?**

— Сәнгать дөньясына аяк атлавымның беренче баскычлары музыка училищесы белән бәйле. Казанга концертка барам дип киткән җирдән училищега укырга кереп кайттым. Әти-әнием белми дә калдылар. Алар минем җырлавыма беркайчан да җитди карамадылар. Җырлар җырлар да туяр, ташлар дип уйладылар, күрәсең. Әмма минем җырлау теләгенең күпкә зуррак икәнлеген аңлагач, тыймадылар, артист булуыма да каршы килмәделәр.

**— Габделфәт Сафин белән син башкарган әлеге җырның клибын да күрү бәхетенә иреште тамашачы. Анда сез геройларыгызның эчке кичерешләрен бик оста чагылдырасыз. Мәхәббәт утында үзе янмаган кеше бу хисләрне клипка төшкәндә дә аңлатып, күрсәтеп бирә алмаган булыр иде. Синеңчә, нәрсә ул мәхәббәт?**

— Мәхәббәт ул — бер-береңне аңлау, хөрмәт итү. «Мәхәббәт кирәкми, байлык булса, шул җитә», — дигән кызларны беләм мин. Алар белән һич кенә дә килешмим. Иң мөһиме — яратканың күңелгә якын булсын.

**— Концерт вакытында чәчәкләрне егетләр сиңа аз бирмиләрдер. Араларында күңелгә ошап калганнары буламы?**

— Йөрәгеңдә кемдер бар икән инде, анда башкага урын булмый. Яхшы егетләр дусларым арасында да күп. Ләкин яратканым берәү генә.

**— Аның белән кайда таныштыгыз?**

— Иптәш кызымның туенда мин шаһит булдым. Эльмира әйтә: «Казаннан туйга бер егет кайта, таныштырам әле мин сине», — ди. Башта ул миңа бөтенләй ошамады. Кешенең күңелен белмичә, бер күрүдә генә гашыйк булып булмыйдыр, күрәсең. Соңыннан исә ул мине эчке матурлыгы, самимилеге белән җәлеп итте.

**— Бу хәлләр күптән булдымы инде?**

— Ике ел элек. Хәер, без бер елдан соң гына яңадан очрашып, дуслашып киттек.

**— Синдә көнчелек хисе бармы?**

— Бар гына түгел, бик күп. Хатын-кызлар ба-

рыбыз да шундый бит инде. Башта хис, аннан соң гына акыл өстенлек итә бездә.

**— Егетең дә көнләшәме?**

— Ул бик сабыр кеше. Шуңа яратам да мин аны. Дөрес, көнчелек чалымнары да күренгәли. Әмма ул миңа ышана.

**— Газетага биргән анонста «Венера «Салкын чәй»сез дә калды» дип язган идек.**

— Бер ел элек Камәрия апа Вәлиева белән очрашып күрештек. Шул вакыт ул: «Беркемгә дә биргәнем юк, яңа гына язылган», — дип, берничә шигырен бирде миңа. «Салкын чәй» шигыре иң ошаганы булды. «Бусын башкаларга тәкъдим итмәгез», — дидем Камәрия апага. Ул вәгъдә бирде. Озакка сузмыйча, шигырьне композитор Илфат Дәүләтшинга күрсәттем. Әмма ул, бу бит «шырт та пырт» дип, шигырьне яратмады. Аны гаепләп әйтүем түгел. Илфат абый күбрәк фәлсәфи шигырьләрне үз итә. Шулай итеп, «Салкын чәй»гә көй язу арткы планга күчерелде. Салават башкаруында ул җырны ишетү минем өчен чын мәгънәсендә зур югалту булды. Аны ир-ат авызыннан ишеткәч, аптырап та калдым әле. Татар халкында чәйне күбрәк хатын-кызлар эчә. Шуңа күрә Салаватның салкын чәй эчеп, кемнедер көтеп утыруын күз алдыма да китерә алмыйм. Егет кеше көтеп утырырга түгел, башлап үзе барырга, үзе сүз катарга тиештер. Нишләтәсең, дөнья шулай югалту-табышлардан тора. Бу югалтуым өчен алда икеләтә зур табыш көтәдер дип өметләнеп торам әле, Алла боерса.

**— Бүген син — Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясе студенты. Укучының укытучысы була инде аның. Синең остазың кем?**

— Беренче остазым Клавдия Захаровна Щербинина булды. Аңа 78 яшь. Бик күп сәхнә осталарын укыткан укытучы. Мин хәзер инде аның укучысында — Венера Әхәт кызы Ганиевада белем алам. Бу минем өчен бик зур бәхет. Ходайның биргәненә шөкер, бүгенге көндә Клавдия Захаровнаның мәктәбен дәвам итәм.

**— Венера, син кечкенәдән җырлыйсың. Телевизор экраныннан карап кына үстердек үзеңне. Шулай да олы сәхнәгә чыгаручы кешең кем булды?**

— Балык Бистәсендә яңа мәктәп ачылды. Бәйрәмгә Мәдәният, Мәгариф министрлыкларыннан да килгәннәр иде. Кунаклар алдында мин дә җырладым. Ул чакта бишенче сыйныфта гына укый идем әле. Шуннан соң аларның тәкъдиме белән Татарстан телевидениесе минем турыда фильм төшерде. Габделфәт Сафин мине телевизордан күреп калган. Өйгә шылтыратып: «Казанда минем концертларым була. Кил, җырларсың», — диде. Яз көне иде. Мин тәвәккәлләп килдем һәм берниндирепетициясез дүрт көн буе опера театры сәхнәсендә җырчының концертларында җырладым. Шуннан башланды. Мәскәү, Чаллы, Казан...

**— Хәзер инде сигез ел бергә эшлисез. Габделфәт — бик таләпчән җырчы. Үзенә дә, үзе белән бергә эшләүчеләргә дә. Аның белән иҗат итү авыр түгелме?**

— Иҗатта таләпчән булмаган кеше хәзерге шоу-бизнес заманында җиңә алмый. Бу уңайдан без аның белән бер-беребезне аңлыйбыз. Гомумән, миңа эшләргә авыр дип әйтмәс идем. Габделфәт абыйның иҗат берләшмәсе миңа репертуар сайлаганда да, җырларга музыкаль бизәлеш ясаганда да, киемнәр тектергәндә дә булыша.

**— Инде өченче тапкыр бугай, «Хыянәт»кә тагын әйләнеп кайтыйк әле. Ул җырдан соң дус кызларың арасында сиңа сөяркә дип караучылар булмадымы?**

— Артымда сөйләүчеләр, бәлки, булгандыр да, үземә әйтүчеләр булмады.

**— Бу җыр халык арасында популяр булып китәр дип уйланылган идеме?**

— Бормалы көен, үтемле сүзләрен истә тотып, без аның популяр җыр булачагын сизендек. Җырның авторы Тәслимә Низамига рәхмәт. Бу җырны Габделфәт абыйга ул тәкъдим иткән. Габделфәт Сафинда интуиция бик көчле. Ул, җырның шигырь текс-

тын дуэтка яраклаштырганнан соң, миннән: «Син бу җырны минем белән җырларга ризамы, әзерме?» — дип сорады. Уйламыйча гына булмады шул. Без күпмедер дәрәҗәдә ут белән «уйнадык». Мин үземнең яшьлегемне, киләчәгемне, ә Габделфәт абый гаиләсен кыл өстенә куйды. Бу гади җыр түгел иде. Үз имиджымны булдыруда ярдәм иткәне өчен катлаулы драматик җырны сәхнәгә куючы һәм әзерләүче Рүзилә апага да рәхмәтем зур.

**— Венера, уңышлар сиңа, киләчәктә мондый табышлы җырларың бик күп булсын.**

*«Акчарлак» газетасы*
*2001 ел, февраль*

# «Җырларга дип кайттым...»



*Хәмдүнә Тимергалиеваның җырлавын ишеткән саен, күңелемдә бала чактагы бер хатирә яңара.*

*...Кыш. Без, тугыз-ун яшьлек балалар, кое янындагы тауда чана шуабыз. Шул вакыт дус кызымның әнисе Рауза апа, капкадан башын тыгып, безгә:*

*— Кызлар, Хәмдүнә радиодан «Җомга»ны җырлый, — дип кычкырды.*

*Ап-ак карга чумган килеш, өсләребезне, киез итекләребезне дә какмыйча, өйгә йөгердек. Җырның ахырын гына ишетеп калсак та, бәхетле идек без...*

*Бүген исә мин бала чагымда үзем табынган артистның каршысында утырам. Аңа үземне кызыксындырган сорауларны бирәм.*

**— Хәмдүнә апа, Сез соңгы вакытта сәхнәдән китеп тордыгыз шикелле. Сәхнәдән генә түгел, Татарстаннан да киттегез бугай әле. Җырларыгыз яңгыраса да, үзегез күренмәдегез.**

— Без, артист халкы, шулай бит инде. Бүген — монда, иртәгә — тегендә. Элек тә минем ярты гомерем туган ягым Башкортстанда уза иде. Җәй көне айлар буе авылда печән, утын әзерли идем. Әнкәемне мунча кертү өчен генә дә атна саен туган авылым Котлыярга кайтып йөрдем мин. Атнаның бишенче көнендә поездга утырып чыгып китәм, мунча ягып әнкәемне юындырам, чабындырам да дүшәмбе көнне кабат Казанда була идем. Әнием, мәрхүмә, дүрт ел урын өстендә ятты. Аны карап, тәрбияләп, соңгы юлга озаттым. Аллага шөкер, хәер-фатихасын алып калдым. Әнкәйне җирләгәнгә дә өч ел булды инде. Ә соңгы елларда сәхнәдән югалып торуым шәхси сәбәпләр аркасында булды. Мин, кияүгә чыгып, авылга күчендем. Инде менә, халкым алдында җырларга дип, кабат Казанга кайттым.

**— Бөтенләйгәме?**

— Алай ук димәс идем, чөнки минем ярты җаным, бөтен туганнарым Башкортстанда.

**— Казанга гаиләгез белән күчәсездер инде алайса?**

— Юк. Ирем Шауядыда колхоз рәисе булып эшли. Хәзергә икебез ике җирдә.

**— Шулай итеп аерым-аерым яшәрсезмени?**

— Киткәндә аерым, кайтканда бергә инде. Язмышыбыз шулайдыр. *(Көлә.)*

**— Хәмдүнә апа, әйдәгез, иң элек Сезнең яшьлек хатирәләрегезне яңартыйк әле. Казанга ки-**

**леп, филармониядә эшли башлаган чакларыгызны искә төшерик.**

— Башкортстанның Тәтешле районында мәктәптә эшли идем. Музыка укытам. Ул вакытта Стәрлетамак музыка-агарту училищесын тәмамлаган идем. Авылга бер төркем Казан артистлары килде. Алар белән концертта мин дә җырладым. Шунда Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә биюче Ильяс абый Якупов: «Тавышың матур, кил әле син Казанга, бәлки, җырлап китәрсең», — диде. Килдем. Тыңлап карадылар да ансамбльгә барырга тәкъдим иттеләр. Хезмәт хакы аз булганлыктан, кире Башкортстанга кайтып киттем. Көзен телеграмма артыннан телеграмма җибәреп, Эмил Җәләлетдинов төркеменә җырларга чакырдылар. Киттем кире Казанга. Җырлыйсы килү теләге көчле иде шул. 1976 елның 26 октябре иде бу.

**— Мине кызыксындырган тагын бер сорау. Татарстанның халык артисты Хәмдүнә Тимергалиева яшь килен булып авылга кайта. Авыл халкы ничек кабул итте инде җырчы киленне?**

— Иң беренче эш итеп йорт салырга тотындык без. Өй тирәсендә кайтарып аударылган агачлар өелеп ята иде. Апрель ае буенча ук булмаса да, егерме көнләп утын ярдым. Яз көне тиз ярыла бит ул. Җырчы ничек утын яра икән дип, бөтен авыл халкы килеп карады. Шуннан китте инде сүзләр. Ярган утынымны, җир кипкәч, июль аенда уникe йөк машинасына төяделәр. Эштән курыкмыйм. Егерме баш умартабыз гына бар. Маллар тотабыз. Канатларың пар булса, эш ул берни түгел. Үзеннән-үзе үрелеп кенә бара. Гомумән, эш эшләми тора алмыйм мин, күнекмәгән.

**— Флорид та гомер буе сезне көткәнме?**

— Ул өйләнгән кеше булган, аның хатыны Себердә, ул инде кабат тормышка чыккан. Улы исә монда, Казанда укый. Әтисе янына кайтып йөри.

**— Хәмдүнә апа, хатынына хыянәт итмәгән ирләр бик сирәк, дип, хәзер туктаусыз сөйләп тә, язып та торалар. Ә Сез тыныч кына Флоридыгызны Шауядыда калдыргансыз.**

— Ә мин ул хакта уйламыйм.

**— Ә үзегез хыянәтне кичерә алыр идегезме?**

— Кичерә алмас идем... Чөнки ирем минем ярты җаныма әйләнде инде. Яратуыма тап төшерә икән, алга таба аңа ничек ышаныш яшисең? Яшь вакытыбыз түгел бит. Хәзер мин күп нәрсә турында бөтенләй башкача уйлыйм.

**— Хатын-кыз һәм җырчы буларак Сез бәхетлеме?**

— Бәхетне кем ничек аңлый бит. Җырчы буларак мин, әлбәттә, бәхетле. Ә тормышта кеше үз гомерендә биш минут кына бәхетле булырга һәм шул мизгелләрне уйлап, еллар буе яшәргә мөмкин. Ир белән хатынның бер түбә астында көн итүләре бу әле алар бәхетле дигән сүз түгел. Бик күп гаиләле кешеләр, янәшәдә ирләре, хатыннары була торып та, үзләрен ялгыз хис итәләр. Мин бәхетле, дип авыз тутырып әйтүчеләргә ышаныш бетмим мин.

*«Акчарлак» газетасы*
*2001 ел, март*

# Ни өчендер безнең язмыш шундый...



**— Әңгәмәбезне дөньяга шигъри җанлы Шәмсияне бүләк иткән мәрхәмәтле ана белән танышудан башлыйк әле.**

— Минем әнием Мосаллия исемле. Гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә, *намаз укучы хатын-кыз* дигән мәгънәне аңлата. Чыннан да, аның исеме җисеменә бик туры килә. Ул гомере буе намаз укый, ураза тота. Бүген аңа 86 яшь. Гомере буе колхозда эшләп, дүрт кызын берүзе тәрбияләп үстерде, белем бирде. Баекка Мөслим районы Күбәк авылыннан килен булып төшкән. Язмыш җилләре аркасында туган авылына кире кайтып киткән дә булыр иде. Ләкин ул Баекта төпләнеп калган. Хәлле кеше, кулак кызы булуына карамастан, Октябрь инкыйлабы аркасында аңа белем алырга туры килми. Казанда 10 нчы интернат-мәктәптә укыган вакытта, мин: «Әнием колхозчы, әтием юк», — дип әйтергә ояла идем. Хәзер шул чакларга кайтып уйлап карасам, үзем өчен оят булып китә, миндәге барлык яхшы

сыйфатларны әтием белән әнием биргән бит. Бүгенге көндә әнием исән-сау, камил акыллы, Аллага шөкер. Ул — минем горурлыгым. Кайчан кайтсам да, ашы пешкән, чәе кайнаган, өе чип-чиста.

**— Әнкәем җил-яңгыр тидерми үстерде,**
**Тормышта ул миңа зур терәк.**
**«Әнием» дигәндә, «әткәем» дияргә**
**Син кирәк, әткәем, бик кирәк.**

**Шәмсия ханым, мин сезнең әтиегез гүр иясе булгандыр, шуңа күрә сезнең шигърияттә бик аз урын алгандыр дип уйлый идем...**

— Бу — минем күңелемдәге иң яшерен һәм иң ачы сер. Әтием исән-сау. Үзебезнең авылда ук башка гаилә белән яши. Анда биш баласы бар. Безне калдырып киткәндә, миңа бер яшьтән аз гына артык булган. Шуңа күрә мин аны хәтерләмим. Беләм дә, белмим дә кебек. Бер авылда яшәсәк тә, урамда кара-каршы очрашкан чакларда, ул миңа «кызым» дип дәшәргә, сөйләшеп торырга курка иде. Язмыш, тормыш шактый катлаулы шул. Мин әтиемне яратам. Авыл кешеләре төрлечә сөйлиләр иде. «Әтиең гаепле, шундый булган хатынны ташлап чыгып китте», — дип тә әйтәләр иде. Яратуым аркасындадыр, ахры, мин әтиемне һәрвакыт акладым. Башка гаилә коруы өчен һич кенә дә гаепләмим. Моның без аңламаган сәбәпләре булгандыр. Әмма икенче гаилә корып әтием бәхетле булса, мин дә икеләтә бәхетле булыр идем. Мин аңа карыйм да елыйсым килә. Бәхетле кешенең кигән киеменнән, атлап йөрешеннән үк бәхет бөркелә, күзләрендә яшәү чаткысы балкый. Әтиемдә мин андый чагылышны күргәнем юк.

Ир белән хатынның аерылышуына мин лояль карыйм. Кеше гаилә корып ялгышканын аңлый икән, нигә үзен һәм гаиләдәге кешеләрне интектереп яшәргә?! Ул бәхетен башка җирдән табарга тиеш тер. Әтием бик акыллы, тырыш кеше. Кулыннан килмәгән бер эше дә юк. Мин аңа булган мәхәббәтемне шигърияттә чагылдыра алмасам да, «Яшел гармун» дигән повестемда яктырттым.

**— Әтиегез белән күрешкәнегез бармы?**

— 1997 елда туган авылыма Сабантуйга кайткан идем. Миңа: «Сине бер кеше күрергә тели», — дип килеп әйттеләр. Кем икәнлеге белән кызыксынгач: «Әтиең»,— диделәр. Үз колакларыма үзем ышанмадым. Шушы яшемә җитеп, бер тапкыр да очрашып сүз алышмаган әти минем белән күрешергә тели! Карыйм, дөрестән дә, мәйдан кырыннан читтәрәк әтием басып тора. Мин, үзем дә аңламастан, шунда таба атладым. Бу очрашуны, бу хисне сүз белән генә аңлатып булмый. Ул миннән күз яшьләре белән бәхиллек сорады. Без икебез дә озак елаштык. Сабантуй мәйданына җыелган халыкның бөтен игътибары безгә күчте. Без елыйбыз, безгә карап, халык елый. Мин чыгыш ясарга тиеш идем. Мәйданда шигырьләремне түгел, әтиемә багышланган «Яшел гармун» повестеннан бер өзек укыдым. Әтием миңа чәчәкләр бүләк итте.

**— Сине өзелеп сөюемне**
**Ничек аңлатыйм икән?**
**Йокыларыңнан уятып,**
**Таң булып атыйм микән?**

**Кем өчен өзелгән булган икән Шәмсия бу юлларны язганда?**

— Бу шигырь мәрхүм ирем Назыймга багышланган.

...Стипендия алып «баеган» көнне мин, университет ашханәсенә кереп, манный боткасы ашап чыга идем. Назыйм беренче мәртәбә мине шунда күргән һәм гашыйк булган. Ике ел буе күзәтеп йөргән. «Сине күрмәмме дип, көн саен сезнең ашханәгә йөрдем», — ди иде. Без өйләнешкәндә, Назыйм төзүчеләр институтын тәмамламаган иде әле. Дүртенче курстан соң аны Пермьгә практикага җибәрделәр. Телефоннан көн саен диярлек сөйләшеп торабыз. Төннәр буе Назыймны сагынып елап чыгам һәм аңа багышлап шигырьләр язам. «Нишлим?» дигән, соңрак җыр булып киткән шигырь Назыймга багышлап шул вакытта язылды.

**— Нәрсә күрдем соң мин бу тормышта?**
**Дүрт кешегә — 17 квадрат...**
**Өстәл, телевизор, пианино,**
**Ике якта — ике караваt...**

— 17 квадрат метрлы бүлмәдә яшәгән чакларны хәзер исемә төшерсәм, ничек яшәдем икән дип, тәннәрем чымырдап китә.

Назыйм институтны тәмамлагач, без Әлмәткә киттек. Анда алты ел яшәдек. Бала чагым, яшьлегем узган Казан мине гел үзенә тартты. Безнең ул вакытта ике бүлмәле фатирыбыз бар иде инде. Эзли торгач, шуны Казанга алмаштыру мөмкинлеген таптык. Зорге урамындагы өч бүлмәле фатирның бер бүлмәсенә күчеп килдек. Калган ике бүлмәдә күршеләр. Күрше бүлмәдәге рус карчыгын унөч ел тәрбияләдем. Утырып елаган чакларым күп булды. Авырлыклар күреп караган кеше белә, андый чакта Ходай Тәгалә үзе сабырлык бирә, үзе булыша.

17 квадрат метрда да мин матур тормыш белән яшәргә, гаилә җылысын сакларга тырыштым. Иремнең туганнары һәрвакыт безнең белән бергә булдылар. Бүлмәбез гел кунаклар белән тулып торды.

Менә шулай яшәп ятканда, ирем авырып китте. Бу 1988 елның май ае иде. Октябрьдә бу авыруның рак булуы ачыкланды. Табиб бүлмәсендә мин аңымны югалтып егылганмын...

Шул көннәрдә безгә моңарчы кунакка йөргән дуслар, туганнар юкка чыкты. Мин аларны гаепләмим. Авыру янына йөрү җиңел түгел. Назыйм үзе дә, балалар да әтиләренең нинди авыру белән авырганын белмәделәр. Ул чакта бердәнбер сердәшем кәгазь белән каләм булды. Операцияләрнең саны унҗидедән артып киткәч кенә, улым белән кызыма серне чиштем. Бу авыру турында язылган бик күп китаплар укыдым. Әлеге чир белән кешенең озак яшәгәндә дә өч елдан артык тора алмаганлыгын аңладым. Ә мин иремне тәрбияләп биш ел яшәтә алдым. 1988 елның 9 ноябрендә беренче тапкыр шифаханәгә салган идем, 1993 елның 12 ноябрендә вафат булды. Үзендә нинди авыру икәнлеген белмә-

гәч, яшәүгә өмете өзелмәгән килеш үлеп китте дип юанам.

**— Моңа кадәр белмәгәнмен генә,**
**Төннәр о-о-зз-ын икән.**
**Иң читене гомер уртасында**
**Ялгыз калу икән.**

— Ирем һәрвакыт: «Мин 85 яшькә кадәр яшим», — дип әйтә иде. Ходай аңа озын гомер биргән булса, гомер ахырына кадәр бергә атлаган булыр идек. Мин ялгыз калдым. Кемнедер бәхетле итә алып та, кемнедер кадерләп яшәргә сәләтем була торып та, шундый бәхетнең насыйп булмавын аңлаганга, бу ялгызлыкны авыр кичердем. Балаларымның ятим, әтисез калулары да үзәкне өзде. Парлы вакытта кунакка барганда, «Лилияне чакырмыйбыз, монда килеп безнең ирләргә күзләрен тозландырып утырмасын әле...» дигән сүзләрне еш ишетә идем. Назыйм үлгәч, миңа да шушы язмыш килде. Ул чакларда, парлылар чакырса да, парсызлар чакырса да, кунакка бармадым. Ялгыз хатын-кыз турында төрле сүзләр йөри бит ул. Миңа да күп ишетергә туры килде аларны.

**— Мин сине Ходайдан сорап алдым.**
**«Очрат, — дидем, — миңа шундыйны —**
**Күкрәгенә газиз башым салып,**
**Эч серемне сөйләп булырны».**

— Җирдә һәркем үзенең яраткан кешесен тапканчы эзләргә тиештер. Әгәр дә җаннар, тәннәр бәйләнмәгән булса, загс кәгазьләре генә ике йөрәкне беркетә дә, бәхетле итә дә алмыйдыр. Тормышта мондый гыйбрәтле хәлләр бик күп. Кешенең үз тиңен эзләргә хакы бардыр дип уйлыйм. Ходай язган тиңен. Мин 42 яшемдә ялгыз калдым да, башка яратырга да, яратылырга да хакым юк дигән сүз түгел бит әле. Монда мин хатын-кыз буларак фикер йөртәм. Ә хатын-кызлар, минемчә, ике төрлегә бүленә. Бер төрлеләре яратмыйча яши, тормыш кора алмый,

икенчесе яратмыйча да менә дигән итеп гомер кичерә. Мин үзем беренче төркемгә керәм. Аллага шөкер, Ходай миңа юлымда андый кешене бирде.

**— Сөюләргә сусап, исемеңне**
**Бар дөньяга сөрәнләрлек чакта,**
**Бер Ходайдан сабырлыклар сорыйм —**
**Кешеләргә сөйләп ялгышмаска, —**

**дигән шигырегез белән нокта куеп, сүзне икенчегә борыйк әле.**

**Без яши белмәдек...**
**Улым белән кызым**
**Миннән акыллырак булсыннар.**
**Миннән бәхетлерәк булсыннар, —**

**дигәнсез.**

— Шулай дип язсам да, гомеремне яңадан башларга туры килсә, мин нәкъ шул ук юлдан китәр идем. Күңелемнең бер ягы белән мин балаларымның усал, хәйләкәр кешеләр янында хәйләкәр булып яшәүләрен теләсәм, икенче ягы белән эчкерсез, беркатлы булуларын телим. Киләчәктә аларның үз язмышларын башкаларныкы белән бәйлиселәре бар. Миннән акыллырак, бәхетлерәк булсыннар дигәндә, мин нәкъ менә шуны күз алдымда тоттым. Улым Илдар, Казан дәүләт университетының тарих факультетын тәмамлап, Казан шәһәре эчке эшләр идарәсендә эшли. Кызым Гөлназ консерваториядә укый. Әле икесе дә башлы-күзле булмадылар. Мин аларның яннарында җаннары теләгән, үзләре яраткан кешеләр булыр дип ышанам.

**— Без күнеккән**
**Эшкә барып, эштән кайтырга.**
**Эш турында уйлап кич буена,**
**Төнлә төштә күреп ятырга.**

— Йа Аллам, ярый әле эш бар. Гомер буе шул эш тә эш инде дип зарлансак та, эшсез торсак, мөгаен, үләр идек. Ярый әле төн йокыларын бүлеп төш-

ләргә керә, үзе турында, нәкъ шигырьдәгечә, туктаусыз уйлата торган эш бар. Күп ашасаң, тәмле әйбер дә туйдыра дигәндәй, сез хәзер телгә алган ул шигырьне язганда, эштән арып киткән мәлем булгандыр. Ә болай, Аллага шөкер, бернинди эштән дә курыкканым, мин моны булдыра алмыйм дигәнем юк. Кечкенәдән шулай булдым, ат та җиктем, сәгать тә төзәттем, койма да койдым, печән-утын да ташыдым, алтынчы сыйныфта укыганда, хәтта, бер генә кадак та какмыйча, гел агач чөйләр белән генә урындык ясаганым да хәтердә. Ул урындыклар әле дә исән. «Ялкау ятыр, бәхете артыр» дисәләр дә, минем бәхетем эшләгән саен арта. Тәнең сау-сәламәт, аяк-кулларың исән булганда, физик эштән дә, акыл эшеннән дә курыкмаска кирәк, эштән курыкмаган кешенең гәүдәсе сылу, акыл-фигыле камил була. Гомеремдә өч урында: Әлмәт шәһәренең 27 нче номерлы балалар бакчасында, Татарстан китап нәшриятында һәм Татарстан радиосында эшләргә туры килде. Шөкер, кайда да минем өчен кызарырга туры килмәде җитәкчеләргә. Үзем җитәкче булганда да, хезмәттәшләремнең минем өчен оялмаганнарына ышанам. Күптән түгел миңа хезмәттәшләремнең берсе: «Сине Татарстан радиосы кеше итте», — диде. Ә мин аңа: « Анасыннан кеше булып тумаган кешене беркем дә кеше итә алмый», — дидем. Һәм дөрес әйттем.

**— Күргән төшләрем сөйләсәм,**
**Начарга юрамагыз.**
**Авыр булмасын дисәгез,**
**Хәлемне сорамагыз...**

— Без бит бер-беребез белән очрашканда, хәлең ничек, дип сорарга күнеккәнбез. Хәлнең дөресен сөйләргә туры килсә, гел зарлану гына булыр иде кебек. Әлбәттә, бу тормышта яшәве миңа бик җиңел дип әйтмәс идем. Әниемнең һәрвакыт кабатлый торган сүзе бар: «Авызыңда кара кан булса да, кеше алдында төкермә», — ди ул. Зарланмау, авырлыкларны күрсәтмәскә тырышу башымны горур

йөртергә мөмкинлек бирә. Дусларымның күп һәм ышанычлы булулары, кирәк чакта киңәшләре белән ярдәм итүләрен тою көч өсти.

**— Шәмсия ханым, шигъри юллар аша сөйләшкән бу әңгәмәгә, кабат сезнең сүзләргә мөрәҗәгать итеп, нокта куйыйк.**

**Сихри дөнья һаман алга дәшә,**
**Бер күкрәп, бер килә яшьнисе.**
**Кадерләрен белеп гомерләрнең,**
**Яшисе дә әле яшисе.**

*«Акчарлак» газетасы*
*2001 ел, апрель*

# «Җырчы шәхес булырга тиеш...»



*Зөһрә Сәхәбиеваның җырлавында, сәхнәдә үз-үзен тотышында халкыбызның сабырлыгы, тыйнаклыгы, аклыгы, пакьлеге чагыла сыман. Соңгы елларда сәхнәдән югалып торса да, аның башкаруындагы җырлар радиода, телевидениедә һәрвакыт яңгырап торды. Зөһрә ханым белән моңарчы күзгә-күз очрашып сөйләшкәнебез булмаса да, телефон аша гел шылтыратышып, хәл-әхвәл белешеп тора идек. Газета укучыларыбызның теләкләрен истә тотып һәм, әлбәттә инде, үземнең дә аны күреп сөйләшәсем килеп, мин, ниһаять, Чехов урамында урнашкан йортка юл тоттым.*

*Ишекне Зөһрә ханым үзе ачты. Күптәнге дуслардай кочаклашып күрештек. Күптән түгел генә шифаханәдән чыкканын белгәнгә, кәефе яхшы икәнлеген күреп, аның өчен шатланып куйдым.*

*Зур гына фатир. «Күптән ремонт ясаганыбыз*

*юк, игътибар итмә», — дисә дә, һәр җирдә тәртип, чисталык, пөхтәлек.*

*«Менә бу ишекне Хәйдәр алмаштырып калдырды, башкаларына әле кул тими», — диде Зөһрә ханым. Шкафта бик күп китаплар. Алар арасында халкыбызның мәшһүр җырчысы Хәйдәр Бигичевның зур фотосы. «Шушы рәсемгә карап, Хәйдәрем белән сөйләшеп алам», — ди ул. Кухня ягына узып, сөйләшә-сөйләшә бал белән чәй эчкән арада: «Әнием, мин кайттым. Синең хәлең ничек?» — дип, улы Айрат та кайтып керде. Әтисе кебек озын буйлы, таза гәүдәле Айрат. Казан дәүләт финанс-икътисад институтын тәмамлап йөри икән.*

*Зал ягына чыгып, йомшак диванга утырдык та, мин үземне кызыксындырган сорауларны Татарстанның халык артистына, мәшһүр җырчыбызга җиткердем.*

**— Зөһрә ханым, әйдәгез, иң элек сезнең туган якны, бала чакны, әти-әниегезне искә төшерик әле.**

— Минем тормышны сөйли башласаң, бер китап язарга кирәк булыр иде. Шуңа да гомеремдәге кайбер мизгелләрне генә искә төшерәм. Мин элекке Сарман, хәзерге Тукай районы Салих Тукай авылында әтием Габделкотдус, әнием Миңлегөл гаиләсендә бишенче кыз булып дөньяга килгәнмен. Мин туганда, әтиемә 45, әниемә 42, иң олы апама 21 яшь булган. Әти-әнием, Аллага шөкер, тигезлек белән мине 33 яшемә җиткерделәр. Икесе дә дингә нык ышанган, Коръәнне аңлап укый торган кешеләр иде. Гаиләдә бер-берсенә мөнәсәбәтләре дә мөселманнарча булды. Ир — баш, ир — хуҗа. Ул балаларына да, хатынына да хөрмәт белән карарга, аларны матди яктан тәэмин итәргә, ә хатын ирне дә, балаларны да тәрбияләргә тиеш. Алар бу сыйфатларны бездә, кызларында да тәрбияләделәр.

**— Төпчек бала булгач, Сезгә авылда эш күп эләккән инде алайса?**

— Мине малай дип көткәннәр. Шуңа күрә, әтигә авырга килмәсен дип, гел аның янында кайнаша

идем. Әле дә хәтеремдә, миңа 5–6 яшьләр тирәседер. Әни авырып тора. Көтү каршыларга кеше юк. Әни бишмәт кидереп билемне кысып бәйләде дә мине сыерны алып кайтырга дип җибәрде. Үзем сыер тезеннән генә, шулай да куып алып кайттым. Әнием: «Төпчегем дә эшкә ярый башлады», — дип шатланып, аркамнан сөйгән иде. Менә шуннан мин кул арасына керә башладым. Әти белән җәен печән, утын әзерлибез. Аннан әти белән, кара-каршы утырып, юан бүрәнәләрне ышкылап зур сарай салдык. Малай урынына төпчек булып туганга, үземне бар эшкә дә җаваплы саный идем.

**— Аннан туган авылыгыздагы башлангыч мәктәпкә укырга кердегез инде, әйеме?**

— Авылыбыз кечкенә безнең. Анда ике сыйныф кына укыдым да сигез чакрым ераклыктагы Иске Дөрешкә киттем, 9–10 нчы сыйныфларга исә 12 чакрым ераклыктагы Теләнче Тамак мәктәбенә йөрдем.

**— Мәктәпне тәмамлагач, юллар Сезне Казанга алып килә...**

— Минем бик тә укыйсым килде. Укытучылар Ленинградтагы театр артистлары әзерли торган уку йортына барырга киңәш иттеләр. Әтине дә үгетләделәр. Ләкин ул: «Артист тормышы — чегән тормышы», — дип каршы килде. Мин әтидән гармун алып бирүен дә үтенгән идем. Ул: «Гармун уйнау кыз бала эше түгел, син әнә җырла. Анысына мин риза. Җырлау гөнаһ түгел. Моң ул пәйгамбәрләрдән калган», — диде. Җырчы буласым килсә дә, мин медицина училищесын сайладым. Укып чыгармын да авылга кайтып әти-әниемне карармын дип уйладым. Шулай итеп, Хәдия апама ияреп, Казанга килеп төштем.

**— Укырга керү җиңелдән булмагандыр?**

— Керү имтиханнары турында белешергә училищега баргач, аптырап калдым. Имтиханнарны рус телендә тапшырырга кирәк икән бит. Ә мин «эремә» сүзенең дә рус телендә ничек икәнлеген белмим. Шулай да, тырыша торгач, имтиханнарны уңышлы гына тапшырып укырга кердем.

**— Зөһрә ханым, ә җырчы булу теләге кайчан туды?**

— Ул вакытта Сәетгалиев исемендәге мәдәният йортында (Дәрвишләр бистәсендә) Рәис Сафиуллин җитәкчелегендә үзешчән коллектив эшли иде. Мин шунда йөри башладым. Рәис абый җәйге каникул вакытында мине профессиональ артистлар белән гастрольләргә дә алып чыкты. Мәскәүгә кадәр барып концерт куйдык. Рәис абыйның «Зөһрә, синең кебек моңлы тавыш сирәк. Сиңа һичшиксез укырга кирәк» дигән сүзләре минем тормышымны кисәк кенә 180 градуска үзгәртте дә куйды. Бу вакытта инде училищены тәмамлап, 15 нче шәһәр шифаханәсендә шәфкать туташы булып эшли идем. Миндә консерваториягә укырга керәсе килү теләге туды. Ул уку йортының ни икәнлеген дә белмим үзем. Хәзерге аңым булса, анда барырга куркыр идем.

**— Ничек барып кердегез инде консерваториягә?**

— Беркөнне, төнге дежурдан кайткач, киттем консерваториягә. Ике педагог — соңыннан гына белдем, алар тәҗрибәле вокал укытучылары Владимир Воронов белән Михаил Кольцовлар булган икән — Мөнир Мазунов һәм Мансур Мозаффаров иҗат иткән «Туган як» дигән җырымны тыңладылар. Ике куплетын җырладым, өченчесенә тавыш бетте. Укытучылар бер-берсенә караштылар да миңа: «Без сиңа документларыңны консерваториягә бирергә киңәш итмибез. Синең тавышың халыкчан. Бездә андый белем бирүчеләр юк», — диделәр. И-и, күңелем төште инде. Тавышым беткәнгә алмыйлар дип уйлап, елый-елый кайтып киттем. Үҗәтлек тә бар үземдә. Документларны барыбер илтеп тапшырдым консерваториягә.

**— Сез бит инде бу вакытта шифаханәдә дә эшләгәнсез?**

— Әйе. Имтихан тапшырырга сорап кына бардым. Ике турны да уңышлы уздым. Икенче турдан соң: «Сине ректор бүлмәсенә чакыралар», — диделәр. Җырлавымны ул вакытта, бәхеткә каршы, Нәҗип Гаязович Җиһанов үзе тыңлаган булып чыкты.

«Сезнең тавыш — милли тавыш. Бездә андый бүлек юк. Шулай да сезне эксперимент рәвешендә кабул итәбез», — диде ул. Очып кайттым мин ул көнне өйгә.

**— Шуннан соң Сезнең өчен кабат студент тормышы башланды инде.**

— Тулай торактан бүлмә бирделәр. Дүрт кыз торабыз. Үз караватым булу минем өчен хан сараенда яшәү белән бер иде. Карават асты минеке, тумбочка минеке, кием юк инде, бер итәк тә бер кофта, аларны эләргә карават башы да минеке. Укулар башланды. Ләкин мин шифаханәне ташламадым. Алты ел буе көндез укыдым, төнлә шәфкать туташы булып дежур тордым. Яшәргә, ашарга, киенергә кирәк иде. Шимбә-якшәмбе көннәрендә авылга, әтиәни янына ашыга идем. Печән, утын әзерләшергә, көтү көтәргә.

**— Хәйдәр абый белән танышуыгыз кайчан булды?**

— Ул чакта әзерлек бүлегенә беренче курска ике генә кешене алганнар иде. Көзен укырга килгәч, тагын бер егетне алулары билгеле булды. Ул инде армиядә хезмәт иткән. Күз төшәрлек чибәр үзе — озын буйлы, таза төз гәүдәле. Ләкин күзләре бик моңсу иде аның. Беренче күрүдән үк шуңа игътибар иттем. Сөйләшә-аралаша башлагач белдем, беренчедән, еракта — Сергач якларында калган әнисе өчен борчыла, икенчедән, кан басымы югары икән. Мин бит шәфкать туташы. Аңа гел ярдәм итә идем. Дуслыгыбыз мәхәббәткә әйләнде, һәм без студент елларында ук бу егет белән өйләнештек. Ике якта да никах укыттык. Әмма язылышырга акчабыз булмады. Хәйдәр егетләр белән, мин кызлар белән яшәдем. Җәйге каникулларны бергәләп авылда уздырдык. Мин диплом алган елны гына язылыштык. Хәйдәр авыруы аркасында бер елга укуын соңрак тәмамлады.

**— Бездә яшь гаилә өчен иң беренче проблема — торак мәсьәләсе. Ул ничек хәл ителде?**

— Фатирга кердек. Үзебезнең түләргә акчабыз да юк. Безгә ул вакытта Нияз Даутов ярдәм итте,

акча биреп торды. Мең рәхмәт аңа. Хәйдәр төп рольләрне җырлый башлагач, мин популярлашып киткәч, улыбыз Айрат та тугач, безгә өч бүлмәле фатирның бер бүлмәсен бирделәр. И-и ул вакытлар! Кулда яшь бала. Ул төннәр буе елый. Хәйдәрнең икенче көнне спектакльдә җырлыйсы бар. Раскладушканы күтәрә дә уртак кухняга чыгып китә иде. Айратка алты ай булгач, мин дә эшкә чыктым. Яшәргә кирәк. Икебез дә опера театрында. Хәйдәр 110 сум, мин 90 сум акча алабыз. Ашарга, киенергә, сәхнә киемнәре тектерергә кирәк. Әти-әниләргә дә булышырга тырышабыз. Кешедән ким булмадык, Аллага шөкер. Айрат укырга кермәгән иде әле, безгә Татарстан урамыннан өч бүлмәле фатир бирделәр.

**— Килен булып төшкәч, сезне мишәр авылында ничек каршы алдылар?**

— Ул төбәктәге милләттәшләребез башта һәрнәрсәгә сагаеп карыйлар. Анда кайтып төшкәч, Америкага эләктем дип торам. Ярты сүзләрен аңламыйм, интонацияләре башкача. Хәзер Түбән Новгород татарлары белән бик яхшы сөйләшәм. Хәйдәр бит ул һәрьяктан зур талант иясе иде. Әдәби телгә өйрәнеп тормады, күчте генә. Хәйдәрнең гаиләсендә киленнәргә бик таләпчәнлек күрсәтәләр, каты торалар. Ул сөйли иде, аның әнисенә, мәсәлән, инде балалар үсеп беткәч тә, бөтен гаилә утырып ашаган өстәл артына утырырга ярамаган. Ул почмак якта ашарга тиеш булган. Әмма, гомумән әйткәндә, Хәйдәремнең авылдашлары да, ул төбәктә яшәүче халык та мине шәхес буларак та, җырчы буларак та яратып кабул иттеләр.

**— Ике шәхеснең бер гаиләдә яшәве җиңел булмагандыр. Көнләшү хисе бар идеме сезнең арада?**

— Без бер-беребезне аңлап яшәдек. Ул тормышта да Отелло иде. Чиста, саф күңелле. Үзенә хыянәтне күтәрә алмас иде. Без өйләнешкәч үк, Хәйдәр көнләшкәнлеген сиздерде, чөнки бергә укучы кыз минем хакта аңа төрле уйдырмалар сөйләгән. Соңыннан билгеле булганча, аның үзенең Хәйдәргә күзе

төшеп йөргән икән. Шул вакыт Хәйдәр көнләшеп мине бик нык куркытты. Аллаһы Тәгалә тарафыннан Хәйдәргә зур аң, зур акыл, зур талант бирелгән иде. Егерме биш ел бергә яшәү дәверендә көнләшүен башка белгертмәде. Гомумән, мин үзем юктан көнләшүне бер-береңне кимсетү галәмәте дип аңлыйм. Мин: «Син юктан көнләшә торган булсаң, бергә яши алмыйбыз», — дип әйтә идем. Ә ул: «Хыянәтне сизсәм, характерым бик кайнар, сак бул, Зөһрәм!» — ди иде. *(Көлә.)*

Төрле чаклар була — без артистлар бит. Мин гастрольгә чыгып китәм. Төркемдә күбесе ир-атлар. Хәйдәр дә гастрольдә. Икебезгә дә гашыйк булучылар, хат язучылар да була иде. Хәйдәрне бүгенгәчә яратып яшәүчеләр бар. Аның турындагы истәлекләр китабында Уфа филармониясеннән Гөлсем: «Мин аңа һаман гашыйк», — дип язган. Без бер-беребезгә ышанып яшәдек. Тормышыбызны авырлык белән башладык шул без. Мин: «Хәйдәр яши генә күрсен, җырлый гына алсын», — дип яшәдем. Аңа шартлар тудырырга тырыштым. Катлаулы операция кичергәннән соң, авыр әйбер күтәртмәдем, кибеткә дә йөртмәдем, зур акчалар да таләп итмәдем. Барысына да үзем чаптым. Сабыр булырга тырыштым. Тугрылык, саф күңеллелек, бер-беребезне ярату авырлыкларны җиңәргә көч бирә иде. Аллага шөкер, авызымны тутырып әйтә алам, туган халкыма күп хезмәт иттем. Иҗатым, җырым белән. Бөек талант иясе Хәйдәргә тормыш, эш шартлары тудыруым, аңа рухи терәк булуым белән дә хезмәтем зур дип саныйм. Аллаһы Тәгаләгә әле тагын да шулай хезмәт итәргә язсын.

**— Җырчы тормышы гел юлда уза. Ул чакта бит аның әле юллары да булмаган, асфальт төшләргә дә кермәгәндер.**

— Ике тапкыр авариягә очрадым. Беренчесендә, концерт куеп, төнлә Апастан кайтып киләбез. Автобуслар турында сүз дә юк. Концерт өзелмәсен дип, өч тәгәрмәчле фургон белән барган идек. Фургон авып, башым бик каты бәрелде. Икенчесендә Хәйдәр белән бергә, Сергач якларына баргач, юл

һәлакәтенә очрадык. «Вольво» машинасы ике тапкыр әйләнеп капланды. Мин арттагы утыргычка утырган идем. Җәрәхәтләнмәдем. Ул чакта да башым гына каты бәрелде. Ә менә Хәйдәргә бик авыр булды. Үлә дип котларым очып торды. Алла кушып, гомере бетмәгәч, тернәкләнеп тә киткән, ныклап аякка да баскан иде, ләкин нишлисең, гомере озын булмаган икән.

**— Зөһрә ханым, улыгыз Айрат турында сүз булды. Калган ике балагызны да искә төшерсәк...**

— Кызыбыз Айсылу прививкадан соң вафат булды. Никләр генә ясаттым икән дип, үз-үземне озак битәрләдем. Аннан соң Ходай Тәгаләнең тәкъдире икәненә төшендем. Җәннәт кошы булып китте бит балакаем. Айсылуга сигез ай гына иде. Бу безнең өчен аңлатып булмаслык югалту булды. Югалтуны онытырга, бушлыкны тутырырга теләп, мин тагын бер бәби алып кайтырга уйладым. Ике ай саклануда ятып, ир бала таптым. Дөресрәге, ярып алдылар. Операция ясамаган булсалар, үлгән булыр идем. Ир баланам туды, җиде айлык кына иде ул. Әмма гомере бөтенләй кыска булды. Сигез сәгать кенә яшәде дә вафат булды. Исмәгыйль исеме кушып җирләдек. Анысын да бик авыр кичердек. Тагын тәкъдир сездерде дип, мәңгелеккә күчкәндә каршы алырга җәннәт кошларыбыз бар дип кенә тынычландык. Минем үземә дә, ике ай урын өстендә ятканнан соң, кабат йөрергә өйрәнергә туры килде. Менә хәзер Хәйдәр мәңгелектә. Мин аларны бергәдер дип уйлыйм. Төшләргә дә нәни бала тоткан килеш бик матур итеп керә. Кызым, улым, Хәйдәрем рухына намаз укыган саен дога кылам, Аллага шөкер.

**— Айрат инде менә дигән кияү егете. Киленегезнең нинди сыйфатларга ия булуын телисез?**

— Улымны үзебезчә тәрбияләргә тырыштык. Әтисе кебек ул. Аллаһы Тәгалә иманыннан, тәүфыйгыннан аермасын. Ә киленгә килгәндә, мин аның тәрбияле, тәртипле, әхлаклы татар кызы булуын теләр идем.

**— Зөһрә апа, Сез үз җырыгызны озак эзләдегезме?**

— Мин Аллаһы Тәгаләдән сорый торган идем: «И Аллам, халыкны туйдырмый торган, минем үз йөземне генә чагылдырган җыр бирсәң иде», — дип. Күрәсең, Ходай ишетте. 1977 елда — миңа ул вакытта 26 яшь иде — Сара апа Садыйкова Гомәр Бәширов сүзләренә язылган «Җидегән чишмә» җырын тәкъдим итте. Җырның беренче премьерасы Пермь шәһәрендә булды. Концертның урта өлешендә «Җидегән чишмә»не җырладым, Сара апа үзе рояльдә уйнады. Җыр бетүгә, тамашачы торып басып бик озак кул чапты. Мин инде, әлбәттә, яшь җырчы буларак, алкышларны Сара апага хөрмәт дип кабул иттем. Аннан соң «Җидегән чишмә» минем визит карточкама әйләнде. Авторларга мин бик рәхмәтле. Урыннары оҗмахта булсын.

**— Татар халык җырларын башкарганда, нинди хисләр кичерәсез?**

— Халык көйләрен аккомпаниаторсыз гына башкарырга яратам. Шулай бервакыт «Уел»ны җырлыйм. Тәнәфестә сәхнә артына бер рус кешесе керде дә миннән: «Когда вы пели в акапеллу, я чувствовал себя крепко стоявшим на земле. Что это за песня?» — дип сорады. Шунда мин халкыбызның озын, борынгы көйләрен эчке горурлык хисе белән югары профессиональ дәрәҗәдә башкарсаң, башка милләт вәкилләренә дә сәнгатебезнең югарылыгын, чисталыгын, матурлыгын аңлатырга мөмкин икәнлеккә тагын бер кат инандым. Гомумән, җырчы кайда гына булса да үз милләте өчен җаваплылык тоеп хезмәт итәргә тиеш. Чөнки әйткән сүзең, фикер тирәнлегең, культура дәрәҗәң, әхлакый югарылыгың аша синә гына түгел, милләтеңә дә бәя бирелә. Җырчы шәхес булырга тиеш.

**— Сез — халык күңелендә үз урынын тапкан хөрмәтле җырчы. Татарстанның халык артисты гына түгел, бөтен татар халкының яраткан җырчысы. Утыз еллык иҗатыгызга хөкүмәтебез тарафыннан житәрлек игътибар бирелде дип уйлыйсызмы?**

— Мин эшләдем дә эшләдем. Исем артыннан йөрмәдем. Халкыма рәхмәтем зур. Ул мине онытмый. 1984 елда, 10 елдан артык җырлаганнан соң, Татарстанның халык артисты дигән исем алдым. Исем алулардан бәхетем юк минем. Хәер, әллә ни исем китми, Тукайның да премияләре булмаган. Шуңа күрә исемнәр артыннан кумадым. Халкым онытмый икән — миңа шул җитә.

**— Онытмыйлар Сезне, Зөһрә ханым. «Акчарлак» газетасының беренче саны чыгуга, Сезнең белән очраштыруны үтенеп, бик күп хатлар килде. Ниһаять, без очрашып, кара-каршы сөйләшеп утырабыз. Алар Сезне кайчан сәхнәдә күрербез икән дип сорыйлар.**

— Мин сәхнәдә 30 ел эшләдем. Бер генә гастролемне дә өзмәдем. Тик аварияләргә очрауларым эзсез үтмәгән, күрәсең. Авыру сәбәпле, күпмедер вакыт сәхнәдән китеп торырга туры килде. Бары да Ходай кулында. Иҗаттан туктаганым юк. Язмыш сынаулары этәргеч булгандырмы, соңгы вакытта күңелемдә көйләр туа. Аллаһы Тәгалә насыйп итсә, мин аларны сәхнәгә чыгып халкыма җиткерермен дип өметләнәм.

**— Без дә шуңа ышанабыз. Сәламәт булыгыз, Зөһрә ханым. Кабат сәхнәдә очрашканга кадәр.**

— Саубуллашырга ашыкма әле, сеңлем. Минем сиңа тамашачылардан безгә килгән хатларны күрсәтәсем килә.

**— Зөһрә апа, әйдәгез, бу турыда сөйләшүне башка вакытка калдырыйк.**

— Мин риза, Гөлназ сеңлем. Рәхмәт.

**— Хәзергә сау булыгыз.**

*«Акчарлак» газетасы*
*2001 ел, июнь*

# «Аның таланты чиксез океан кебек иде...»



*...Без төргәктәге хатларны берәм-берәм кычкырып укый башладык. «Хәйдәр, әйтегез әле, Сез кем — кешеме, әллә пәйгамбәрме?..»*

**— Зөһрә апа, ни өчен шулай сорадылар икән Хәйдәр абыйдан?**

— Бу хатлар Хәйдәргә гастрольләр вакытында, ул сәхнәдә җырлаган чагында киләләр иде. Күз алдыңа китереп кара, Гөлназ сеңлем, аның күңеле сабый баланыкы кебек чиста, саф, ә таланты чиксез океан кебек иде. Хәйдәр сәхнәгә чыгып баскач, аның мәһабәт, төз, озын буеннан, чибәр йөзеннән нур сибелә. Җырлаганда бөтенләй сөйләми. Хәтта җырларның да исемен үзе игълан итми. Бу аның сөйли белмәвеннән түгел. «Сәхнәдә һәркем үз эшен баш-

карырга тиеш» дигән фикердә тора иде ул. Тамашачының игътибарын җәлеп итү өчен артык хәрәкәтләр дә ясамый. Ул аларны фәкать үзенең таланты, моңы белән генә әсир итә иде. Микрофоннан шактый ерак басып яки аны бөтенләй алып куеп җырлый да җырлый...

Тамашачылар, дөньясын онытып, моң дәрьясында чайкала. Залда гына түгел, сәхнә артында да тын алмый җырчыны тыңлыйлар...

Шуңа күрә тамашачыдан мондый хатлар килү бер дә гаҗәп түгел. Хәйдәрне мәңгелеккә озатканда, аның белән саубуллашырга дип җыелган халык театр бинасына сыймады. Урамда халыкның күплегеннән хәтта трамвайлар туктады. Мондый хәл бары өч кешене — Тукайны, Сәйдәшне һәм Хәйдәрне соңгы юлга озатканда гына булган. Шуны әйтәсем килә: Хәйдәр ул бөтен күзәнәге, җаны-тәне белән халыкны яратты, халык өчен иҗат итте. Хәйдәрнең гомере озын булмады. Әмма шул кыска гына вакыт эчендә дә ул опера сәнгатендә, татар халык җырларын чын татар моңы белән сугару өлкәсендә, бик нечкә хис белән башкару таләп ителгән романслар җырлауда, композиторларның яңа җырларын дөньяга чыгаруда берничә зур җырчының гомеренә җитәрлек эшләр башкарды һәм үзеннән соң олы мирас калдырды. Аллаһыдан уй-фикереңне яшерә алмыйсың. Хәйдәрнең халыкка булган олы мәхәббәтен Аллаһы Тәгалә аның үзенә халыкның чиксез ихтирамы һәм хөрмәте итеп кире кайтарды. Хәйдәр вафат булгач, дөньяның татарлар яшәгән бик күп илләреннән, хәтта Кытайдан да шылтыратып кайгыбызны уртаклаштылар, сабырлык теләделәр. Рәхмәт барысына да.

**— Зөһрә апа, Хәйдәр абыйның соңгы көннәрен искә төшерсәк...**

— Син бу сорауны биргәч, күңелемдә бер хатирә яңарды. Студент чак. Консерваториядән җәяүләп кайтып киләбез. Опера театры бинасына җиткәч, Хәйдәр кинәт: «Их, шушы театр сәхнәсендә җырлаганда үлсәң иде», — дип куйды. Минем котым очты бу сүзләрдән. Ә ул миңа карап елмайды гына.

Һәм, дөрестән дә, Хәйдәр соңгы минутына кадәр эштә булды. Вердиның «Аида» операсыннан Радамес партиясен итальян телендә өйрәнеп беткән иде. Бик теләп, минем өчен язылган, минем тавышыма ята дип канатланып йөргән көннәре иде. Ә Радамес партиясе драматик тенорлар өчен иң авыр партияләрдән санала.

**— Мин әле Сезне ул көнне Татарстан радиосында күрдем бит...**

— Әйе, төшкә кадәр Хәйдәр театрда концертмейстер белән Радамес партиясен җырлап чыкты. Аннан, театр директоры Рәүфәл Сабирович янына кереп, шушы куелачак яңа опера хакында сөйләштеләр. Ә төштән соң икебез дә радиода баянчы Максат Гомәров белән репетиция ясадык, җырлар кабатладык.

Радиодан мин өйгә кайтып киттем, ә Хәйдәрнең тагын бер мероприятиедә катнашасы бар иде. Ул шунда китте. Ишекне ачып өйгә кердем генә, телефон шылтырый. «Зөһрә, Хәйдәрне ашыгыч ярдәм машинасы белән махсус клиникага алып килдек. Тиз килеп җит», — диләр. Мин нәрсә булганлыгын да аңлап бетермичә, әмма эчке бер шомлы курку белән чыгып чаптым. Безне ул клиникадан: «Кан юллары хирурглары 6 нчы номерлы шифаханәдә», — дип, шунда күчерделәр.

**— Ничек уйлыйсыз, вакытында тиешле ярдәм күрсәтелсә, Хәйдәр абыйның гомерен саклап калып булыр идеме?**

— Булыр иде дип уйлыйм. Үзең уйлап кара, хәтта аспирин да юк иде бит больницада. Дарулар исемлеге язылган кәгазь тотып, мин төнлә дежур даруханәгә чыгып чаптым. Хәйдәргә бик тиз ярдәм кирәклеген тойган күңелемә бу мәшәкатьләрнең агышы чамасыз озак тоелды. Аллаһы Тәгалә минем килүемне генә көттергән икән. Башын учларыма куеп, Хәйдәрем үз кулларымда мәңгелеккә күчте. Ни гаҗәп, бу минутларда Хәйдәремнең йөзендә дүрт сәгать буе кичергән газабының эзе дә юк, киресенчә, йөзе әз генә елмаюлы, тыныч, нурлы һәм чибәр иде. Хәйдәрнең үлеме минем өчен әйтеп, аңлатып

бетерә алмаслык зур тетрәнү булды. Мин табиблар ярдәм итәрләр дип өметләндем. Шулай да күңелдә ниндидер шом, курку бар иде. Минем Хәйдәр өчен курыккан вакытларым күп булды, монысы башкача иде. Аллаһы Тәгалә сиздергәндер, күрәсең. Харис хәзрәткә рәхмәт: «Зөһрә, Ходай Тәгалә Хәйдәрне бу җирдә калдырырга теләсә, ул аңа ярдәм күрсәтә торган сәбәбен дә бирер иде», — диде. Нишлисең, шушы җирдә тууыбыз — үзе тәкъдирдер. Бу хакта мин озак уйландым. Ярдәм итә алмадым дип ачыну, әрнү утында озак яндым. Хәйдәрне югалту хәсрәте белән килешә алмадым. Сабырлыкны мыскаллап җыйдым.

**— Яраларыгызга кагылдым, кичерегез... Без, бәлки, хәзер яшьлек елларыгызны искә төшерербез?!**

— Хәйдәр үсмер чагыннан ук авыр үлчәмдә штанга, гер күтәрү буенча Түбән Новгород өлкәсендә танылган спортчы була. Аннан армия сафлары... Германиядә танкист булып хезмәт итә. Армиядән соң Казанга консерваториягә укырга керә. Озын буйлы, чибәр, таза, төз гәүдәле егеткә күп кызларның күзе төшә...

**— Зөһрә апа, ә кыз сорарга Хәйдәр абый үзе кайттымы?**

— Иң элек, рөхсәт итсәгез, кызыгызның кулын сорарга кайтыр идем, дип, әти-әниләремә хат язды. Аннары җәйнең матур бер көнендә үзе кайтты. Әти-әниемнең аңа кадәр Хәйдәрне бер тапкыр күргәннәре бар иде. Студентлар төркеме белән Сарман районына гастрольгә кайткач, безгә кергән идек. Шул чагында Хәйдәр әтинең 2 потлы герен бер кулында күп мәртәбәләр чөеп-чөеп уйнаган иде. Әтием исә Хәйдәрнең көч-куәтенә сокланып карап торды.

**— Әти-әниегез каршы килмәде инде алайса?**

— Юк. Яшем җиткән, Хәйдәр акыллы, тыйнак, эчми-тартмый. Шул җәйдә никах укыттык.

**— Туганнарыгызга мөнәсәбәте ничек булды?**

— Бик яхшы. Апаларымны ихтирам итә иде. Хәйдәрнең «әти, әни» дип эндәшүе үз уллары булмаган

әти-әнием йөрәгенә сары май булып ятты, алар кияүләрен үз уллары кебек яраттылар.

**— Сезнең ир белән хатын икәнлегегезне тамашачылар озак вакыт белмәгәннәр дә.**

— Халык мине Зөһрә Сәхәбиева дип белә, тамашачы Сәхәбиева фамилиясенә күнеккән иде. Аннан соң бит әтинең фамилиясен дәвам итүче улы да юк. Шуңа минем әти фамилиясен саклап каласым килде.

Язылышырга барганда, Хәйдәргә әйттем: «Мин Сәхәбиева булып калам, син каршы түгелме?» — дидем. «Юк-юк», — диде Хәйдәр. Язылышканда исә әйтте бу: «Әйдә Бигичева булып языл», — диде. Аңа каршы килә алмадым. Әмма язылышу турындагы таныклыкта Бигичева булсам да, сәхнәдә һаман Сәхәбиева булып калдым. Шуңа күрә фамилияләребез дә бер булмагач, игътибар итмәгәннәрдер инде. Аннан соң без ир белән хатын дип реклама да ясамадык. Үзебез турында интервьюлар да бирмәдек.

**— Хәйдәр абый өйдә, тормышта нинди кеше иде?**

— Ул тормышта да, иҗатта да ирек яратты. Аны ирек биреп һәм ышаныш кына кулда тотып була иде. Иҗатта да, тормышта да таләпчән кеше булды. Кырыс та була белә иде. Шул ук вакытта минем иҗат кешесе икәнлегемне дә бик яхшы аңлады. «Нигә бу әйбер урынында тормый?», «Ник тәлинкәләр юылмаган?» дип, беркайчан бәйләнмәде. Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала диярдәй чакларыбыз күп була торган иде.

**— Хәйдәр абый туып үскән Нижгар якларында дингә ихтирам, хөрмәт атеизм елларында да югалмаган...**

— Әйе, Хәйдәр дә дингә ихтирамлы иде. Ул Аллага инанды, аны бар дип, бер дип белде. Соңгы вакытта намазга да баскан иде. Әмма фанат түгел иде ул. Аллага ышанган, күңелендә иманы булган һәртөрле башка дин, башка милләт кешеләрен дә хөрмәт итә белә иде.

**— Төшкә еш керәме Хәйдәр абый?**

— Ике ел буе көн дә керде. Төшемдә киңәшләр бирә ул миңа. Үзе һәрвакыт матур кыяфәттә, гел каядыр биектә, югарыда басып тора. Әйтәләр бит, алар терек, без үлек, дип. Әле менә беркөнне күрәм, минем янәшәмдә бара. Үзе бик матур. Киемнәре дә яхшы, затлы, ә башмаклары тишек. «Нигә шулай икән?» — дип борчылган идем, зиратта буласы хәлләргә икән.

**— Әйе, бөек җырчыбыз Хәйдәр Бигичевның кабере өстендә вәхшилек кылынганын — җырчы истәлегенә куелган таштан бронза барельефны һәм исем-фамилиясен куптарып алып киткәннәрен ишетеп, күпләр борчылды.**

— Аның туган көне 16 июньдә. Җомга көнне улым, дустыбыз һәм кардәшебез белән дога кылырга Хәйдәрем янына киттек. Барсак, шушы хәл. Аңлый алмый торам. Истәлек ташы шәрә калган. Шул вакытта яныбыздан зиратта эшләүчеләр узып баралар иде, алардан сорадык. «Бүген төнлә бурлар йөргән, күп кенә каберләрдән төсле металл урлаганнар», — диделәр. Нишлисең бит, хәзер инде опера театры дирекциясе белән берлектә башкасын куярга йөрибез.

**— Зөһрә ханым, «Акчарлак» газетасының 6 нчы санында анонс чыккач, шылтыратучылар булды. Алар: «Сез Хәйдәрне авыру кеше итеп күрсәткәнсез, ә без аны көчле кеше итеп беләбез», — дип, ризасызлыкларын белдерделәр.**

— Дөресен әйтим, бу анонс миңа да ошамады. Тормышының авыр көннәрен искә төшерергә яратмыйм. Үзең беләсең, бу әңгәмәгә дә бик авырлык белән күндем. Ярар, бу турыда сүз чыккан икән инде, ул авыр вакытларны искә төшереп китми булмас. Чыннан да, студент елларында Хәйдәр бик нык авырып алды. Табиблар аңарда гипертоник кризислар булуының нәрсәдән икәнлеген озак белә алмадылар. Хәйдәр кан басымы бик югары булган хәлдә дә спектакльләрдә җырлый иде. Мин, медик булarak, үзен нинди куркыныч астына куюын бик яхшы аңлый идем, шуңа күрә ашыгыч ярдәм кирәк була калса дип, сәхнә артында гел әзер тора идем.

Сәхнәгә, халыкка гашыйк Хәйдәрне җырлатмыйча тотып торып буламы соң?! Аңа бит студент чагында ук төп рольләр җырлауны ышанып тапшырдылар. Бу бик сирәк була торган хәл. Х.Вәлиуллинның «Самат» операсыннан Саматны җырлады. Н.Җиһановның «Җәлил» операсыннан Җәлилне. Шупшындый ышанычны акламый калу Хәйдәрнең табигатенә туры килми. Нинди генә авыр хәлендә дә ул бер спектакльне дә өзмәде. Бу инде Хәйдәрнең нинди зур рухи һәм физик көчкә ия икәнлеген күрсәтә. Консерваторияне тәмамлап, дәүләт имтиханнары җырын җырлаганда, Хәйдәр башка җырчылардан күпкә өстенлеге белән аерылып торды. Чыгарылыш имтиханнары комиссиясе рәисе, Мәскәүдән килгән профессор Шпиллер: «Бу егетне һичшиксез Италиягә стажировкага җибәрергә кирәк», — диде.

Әмма ул вакыттагы җитәкчеләр талантның һәм сәнгатьнең киләчәгенә игътибарсыз калдылар, Хәйдәрне Италиягә җибәрү мөмкинлекләрен эзләмәделәр. Кечкенә генә Якутия исә шул елны үзләренең бер егетен Италиягә җибәрде...

Дөньякүләм авыр партияләрне — Вердиның «Отелло»сында Отелло, «Аида»сында Радамес, Бизеның «Кармен»ында Хозе, Чайковскийның «Пики дама»сында Герман һәм башкаларны җырлауга ул күкрәк көче белән ярып килде, үзенең йокысыз төннәре, уйланулары, эзләнүләре, янулары аша җырлау мәктәбен тапты. Ә Италиягә барып ике ел укып кайтса, аңа күпкә җиңелрәк булыр иде, чөнки Италия тавыш белән идарә итүгә өйрәтү буенча иң югары мәктәп санала. Матбугатта чыгуымнан файдаланып, үземне күптән борчыган бер мәсьәләгә тукталмыйча кала алмыйм. Газета-журнал битләрендә, кайбер кешеләрнең аерым чыгышларында, минем белән тәгаен дөреслеген ачыкламыйча, Хәйдәр турында дөреслеккә туры килмәгән фикерләр әйтү, уйдырмалар сөйләү очраклары булды. Бигрәк тә Хәйдәр әйтмәгән сүзләрне «әйтте» дип сөйләүләр һәм ул егерме елдан артык эшләгән опера театрын Хәйдәргә каршы куярга тырышулар мине бик борчый. Театр коллективы бик зур. Бөтен коллектив, анда-

гы барлык цехлар Хәйдәргә искиткеч зур хөрмәт белән карыйлар, аны бик яраталар, спектакльләрдә җырлавын көтеп алалар иде. Хәйдәр белән театр арасын бозарга тырышучы кешеләр аның саф күңелле, ышанучан, ярдәмчел кеше икәнлегеннән файдаланырга тырыштылар. Тагын ассызыклап әйтеп үтәм: Хәйдәр үзенең яраткан театрына кирәк булмады дигән сүз чынбарлыкка туры килми. Талантларга каршы талантлары җитенкерәмәүчеләр ачкан көрәш аяусыз, астыртын һәм пычрак була.

Хәйдәрнең рухын рәнҗеттермәү, тынычлыгын саклау — минем вазифам. Шуңа күрә аның хезмәтләре һәм шәхесе хакында ниндидер фикер әйткәндә, минем белән киңәшләшүләрен үтенәм. Хәйдәр белән безнең карашларыбыз, уй-фикерләребез, янукөюләребез бер иде.

*«Акчарлак» газетасы*
*2001 ел, июль*

# «Мин — реалист кеше...»



*Салават Фәтхетдинов татар эстрадасына ак атка атланып килеп керде дә аңа яңа сулыш өрде. Унөч ел эстрада сәхнәсендә беренчелекне тотып баруы сокланырлык та, кызыгырлык та, көнләшерлек тә. Шушы вакыт эчендә ул һәр татар кешесенең күңелендә үз урынын тапты. Ул тәнкыйтькә дә күп эләгә, әмма яратучылар күбрәк. Башкаларга охшамаган, үзен Салават итеп таныткан, тамашачыны гашыйк иткән җырчының, бәлки, берәр сере бардыр? Үзеннән сорыйк әле.*

— Мин нәрсә беләм, шуны эшлим. Сәхнәгә чыгыш бер төрле артистланыш, сәхнә артында икенче төрле кыланмыйм. Тормышта да шулай мин, гаиләдә дә, спортта да, сәнгатьтә дә. Ничек бар, шулай кабул итсеннәр. Мин — реалист кеше. Хыялланырга да яратам. Ул хыялларның барысы да тормышка гына ашып бетми.

**— Табышмак булып каласың киләме соң?**

— Ансыз мөмкин дә түгел. Минем үзем генә белә торган табышмакларым бик күп. Мин аларны ачарга җыенмыйм да.

**— Серле Салават булып калырга телисең инде.**

— Ике балдакның серен халык әле дә аңламый. Мин дә әйтмим. *(Көлә.)*

**— Халкыбызның хөрмәтле шагыйре Роберт Миңнуллин синең турыда сөйләгәндә: «Салават ул — мөстәкыйльлек, ә мөстәкыйльлекне алып килүдә Салаватның өлеше зур», — дигән иде.**

— Сүзеңне бүлеп әйтәм, Гөлназ, мин Башкортстаннан Татарстанга күчеп килгән вакытта — үзебезнең авыл турында сөйлим — Сәгыйт исемен Сашага, Мәхмүт исемен Мишага үзгәртүчеләр күп иде. Мин шакката идем. Самара татарлары миңа сәхнәдә алтын ай бүләк иттеләр. «Алтын айны муеныңнан салма, шулай йөр, син — безнең милләтнең горурлыгы», — диделәр. Айны тагып Чаллыга килгәч, рус егетләре: «А ну-ка, сними», — дип кисәтәләр иде. «Синең тәреңдә эшем юк, минекенә тимә», — дия идем. Шундый куркыныч чорда тагып йөрдем, бер елдан соң бик күп татар егетләренең муенында алтын ай иде инде. Мин монда үрнәк күрсәттем дия алам.

**— Сәясәт турында сүз башлаганбыз икән, «Мин яратам сине, Татарстан» җырына да тукталыйк.**

— Бер очрашуда Президентыбыз Минтимер Шәймиев белән сөйләшеп утырабыз. Ул: «Син нишләптер «Мин яратам сине, Татарстан» җырын җырламый башладың», — диде. Шуннан без аның аранжировкасын үзгәрттек һәм кабат репертуарга алдык.

Хәзер күп очрашулар, кичәләр, сәяси җыеннар шул җыр белән тәмамлана. Сәяси файдам бу яктан да аз гына булса да тигәндер дип исәплим.

**— Салават, мин синең Татарстанны яратканыңны беләм. Ул синең һәр чыгышыңда, һәр әңгәмәңдә чагыла. Шулай да Татарстан синең өчен нәрсә ул?**

— Чит җирләрдә гастрольдә вакытта Татарстан турында сүз чыкса, мин дулкынлана башлыйм. Бервакыт без футболкаларга инглиз телендә «Татарстан — минем туган йортым» дип яздык та Португалиягә дөнья чемпионатына киеп бардык.

Туган җир бик кадерле. 28 ел гомеремне Башкортстанда уздырдым. Татарстанда нибары 13 ел яшим. Шулай да минем туган йортым — Татарстан. Мин бу илне беркайчан берни белән дә алмаштырмыйм. Балаларым да биредә туды. Алар Башкортстанны «кунакка кайту» дип кенә беләләр.

Безнең башка илләргә дә үрнәк булырлык сәясәтебез, икътисадыбыз, халкыбыз, динебез, җырыбыз-моңыбыз бар. Бу халыкны бетерергә мөмкин түгел. Аллага шөкер, безнең киләчәгебез өметле.

**— Илнең данын яклауда һәм саклауда спортчыларның да роле зур, миңа калса.**

— Әлбәттә. Әйтик, «Ак барс» чемпион булды. Моңа Россиядә яшәүче барлык татар сөенде. Берберсен котладылар, мактанштылар. Үзләре уйнап чыкканнар диярсең. 20 кеше Татарстанның данын күтәрде. Хоккей, теннис, автоузышлар, баскетбол, футбол буенча да Татарстан алда бара, Аллага шөкер. Без бик күп яктан үрнәк булып торабыз. Бездән өйрәнсеннәр, көнләшсеннәр, әзрәк кенә курыксыннар, анысы да кирәк. *(Көлә.)*

**— Салават, син җырлыйсың, спорт белән шөгыльләнәсең: ярышасың, узышасың, уздырасың. Соңгы вакытта туризм белән дә мавыгасың.**

— Туризм гына түгел, башымда әллә нинди уйларым, хыялларым бар. Дөньяны төрле яклап таныйсым килә. Гомер буе җырлап кына да булмас. Халык бүген сине ярата, ә иртәгә синнән талантлырак,

синнән акыллырак, синнән яшьрәк җырчыны тыңлый башлаячак. Моның өчен тамашачыны гаепләп булмый. Мин ярты залга җырлап яшәргә җыенмыйм.

**— Бүгенге сөйләшүебез Татарстанның халык артисты Салават Фәтхетдиновның «Яшьлегем — кырыкта» дигән концерт программасы башланыр алдыннан бара. Шулай булгач, концерт турында берничә сүз әйтмәсәк, әңгәмәбез тулы булмас кебек. 13 нче августта башлана, 13 нче сезон, 13 нче концерт. Нинди могез чыгарырга җыена икән Салават?**

— Юмор белән мавыкмыйбыз. Җырлар күп булачак. Концертта Үзбәкстаннан кайткан Мәликә җырлаячак. Күп сөйләмим. Минем иҗатымны яратучы тамашачым килсен, күрсен, бәя бирсен. 13 санына килсәк, бу — минем өчен бәхетле сан. Ә автоузышларда менә бу санны беркем дә алмаска тырыша...

**— Инде, Салават, «Заман» газетасын укучыларга теләкләреңне җиткерик.**

— Минем бөтен кешегә дә әйтә торган бер сүзне җиткерәсем килә. Һәркем сау-сәламәт булсын. Авырып китсәң, дөньяның кирәге калмый. Шуңа күрә барыбыз да исән-сау булыйк.

**— Әңгәмәң, теләкләрең өчен зур рәхмәт сиңа. Киләсе очрашуларга кадәр.**

*«Заман» газетасы*
*2001 ел, август*

# «Җыр белән вәгазьне бутамыйк...»



*Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин — җырлары белән халкыбыз күңелендә үз урынын алган шагыйрь. Аның ике йөздән артык җырының берничәсен искә төшерү дә җитә: «Әнкәмнең догалары», «Соңдыр шул, соңдыр», «Каеннар арасында», «Миңа йөрәк бүген кирәк» һ.б. Барысын да санап китсәң, шактый озын исемлек килеп чыгар иде. Бүгенге татар эстрадасының хәле, татар җыр сәнгате, шагыйрьнең иҗаты турында кызыксынып, мин Роберт Миңнуллинга мөрәҗәгать иттем.*

**— Роберт абый! Сезне җырчы шагыйрь итеп таныткан җырыгыз кайсысы булды?**

— Шагыйрьгә генә түгел, композиторга, җырчыга да җыр тарихына кереп калырга, популярлашырга бер җыр җитә. Минем өчен ул җыр — иң беренче җыр — Сара апа Садыйкова белән бергәләп иҗат иткән «Әнкәй» җыры булды. Ул җыр әле дә искермәгән дип уйлыйм. Аны мөхтәрәм җырчылар башкара. Ә иң мөһиме — халык җырлый. Аңа чаклы да әнкәйләргә багышланган җырлар шактый иде. Мәсәлән, «Сәлам сиңа, әнием», «Әниемнең җылы кочагы», «Әнием» дигән казак җыры һ.б. Алар да әйбәтләр. Ләкин минем җыр әнкәйләр темасын башкачарак күз алдына китерде. Аның шигыре дә эчке кичерешләр белән бәйләнгән, сүзләре дә гади.

**— Соңгы вакытта әлеге теманы яктырткан җырлар күбәеп китте. «Әниемнең туган көне» (Сәгыйт Гыйбашев җырлый), «Картайма әле, әнкәй» (Рөстәм Закиров җырлый)... Шагыйрь буларак алар турында ни уйлыйсыз?**

— Алар — икенчел җырлар. Мәсәлән, Рөстәм Закиров җырлый торган җырны алыйк. Разил Вәлиев белән Рәшит Абдуллин иҗат иткән «Нигә, әнкәй, нигә картаясың?» дигән җыр бар. Рөстәмнең җыры исә шуны кабатлау, һәм ул бу җырның бәясен киметә. Андый мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Минем «Гомерләр үтә икән ул» дигән җырымнан соң унбишләп җыр туды инде. Гел гомер турында язалар. Менә шундый әйберләр белән сак булырга кирәк. Тагын бер нәрсә. Без хәзер, бик тырышып, барыбыз да көнкүреш темасын яктыртабыз. Кайбер җырлар мәкаль-әйтемнәрдән генә тора сыман. Кем иренми, бар да «Ходай», «Алла» сүзен кулланa. Минем «Әнкәмнең догалары» җыры «дога» сүзе кергән беренче җыр булды. Ул сүз бу очракта киң мәгънәсендә әйтелә. Ә хәзер җырга, шигырьгә Коръәндәге бөтен сүзне кертеп бетерергә тырышалар. Мин ул җырчыларны «сәхнә муллалары» дип атыйм. Һәрнәрсәнең үз урыны. Вәгазь уку өчен мулла һәм мәчетләр бар. Ә сәхнәнең үз роле. Җыр белән вәгазьне бутамыйк. Уйлансаң, уйланырлык әйберләр

җитәрлек. Туган-тумачалык турында җырлыйлар. Ул ризыкларның ниндиләре турында гына юк җырлар. Кода-кодагыйлар хакында гына язасы калды. Бу — җыр сәнгатендә югары шигърияттнең бетүе дигән сүз. Мин Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Наҗар ага Нәҗми шигырьләренә язылган җырларны сагынам.

**— Сезнең җырлар тәнкыйтькә эләгәләрме?**

— Эләгәләр. Кайбер очракларда шигырь язылганда ук төгәлсезлек киткәнен үзем дә тоям. Бәлки, сизелмәс дип уйлыйм. Ләкин безнең халык сизгер ул. Аны алдап булмый. Кайбер очракта җырчылар үзләре дә хаталар җибәрә. Мәсәлән, «Әнкәйнең догалары» дип җырлыйлар. Ә бит төбенә төшеп уйласаң, бу сүзләрнең аермасы шактый. «Әнкәм» дип эндәшү ул бик якынлыкны аңлата. Хәзер инде ул җырны ике төрле җырлыйлар. «Яратыгыз» дигән җырда Венера Ганиева сүзнең бары бер хәрефен алмаштырган. Шигырьдә ул «Андыйларга яну янамый» диелгән. Ә Венера «ярамый» дип җырлый. Җырның икенче юлында да шул ук сүз кабатлана. Менә шуннан соң килеп туа инде тәнкыйть. Янәсе, мин рифма өчен башка сүз таба алмаганмын.

**— Сезнең «Каеннар арасында» дигән җырыгыз турында да күп сөйләделәр шикелле.**

— Нык бәйләнделәр инде аңа. Югыйсә анда менә дигән матур шигъри образ. Аннан ул образны мин үзем уйлап тапмадым. Ул Есенин шигъриятендә дә нык чагыла. Кем ничек уйлый һәм кабул итә бит?! «Әнкәмнең догалары»н тәнкыйтьләүчеләр дә күп булды. «Ташлама, әнкәй, ташлама» дигән сүзләрне «Калдырма, әнкәй, калдырма» дип җырларга куштылар. Тагын шунысы кызык: минем җырдан соң «Ташлама мине, ташлама» дигән 5–6 җыр барлыкка килде.

**— Заказ буенча шигырь язганыгыз бармы?**

— Яшермим, бар. Мин бит аларны шагыйрь буларак язам. Салават җырлый торган «Ак бүре», Рәсим Низамов башкара торган «Теләче» җырлары шундыйлар.

**— Роберт абый, Сезнең инде, әйткәнебезчә, ике йөздән артык җырыгыз бар. Кыска дулкын-**

**лы радиоларда алар еш яңгырый. Ләкин беркайчан да авторлары әйтелми. Моңа йөрәгегез әрнидер.**

— Әйе, бу бик күңелгә тия торган нәрсә. Минем шигыремне көйгә салганнар икән, аны кемдер җырлый икән, әлбәттә, композиторы да, шагыйре дә әйтелергә тиеш. Кеше хезмәтен хөрмәт итүчеләр моны шулай эшлиләр дә инде. Аннан закон буенча да каралган бит. Авторлык хокукы бар. Кыска дулкыннарда тапшыру алып баручы егет-кызлар күп очракта җыр авторын белмиләр дә. Монысы инде җырчы гаебе. Чөнки алар җырларын алып килгәндә, кассеталар чыгарганда, шагыйрь, композиторларны бөтенләй күрсәтмиләр яки бутап бетерәләр. Тагын шуны да әйтәсем килә. Кызганычка каршы, җырчыларның күбесе үзләре башкарган җырларның сүзләрен ахыргача аңламыйлар шикелле. Мин моны наданлык димим, шулай да... Алар — җырларын үзләре чүплеккә чыгарып атучылар. Бер сезон гына җырлыйлар да менә дигән җырларны «оныталар». Бу бернинди кысаларга да сыймый. Акча эшләү өчен генә җыр арты җыр алыштыру акыллы күренеш түгел.

**— Менә, сөйләшә торгач, сәхнә, татар эстрадасына да якынлаштык. Бүгенге сәхнә, тамашачы нинди ул?**

— Популяр җырчыларның һәрберсенең үз урыны бар. Алар үзара ярышалар, тамашачының күңелен яулап алырга тырышалар. Болар — беренчел дәрәҗәдәге җырчылар. Бар шундыйлар, аңа карыйсың да шаккатасың, ни кыяфәте, ни тавышы юк. Гомумән, аңа сәхнәгә чыгып басарга да оят булырга тиеш. Әмма бүгенге эстрада ул — шоу-бизнес һәм ул, кызганычка каршы, тавыштан гына тормый. Ләкин ничек кенә булмасын, талантлы җырчылар, иләктән иләнеп, барыбер сәхнәдә кала алалар. Җырчылар күп булган кебек, хәзер концертлар да күп бит. Минем күзәтеп караганым бар, ул концертларга гел бер үк тамашачы йөри. Әмма мин халыкны эстрадага гына мөкиббән киткән димәс идем. Аллага шөкер, тамашачы опера театрына да, Камал театрына да күп йөри.

**— FM дулкынында яңгырый торган хит-парадларга ничек карыйсыз?**

— Мин аларны аңлап бетермим. Каян белә алар нәкъ менә шул җырның иң популяр җыр икәнлеген? Фәлән җыр фәлән тапкыр җырланды, диләр. Ничә тапкыр куялар, шуның хәтле яңгырый инде ул. Җыр шуңа карап популярлашадыр да. Тагын шуны онытмаска кирәк. Җырны бер ай эчендә көненә 5–6 тапкыр уйнатып юкка чыгарырга да мөмкин. Икенче айда инде аны башта бик яраткан булсаң да тыңлыйсы килми.

**— Сез бүгенге көндә иң популяр дип кайсы җырыгызны саныйсыз?**

— Популярлык — кызык нәрсә ул. «Буран дулый»ны менә кыска дулкында Казан тирәсендә генә тыңлыйлар. Авыл җирендә яшәүчеләр аны белми дә. «Әнкәмнең догалары», «Соңдыр шул, соңдыр» — болар ныклы җырлар. Оскар Усманов белән бергәләп иҗат иткән «Мәхәббәт шушыдыр», «Буран дулый», «Чабам гомер атында» кебек җырлар да еш яңгырый, миңа калса. Оскарның җырлары татарча да, шул ук вакытта аларда гомумэстрада аһәңнәре дә бар.

**— Сездән җыр текстларын махсус сорап алган композиторлар бармы?**

— Әйе, без Илгиз Закиров, Резеда Ахиярова белән иҗади дуслыкта яшибез. Соңгы вакытта Оскар белән дә яхшы элемтәдә.

**— Ә җырчылар ничек, алар да җырларны сорап алалармы?**

— Машинада барганда, кайчак тыңлап барасың — җыр яңгырый. Сүзләре таныш кебек, берзаманны шоферга әйтәм: «Әхәт, тавышын ач әле, минем җыр түгелме икән ул?» — дим. «Әле сез ишетмәдегезмени? Әллә ничә көннән бирле җырлаталар бит инде ул җырны», — ди Әхәт. Күп очракта шулай була шул. Дөрес, бергәләп иҗат иткән очраклар да шактый. Элек Римма Ибраһимова, Зөһрә Сәхәбиева, Хәйдәр Бигичев белән берлектә күп эшләдек. Хәйдәр соңгы тапкыр минем иҗат кичәмдә чыгыш ясады. Хәзер Салават, Айдар Галимов белән

тыгыз элемтәдә торабыз. Җырны студиядә яздырганда да, композитор белән шагыйрь катнашырга тиештер. Шулай эшләмәгәнгә күрә сүзләрдә хата китә, һәм җыр текстының мәгънәсе югала. Көй шигырьнең мәгънәсен тыңлаучы күңеленә җиткерү өчен туа.

**— Роберт абый, минем бу җырымны башка җырчы башкарса, үтемлерәк булыр иде дигән чакларыгыз бармы?**

— Бар. Бик күп җырларым турында шулай уйлыйм, ниндиләре икәнен әйтмим әлегә. Киләчәктә очрашып сөйләшергә дә сүз калсын.

**— Мин каршы түгел. Димәк, киләсе очрашуга кадәр.**

*«Акчарлак» газетасы*
*2001 ел, сентябрь*



*— М.Горький исемендәге Үзәк ял паркы тукталышында ике ханымның: «Фердинанд Сәләхов Петербургта суга батып үлгән икән», — дип сөйләшеп торганнарын ишеткәч, әллә нишләп киткән идем. Менә карап торам, син, Аллага шөкер, исән-сау, күңелең дә күтәренке, шулай да утсыз төтен чыкмый бит ул.*

— Әйе, мин «Циалковский» теплоходында Петербургка бардым. Ул йөзгеч ике пар казаны белән эшләргә тиеш булса да, берсе бик күп еллардан бирле «ял итә» икән, ә икенчесенең автомат күчергеч-

ләре эшләмәгән. Без, бернәрсә белмичә, чыра белән кабызып яндыра торган йөзгечтә ял итеп йөргәнбез, һәм шушы теплоходыбыз Петербургта 3 көн ял итеп туктап торганнан соң, башта дөмбердәп шартлады, аннан соң янды, соңыннан батты. Кеше белән, гадәттә, афәтнең бары берсе генә була бит, ә монда барысы да берьюлы булды — шартладык та, яндык та, баттык та. Кызганычка каршы, 20 яшьлек берәүнең тын юллары зарарланды, ул нык кына пеште дә һәм тагын теплоход табибы зыян күрде. Калганнарыбыз ничек кирәк алай яр буена чыгып аудык. Ял итәргә барганда, күп кеше үзе белән видеокамералар, фотоаппаратлар, яхшы киемнәр алып чыга бит. Беренче палубадагыларның әйберләре дә су төбенә китте. Менә шулай бернисез иртәнге дүрттә Казанга кайтып төштек. Каршы алырга килүчеләр күп иде. «Судан коры чыгып», исән-имин кайтуыбызга куанышып, өйләргә таралыштык. Менә шуннан бирле яшәүнең тәмен тоеп, рәхәтләнеп яшибез.

**— Бу маҗара Фердинанд Сәләховка күпмегә төште инде?**

— Юлламаның ярты бәясе 17 мең 800 сум тора. Шуңа минем су астында калган 60—65 меңлек әйберләремне дә кушсак... Профессиональ фонограммалар, концерт костюмнары, кәрәзле телефон һәм башка вак-төяк. Шактый гына зур сумма килеп чыга шул. Әле бу бер минеке генә. Ә ял итүчеләр 160 кешедән артык иде.

**— Югалткан әйберләр өчен компенсация түләгәннәрдер бит?**

— Моңысы — әкият иленнән килгән сорау.

**— Фонограмма, концерт костюмнарыңны югалткач, кулыңнан икмәгеңне тартып алган кебек булгандыр. Инде нишләрсең? Бу көннәрдә күңелеңнән нинди җыр көйлисең?**

— Мин хәзер сәхнәдән гел «Эскадрон»ны гына җырлап йөрермен инде. Анда бит «Яуга китеп исән кайталмасам, Урал тавы искә алсын» дигән юллар бар. Бездә «Дөнья яхшы кешесез булмый ул» дигән әйтем бар. Иҗатта да миңа иңнәрен куеп, кул биреп торучы дусларым бар. Шуларда бөтен ышаныч.

Бу ялга мине дусларым көчләп озатканнар иде. Егерме ел сәхнәдә эшләдем, бер тапкыр да ял иткәнем булмады. Хәзер калган егермесен дә ял итмичә эшли алам, Алла боерса. Сәхнәдә бит су да юк, ут та юк. Бу афәттән соң без Ярославльгә кадәр өч көн «Родина» теплоходында кайттык. Мин анда халыкны тынычландырыр өчен рәттән ике көн концерт бирдем. Кемдер кушылып җырлады, кемдер рәхәтләнеп тыңлады. Шул афәттән соң теплоходта җырлый алганмын икән, калганы булыр, Алла боерса. Көзен Казаныбызда концертлар эшләргә җыенам.

— **Уңышлар сиңа.**

*«Акчарлак» газетасы*
*2001 ел, сентябрь*

# Бәхетнең чиге юк



*Көтмәгәндә-уйламаганда Сочи каласында Хәния Фәрхи гаиләсе белән очраштык. Алар да ике кызлары белән ял итәргә килгәннәр. Чит-ят җирләрдә уртак ял аеруча җанланып китте: бергәләп табигать кочагына чыгып, учак ягып, уха пешердек, көньяк кояшында кызындык, диңгездә коендык. Әйдәп баручы җырчыларыбызның берсе, Татарстанның халык артисты Хәния Фәрхи — кызыклы шәхес, күңелле әңгәмәдәш.*

**— Ялыгызны сентябрьгә калдыргансыз икән...**

— Быел, көньякка киткәнче, ун көнгә туган ягыма кайттым. Элегрәк бөтен туганнарымны барлап, иркенләп йөри алганым булмады. Аннары Биектауда Габделхәйнең туган авылында ике атна яшәдек. Менә хәзер — биредә. Быелгы ялның бер зур вакыйгасы бар: Сочиның легендар дуслык бакчасы-

на — 164 илдән килгән милләт вәкилләре эз калдырган изге җиргә — «Хәния Фәрхи» агачын утырттым. Дөньялар тыныч, илләр имин, гаиләләр бәхетле яшәсеннәр диеп теләк теләп, күңелемне бушатып кайттым.

**— Иҗатыгыз турында сөйләшүгә күчкәнче, хатын-кызларча, кием турында гәпләшеп алыйк әле. Гадәттә, җырчы, яңа программа белән сәхнәгә чыкканда, тамашачыны өр-яңа күлмәк киеп тә шаккатырырга ярата. Еллар буена андый кием шактый җыеладыр. Чит ил артистларының концерт костюмнарын аукционнарда сатканнарын ишеткәнем бар. Сездә, Хәния, андый теләк тумадымы?**

— Күлмәкләремне бик кадерләп саклыйм. Аларда минем тәнем, җаным җылысы. Күлмәкләремне бик кыйммәт бәягә сораучылар булды. Сатмадым. Музейларга сораучылар да бар, аларына әле җавап бирмәдем. Бәлки, шунда үз урыннарын табарлар. Бәлки, бенефис уздырганда, онытыла төшкән җырларымны шул чактагы киемнәрне киеп җырлармын.

**— Унике ел рәттән төрле төбәкләрдәге сәхнәләрдә җырлыйсыз. Шулай да Казан тамашачысы каршында чыгыш ясау каушатмыймы?**

— Бик нык каушата. Ул — имтихан дигән сүз. Казан сәхнәсендә «яхшы» дип бәялиләр икән, теләсә кая курыкмыйча чыгыш китәргә ярый. «Концерт йомшак булды» дисәләр, чәчең белән җир себерсәң дә, соң инде.

**— Ничек уйлыйсыз, татар артистына тән сакчысы кирәкме?**

— **Хәния.** Бик кирәк! Минем алар дүрт егет. Һәрберсенең үз вазифасы.

— **Габделхәй.** Төрле кеше бар бит. Кайчагында чакырылган кунакларны да концерт алдыннан артист янына кертмибез. Чыгышларына кадәр җырчыларның күңеленә тиярлек сүзләр ишетелмәсен өчен шулай эшлибез.

**— Бер хыялый сорау: яшьлегеңә кире кайтып, тормышыңны яңадан башлар идеңме?**

— Һич юк. Узган яшьлегем җиңел булмады. Бу-

генге дәрәҗәм бөртекләп җыйган энҗе-мәрҗән сыман кадерле миңа.

— **Кызларыгызны җырчы итәсегез киләме?**

— **Хәния.** Бик килә!

— **Габделхәй**. Үзләре ничек телиләр бит. Ләкин кызларга эстрадада җырларга авыр булачак. Аларны иң элек Хәния Фәрхи балалары дип кабул итәчәкләр.

— **Хәнияләр Казанга күчә, диләр...**

— **Хәния.** Алла боерса, теләк бар.

— **Габделхәй.** Хәниянең бик күчәсе килә. Ә минем 23 ел яшәгән Чаллымнан аерыласым килми. Шулай да калганын киләчәк күрсәтер.

— **Эстрадада август ае Салаватныкы, октябрь Хәниянеке, март Габделфәтнеке булып тамгаланды. Бу традицияне быел сез генә үзгәртмисездер инде.**

— Сочида юкка гына көч туплап ятмыйбыз бит. Унсигезенче октябрьдән, Алла боерса, Казанда «Бәйрәм» ансамбленең концертлары башлана. Сценарийны язучы Марат Кәбиров белән бергәләп төзедек. Нигезендә — биографиям. Яңалыклар күп, тик әлегә бөтенесен әйтеп бетерәсем килми. Концертыма килгән һәркем мөлдерәмә күңел белән китә алсын дигән теләгем бар.

— **Соңгы елларда җырчылар гел яңа җырлар белән генә чыгарга яраталар...**

— Бу яңалыкны Салават кертте. Ә без, башка артистлар, аңа иярдек шикелле. Җыр өлгергәнме, юкмы — анысында эш юк. Дөрес түгел бу.

— **Хәния, Сез — драма артисты. Шул юлны дәвам итсәм, зуррак уңышларга ирешер идем дип уйлаганыгыз юкмы?**

— Ирекле рәссам диләрме әле? Мин дә шулай: режиссер кул астында барыбер ачыла алмас идем.

— **Сәнгатьтән читкәрәк китеп, хатын-кыз бәхете турында сөйләшик әле. Әйтик, Габделхәй белән беренче очрашуыгыз хакында.**

— Безне яучылап таныштырдылар. Ул чакларда бөтен ансамбльне берьялгызым тарта идем: дирек-

торы да, бухгалтеры да, администраторы да, җырчысы да үзем. Барысыннан да арыган чагым. Кич белән Камал театрында зал тулы тамашачы җыеп концерт куеп кайттым да өйдә үзем җырлап, үзем елап утырганда, ишек шакыдылар. Күршеләрем Рәис белән Галия икән. Кулларында шампан шәрабы. Галия әйтә: «Яшь гомерләрең зая уза бит. Чаллыдагы абыйлар күршесендә бер әйбәт егет яши, таныштырыйк әле шуның белән», — ди. Уенын-чынын кушып сөйләштек. Ялгызлык бик авыр бит: янындагы хатын-кыз ни әйтер дип, парлыларга күтәрелеп карарга да куркыта. Казан сабан туе көне иде, килде бу егет. Карыйм: буе-сыны бар, бик мәгънәле сөйләшә. Мәйданнан кайттык та ашарга утырдык. Шунда Габделхәйнең кулы киселде. Яраны бәйләгәндә, кулларыбыз кулга тиеп китте. Ток суккан шикелле булды... Икенче атнада ул кабат килде. Мине бөтенләйгә алып китәргә...

**— Исеме һәр татар кешесенә таныш Хәния авылга килен булып төшкәч, каенанагыз, авыл ничек кабул итте?**

— Артист килен нишләр икән дип сынаучылар булды, әлбәттә. Ә менә әти-әни ничек бар — шулай кабул итте. Алар — «кызым», Габделхәйнең сеңелләре «туган апа» диләр. Мин бит авыл баласы, аларга кайткач, гап-гади киленгә әйләнеп калам. Төп эшем — ашарга пешерү. Бергәләп бәрәңге алабыз, кирәк булса сыер да савам. Мине эш куркытмый.

**— Габделхәй, популяр җырчы белән яшәү авыр түгелме?**

— Дөресен генә әйткәндә, мин артистларның кем икәнлекләрен дә белми идем. Хәния танылган җырчы дип башыма да китермәдем. Мин җырчыга өйләнәм дип өйләнмәдем. Аның үткәне дә мине кызыксындырмый. Хәнияне хатын-кыз итеп кабул иттем. Ул — ике кызымның әнисе, минем яраткан хатыным.

**— Тормышның авырлыгын да, җиңеллеген дә үз иңнәрендә күтәреп, ирекка өйрәнгән Хәния гаилә тормышын ничек кичерә?**

— Ишле гаиләдә үстем. Әти эштә, тормыш йө-

ге әни җилкәсендә икәнен күрә идем. Габделхәй исә тормышның бар мәшәкатен үз өстенә алды — кибеткә дә йөртми. Кулыма акча да тотканым юк. Мин чыгыш җырлыйм гына. Рәхәт бит. Ләкин алай гына булмый икән. Алтын читлеккә уралган җешләрне сүтәсе килә башлый.

**— Гел бергә булу арытмыймы?**

— Арыткан кебек тә була, әмма Габделхәйне озаграк күрми торсам, сагына башлыйм. Беренче елларны «һай бәхет, һай бәхет» дип җырладым. Аннары «Бәхеткә түзеп кара» дигән җыр туды. Рәхәтлекне тоеп, шуңа түзеп кала белергә кирәк икән. Анысы — иң кыены.

**— Димәк, һаман «без бәхетле» дип әйтә аласыз әле?!**

— **Габделхәй.** Ышаныш әйтәм. Әти-әнием исәнсау. Гаиләбез түгәрәк. Бергәләп эшлибез. Шушы бәхет түгелмени?!

— **Хәния.** Тормышта күпне күрдем. Инде дөньям түгәрәкләнде, Аллага шөкер, гаиләмдә тынычлык. Хөкүмәтебез, хезмәтемне бәяләп, «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исем бирде. Тамашачылар җырымны тыңларга зал тутырыш килә. Ходай күпсенмәсен, мин бик бәхетле.

*«Акчарлак» газетасы*
*2001 ел, октябрь*

# «Казанда мин үземне таптым...»



*Планетаның төрле почмакларында яшәгән милләттәшләрем белән еш аралашам. Миңа калса, Америка, Төркия, Япония, Кытай, Финляндия һәм башка җирләрдә гомер иткән татарлар ана телебезне Россия җирлегендә яшәүчеләргә караганда яхшырак беләләр. Алар белән сөйләшкәндә, татар теленең байлыгына, матурлыгына тагын бер кат инанасың.*

*Рокыя Сафа — дөньяга сибелгән татарның бер кызы. Ул Японидә туып үскән. Әбисе белән бабасы Россиядән киткәндә, әтисе бик кечкенә була, ә әнисе Кытай чигендә дөньяга килә. Россиянең барлыгын белеп яшәсәләр дә, бу илне үз күзләре белән күрү насыйп булмый аларга. 30—40 нчы елларда Япониянең Кубо шәһәрендә татар мәхәлләсендә берничә йөз татар исәпләнә. Үз мәктәпләре, мәчетләре була. Рокыя да дүрт сыйныф белемне ана телендә ала. Аннан соң инглиз мәктәбендә укый. Күршедәге дус-*

*лары белән япон телендә аралаша. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң алга киткән Япония Россиядән күчеп килгән эмигрантларны үзенә сыендырырга теләми. Бу вакытта татар мәхәлләсенең Төркия дәүләте белән элемтәсе нык була. «Алар безгә төрек дигән документ әзерләп бирделәр. Шулай итеп, без төрек сәхабәләре булдык», — дип искә ала Рокыя апа ул вакытларны. Шуннан соң Япониядә яшәгән милләттәшләребез күпләп Төркиягә китә. Бу вакыт Рокыяның ике апасы, инглизләргә кияүгә чыгып, Америкада яшәгән була. 18 яшьлек Рокыя да Сан-Францискога барып төпләнә.*

*Рокыя апа — бик мөлаем, акыллы татар хатыны. Татар дип җан атып йөрүче милләттәшләребезнең берсе. Татарстан, бездәге хәлләр белән ул һәрдаим хәбәрдар. Өченче Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә миңа Рокыя Сафа белән очрашып сөйләшү мөмкинлеге туды.*

**— Рокыя апа, Сез Япониядә туып үскәнсез, хәзер Америкада яшисез. Сезгә кайсы ил якынрак?**

— Әлбәттә, Япония. Ул — минем туган илем. Анда минем бала чагым, яшьлегем узган. Беренче мәхәббәт хисләре кичерелгән. Хәзер дә, бергә уйнап үскән дусларым белән аралашканда, ул илне сагынып искә алабыз. Ел саен ирем Даян белән (ул да Япониядә туып үскән кеше) бергәләп, үз илебез дип барып кайтабыз.

**— Казанга беренче тапкыр кайчан килдегез?**

— Хат аша журналист Римзил Вәлиев белән таныштык. 1997 елның август аенда ул безгә икенче Бөтендөнья татар конгрессына чакыру җибәрде, һәм без беренче тапкыр татар иленә аяк бастык.

**— Нинди хисләр кичердегез ул вакытта?**

— Беләсезме, бәләкәй чакта уйланылмаган. Хәзер күңелгә «Үзең татарсың, ләкин татар дигән мәмләкәт юк; Япониядә тугансың, сине үзләренеке итеп кабул итмиләр; төрек паспорты бирделәр, әмма син төрек түгел. Кем соң син?» дигән уйлар еш килә. Тәүге тапкыр Казанда мин үземне таптым. Җаным

рәхәтлек кичерде. «Менә кайда икән ул үземнекеләр!» — дип уйладым. Казанны һәрвакыт сагынып яшим, сагыныш киләм. Концерт, театрларга йөрим. Татарстанның табигатен яратам. Без бәләкәй чакта әбкәм: «Их, безнең каен урманнарын күрсәгез!» — дип сөйли иде. Ә мин нәрсәсе бар инде ул каенның дип уйлый идем. Монда килеп каен урманын күргәч, матурлыкка сокланып, әби-бабаларымны сагынып, утырып еладым. Аларның яшьлекләре белән очрашкандай булдым. Хәзер дә каенлыкка керсәм, йөрәгем жу итеп китә.

**— Рокыя апа, Сез үз телебездә бик матур итеп сөйләшәсез. Ә балаларыгыз татар телен беләләрме?**

— Улыбыз Камал, кызыбыз Әдилә икесе дә, Аллага шөкер, татар телен камил беләләр. Без өйдә гел үзебезчә сөйләшәбез. Гомумән, Америкадагы татар гаиләсендә туып үскән яшьләр телне дә, динне дә, гореф-гадәтләрне дә югалтмыйлар. Сан-Францискодагы татар мәхәлләсенә бәйрәмнәрдә 250—300 ләп кеше җыелабыз. Яшьләребез дә теләп киләләр.

**— Гомер тиз уза. Сезнең Казанга тәүге тапкыр килүегезгә дә биш ел вакыт үткән. Менә Сез кабат ата-бабалар җирендә. Өченче Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә дөньяның төрле кыйтгаларыннан җыелган милләттәшләребезгә, гомумән, татарларга әйтер сүзегез нинди булыр?**

— Телебезне, динебезне, гореф-гадәтләребезне югалтмыйк. Дөньяда татар дигән бөек, горур милләт барлыгын тагын бер кат исбатлыйк. Барысы да үзебездән тора.

**— Теләкләрегез, әңгәмәгез өчен рәхмәт Сезгә.**

*«Татарстан яшьләре» газетасы*
*2002 ел, август*

# «Һәр тыңлаучының сулышын тоям...»



*«Татар җыры — 95» конкурсында сәхнәгә кара күзлек киеп, гармун күтәреп чыккан, моңлы итеп җырлаган егеткә татар тамашачысы шундук игътибар итте. Ул тиз арада популярлашып китте. Закир Шаһбан исемен кызлар да күңел түренә салып куйдылар.*

*Закир — дөньяга сибелгән татар халкының моңлы баласы. Ул — Новосибирск өлкәсенең Чаны районы Тармакүл авылы егете. Гаиләдә иң олы бала. «Язмыш минем башымнан сыйпамады, ләкин мин бирешә торганнардан түгел», — ди Закир. Тумыштан дөнья яктысын күрүдән мәхрүм малай 8 яшенә кадәр туган авылында яши. Аннан соң аны Новосибирскидагы сукырлар мәктәбенә урнаштыралар. Язгы, җәйге, кышкы каникуллары Тармакүлдә уза. Шәһәрдә рус телендә укыса да, татар җырыннан аерылмый Закир. «Минем «Рекорд» дигән радиоалгычым бар иде. Зур тырышлык белән урта дулкыннарда Казаннан кичке тапшыруларны тыңлый идем. Җыр миңа яшәргә көч бирде. Әнием Гөлфия дә авыл-*

*да оста җырчылардан саналды. Миңа да моңга мәхәббәт аннан күчкәндер, мөгаен».*

*Закир белән сөйләшеп утыруы бик рәхәт. Ул дөньядагы һәр яңалыктан хәбәрдар. Аның хәтеренә шаккатам. «Республикада ничә мәдәният сарае бар, шуларның директор, кассир бүлмәләрендәге телефон номерларын шәһәрара кодлары белән хәтерлим», — ди ул.*

*Күптән түгел миңа Закирлар гаиләсендә кунакта булырга туры килде. Озак кына сөйләшеп утырдык.*

**— Закир, Казанга килергә ничек батырчылык иттең?**

— Казанда яшәрмен, зур залларда чыгыш ясармын дип хыялланырга да курка идем. Мин язмышыма рәхмәтле. Танышларым мине татарның мәркәзенә алып килде. Сукырлар җәмгыяте аша «Электроконтакт» җитештерү берләшмәсенә слесарь-җыючы булып урнаштым. Татар җырын яратуым мине буш вакытларымда аларның клубларына тартты. Гармунда үзем уйнап җырлавымны ишеткәч, инвалидлар фестивалендә катнашырга чакырдылар. Шушы чыгыштан соң Рүзәл Габитов белән таныштым. Ул мине Татарстанның халык артисты Миңгол абый Галиев белән очраштырды. Аннан соң мин Казан дәүләт педагогика институтының музыка факультетына укырга кердем. Җырчы булып китүемдә дә, «Татар җыры—95» конкурсында катнашып, лауреат булуымда да Миңгол абыйның өлеше зур. Мин аңа гомерем буе рәхмәт укыячакмын.

**— Кулыңа кайчан гармун алдың?**

— Безнең авылда җәен сыер савучы хатын-кызларны ачык машинада җәйләүгә эшкә йөртәләр иде. 15—20 хатын-кыз, бергәләп, халкыбызның «Озату» җырын җырлап китәләр, җырлап кайталар. Мин дә аларның җырлаганнарын тыңларга капка төбенә чыгып утыра идем. Биш яшемдә кулыма гармун алып, иң беренче өйрәнгән җырым шул булды.

**— Закир, пединститутның музыка факультетын тәмамлый алдыңмы?**

— Беренче курсны тәмамлагач, 1995 елда мине филармониягә эшкә чакырдылар. Көндезге бүлектә укый идем. Эшләп укыгач, икенче курста дәресләргә йөрергә вакыт калмады. Кышкы сессия имтиханнарын тапшырдым, язгысын вакытында бирә алмадым. Әнине җирләргә кайтып киттем. Көз көне язгы имтиханнарны да тапшырырмын дип укырга килгәч, дәресләргә йөрмәгән өчен институттан чыгарылуымны белдем. Шуны гына әйтәсем килә: мин, укыганда, бернинди ташламаларга да мохтаҗ булмадым. Күрмәүчеләр өчен махсус дәреслекләр булмаса да, имтиханнарны барлык студентлар белән тигез дәрәҗәдә тапшырдым. Беренче курсны ике «4»ле, калганнарын «5»леләр белән тәмамлаган идем. Укый алмаганыма үкенмим. Хәзер, Аллага шөкер, шоу-бизнеста да, продюсерлык өлкәсендә дә, иҗатта да тәҗрибәм бар инде.

**— Укуны дәвам итәргә теләгең юкмы?**

— Юк. Бу сүзләрем өчен, бәлки, кемнәрдер тәнкыйтьләр, шулай да бүгенге көндә, тәҗрибәң булмаса, диплом белән генә әллә кая барып булмый. Музыка училищесын, мәдәният академиясен, консерваторияне ел саен күпме кеше тәмамлый, шуның ничәсе үз һөнәре буенча эшкә урнаша икән? Белергә иде бу саннарны. Кешенең эшен кылган гамәлләре белән бәяләргә кирәктер. 1996 елда, «Мәгърифәт» газетасында җан авазым белән «кирәк булса, мин дипломны сатып та алам» дип, мәкалә бастырдым. Бәлки, ул амбицияле сүз булгандыр. Ләкин бу — минем шәхси фикерем. Укучылар Закир белем алуга каршы икән дип уйлый күрмәсен. Һәрнәрсәнең үз вакыты. Хәзер миңа уку кирәк түгел инде.

**— Сиңа кешеләрдәге нинди сыйфат күбрәк ошый, ниндие ошамый?**

— Мин ачык күңелле, тирән фикерле, гомумән, акыллы кешеләрне яратам. Икейөзлелекне кичерә алмыйм.

**— Яраткан җырчыларың кемнәр?**

— Хатын-кыз җырчылардан Зәйнәп Фәрхетдинова. Ир-ат җырчылар арасыннан Таһир Якуповның

җырлавын кечкенәдән үк яратып үстем. Ул башкарган җырларны бүген үз репертуарыма кертәм. Кызганыч, җырчыбыз арабыздан вакытсыз китте. Халык күңелендә үз урынын тапкан Таһир Якуповның иҗатын мәңгеләштерү өчен, бәлки, аның фондын оештырып булыр. Искә алу кичәләре оештырсак та яхшы булыр иде. Гомумән, Таһир Якуповның иҗатына кереп китсәм, күп сөйлим мин.

*Без Закир белән сөйләшкән арада, хатыны Гөлүсә табын әзерләде, әңгәмәбезне чәй өстәле янында дәвам иттек.*

**— Закир, яраткан ризыгың нинди?**

— Мин бик талымлы кеше. Гөлүсә һәр көнне: «Әтисе, нәрсә пешерим?» — дип кенә тора. Мин бит Себер ягыннан. Шуңадырмы, яратып ашый торган ризыгым — пилмән.

**— Гөлүсә белән ничек таныштыгыз?**

— Җырчы Фәйрүзә Сибгатуллина мине кунакка чакырды. Гөлүсә дә шунда иде. Ул минем иҗатыма гашыйк икән. Бер-беребезне беренче очрашканда ук аңладык. Язмыш кавыштырды безне.

*Безнең сөйләшүгә Гөлүсә дә кушылды.*

— Бервакыт телевизордан Закирның җырлаганын карагач: «Их, шуның белән бер генә тапкыр сөйләшеп утырсаң иде», — дигән идем. Фәйрүзә икебезне дә кунакка дәште. Без аңа рәхмәтле. Закир белән танышу минем өчен хыял гына иде. Гаилә корып бергә яшәрбез дип башыма да китермәдем. Ул Аксубайга кайтып әти-әниемнән мине сорады да, никах укытып бергә яши башладык.

**— Гөлүсә, хәзер әзме-күпме тәҗрибәң бар. Закир белән тормышыңны бәйләгәнгә үкенмисеңме?**

— Мин үземне бәхетле тоям. Безнең шулай, Закир уйлаган уйны мин телдән әйтәм, Закир әйткәнне мин уйлаган булам. Уйларыбыз, теләкләребез туры килә. Ходай шулай яраткандыр инде. Миндә бернинди үкенү юк һәм булмаячак та.

**— Закир, ә син мәхәббәтнең барлыгына ышанасыңмы?**

— Әлбәттә, барыбыз да мәхәббәттән яратылганбыз. Ул хис кешегә Ходай Тәгалә тарафыннан бирелә. Мәхәббәт ул — зур, илаһи көч, яшәү чыганагы. Гөлүсәм, без танышкач, шигырьләр яза башлады. Һәм менә быел Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга да керде.

**— Гөлүсә, Закирга дип атап язган бер шигырең белән укучыларны да таныштырмыйсыңмы?**

— Бик рәхәтләнеп. Шигырь «Әгәр күрсә синең күзләрең» дип атала.

Күзләреңә карап әйтер идем
Күңелемдәге тирән хисләрем.
Күтәрелер идең зәңгәр күккә,
Күрсә әгәр синең күзләрең.

Көннәр буе сиңа сөйләсәм дә,
Бетмәс төсле минем сүзләрем.
Зәңгәр диңгезләргә чумар идең,
Күрсә әгәр синең күзләрең.

Бакча сукмагыннан атлыймын мин,
Анда синең, синең эзләрең.
Бар дөньяны кочып назлар идем,
Күрсә әгәр синең күзләрең.

Болыннарга чыгып чәчкә җыям,
Матурларын сиңа эзләдем.
Син таң калыр идең гүзәллеккә,
Күрсә әгәр синең күзләрең.

Сиңа атап язам бу юлларны,
Кыерсытмас микән сүзләре?
Язар идемме соң шундый сүзләр,
Әгәр күрсә синең күзләрең.

Сиңа, дустым, бары синең өчен
Йөрәктәге кайнар хисләрем.
Тормыш юлын бергә үтәр өчен,
Гомерем буе сине эзләдем.

Кулларыңа гармун алган чакта,
Нигә моңсулана йөзләрең?
Нинди язмыш сайлар идең икән,
Әгәр күрсә синең күзләрең?

Урманнарда йөрим адашып мин,
Исертәләр нарат исләре.
Җыр-моңнарың юлдаш булыр иде,
Күрсәләр дә синең күзләрең.

Басып торам биек яр читендә,
Истә һаман синең сүзләрең.
«Барыбер,— дидең,— сине сайлар идем,
Күрсәләр дә минем күзләрем».

**— Закир, «Заман» төркеме егетләре гел юлда. Гастрольләрдә йөргәндә, өй сагындырамы?**

— Ничек кенә әле! Сине сагынып көтеп торучы яраткан кешең барлыгын тою көч бирә. Күпмедер вакыт аерылып тору безнең мәхәббәтне сыный. Никадәр еракта булсак та, без һәрвакыт телефон аша элемтәдә торабыз.

**— Җырчы егетләргә залда утырган кызлар, әлбәттә, күз салалар инде. Танышырга теләүчеләр дә була торгандыр әле?**

— Иҗат белән кызыксынган булып, батыррак кызлар концерттан соң сәхнә артына да керәләр. Кыюсызлары кырыйдан гына карыйдыр инде. Автограф бирәсең, сине тыңлаганнары өчен рәхмәт әйтәсең.

**— Ошаганнары буламы соң?**

— Мин — сентименталь кеше. Бик тиз гашыйк булам. Яхшы кешене дә тиз ачыклыйм, тоям. Ләкин өйдә минем яраткан хатыным, сагынып көтеп торучым бар. Йөрәгемдә башкага урын юк.

**— Син гастрольдә. Гөлүсә ялгызы кала. Көнләшмисеңме?**

— Юк. Аның мәхәббәте шулкадәр көчле һәм саф, мин аңа ышанам. Чын күңелдән ярата торган кеше хыянәткә бармый ул.

**— Хыянәтне кичерә алыр идеңме?**

— Хәзер дөньясы башка. Мораль принциплар үзгәрде. Ләкин мин шуңа да карамастан хыянәтне беркайчан да кичерә алмас идем.

**— Сәхнәдә син үзеңне ничек хис итәсең?**

— «Син тамашачыны күрмисең бит», — диләр. Күрмәсәм дә, мин һәр тыңлаучының сулышын тоям, нәрсә теләгәнен сизәм. Була шундый вакытлар: билет сатылып беткән, зал тулы тамашачы. Син — сәхнәдә хуҗа. Алкышлар, чәчәкләр... Артист өчен шуннан да бәхетле мизгелләр юктыр, мөгаен.

**— Менә хәзер туган ягыңа кайтып яши алыр идеңме?**

— Мин үземне Казаннан башка күз алдына да китерә алмыйм. Монда халкыма хезмәт итәм. Кайчак үземнең Себердән килгәнлегемне онытып та җибәрәм хәтта. Татарстан җире, Казан каласы мине үзенеке итеп кабул итте. Моның өчен халкыма рәхмәтле мин.

**— Закир, син бәхетлеме?**

— Миннән дә бәхетле кеше юктыр. Бар нәрсә дә җитеш. Яраткан кешем янымда. Җырларымны тыңларга халкым бар. Ә иҗатыма килгәндә, мин аннан беркайчан да канәгать була алмыйм. Эзләнергә, табарга, халкым өчен җырларга да җырларга әле.

*«Юлдаш» газетасы*
*2002 ел, октябрь*

# «Парлы ялгыз булдым...»



*Үзен татар дип санаган кешегә Хәмдүнә Тимергалиева исеме яхшы таныштыр дип уйлыйм. Мин аны күптәннән беләм. Ул беркайчан да авырлыклар каршында югалып калмый, башын горур күтәреп, гел алга омтыла, өмет белән яши. Олы йөрәкле, кече күңелле кеше.*

*Өендә тәртип. Чәе һәрвакыт кайнаган, тәмле ризыгы пешкән булыр. Менә бүген сезнең хөкемгә тәкъдим ителәсе язма Татарстанның халык артисты Хәмдүнә Тимергалиеваның аш бүлмәсендә, чәй өстәле янында әңгәмә корганнан соң язылды.*

**— Хәмдүнә апа! Юбилеегызны каршы алган көннәрдә күңелегездә нинди хисләр йөртәсез?**

— Беләсеңме, Гөлназ, мин әле бүген дә үземне бала-чага кебек хис итәм. Авылыма кайтсам, рәхәтләнеп нәниләр белән уйныйм. Күңелем белән балачактан киткәнем юк. Ә иҗатыма килгәндә, төрле сәбәпләр белән җырлый алмый калган җырларым күп. Менә шуларны барлап, җырлап яшисе иде дим.

**— Авылым дидегез. Туган якка еш кайтасызмы соң?**

— Безнең Котлыяр авылы зур түгел. Нибары кырыклап йорт. Ул бик матур урынга урнашкан. Авылымны яратам. Хәзер инде сирәгрәк кайтыла. Быел авылыбызга нигез салынганга 145 ел. Менә шул вакытта кайтып, барлык туганнар, авылдашлар җыелып, әлеге датаны билгеләп үтәргә исәп бар, Ходай кушса.

**— Ә бөтенләй авылга кайтып яшәргә теләгегез юкмы?**

Авылда без үскән йорт һаман да тора. Сеңлем Әлфинә ел саен анда бакча утырта. Йортта әткәйәнкәй рухы бүген дә яши. Бик кадерле, изге нигез ул безнең өчен. Ә менә хәзерге көндә анда кайтып яшәргә мөмкин түгел инде. Моның өчен Казандагы дөньямны калдырып китәргә кирәк. Аннан соң олыгайган көндә авылда ялгыз яшәү авыр бит.

**— Хәмдүнә апа! Ә ирегез?**

— Иргә чыгып та, уңсаң гына... Бергә яшәп кала алмадык. Парлы ялгыз булдым мин.

Бүген мин ялгызлыгымнан да рәхәт тормыш юк икән дип, һәр туар көнгә шатланып яшим. Элек ялгызлыгымның кадерен белмәгәнмен. Менә тормышның икенче ягын да күреп карадым. Бер түбә астында ир белән хатын булып яшәү ул әле парлы дигән сүз түгел икән. Мин, киресенчә, иргә чыккач ялгыз булдым. Андыйны Ходай дошманыңа да күрсәтмәсен.

*Хәмдүнә апа шулай дигәч, шагыйрә Шәмсия Җиһангированың шигъри юллары искә төште:*

*Сикереп кенә атланыр да идең...*
*Атлары шул ап-ак бүз түгел.*
*Кем беләндер бергә булу әле*
*Ялгыз булмау дигән сүз түгел.*

Хәзер мин үзем генә түгел. Минем җырларым, яраткан тамашачым, үз иткән халкым, дусларым бар. Татарстанда да, Башкортстанда да кайсы җитәкчегә барып керсәм дә, хөрмәт белән каршы алалар, Аллага шөкер, рәхмәт.

**— Хатын-кызның бәхете нәрсәдә дип уйлыйсыз?**

— Бәхет күреп, иснәп, ашап карый торган нәрсә түгел. Аны кем ничек кабул итә бит. Син кешеләргә кирәк икән, сине яраталар икән яисә үзең яратасың икән, димәк, син бәхетле. Шулай булгач, мин дә бәхетле булып чыгам. Мин җырларым белән бәхетле.

**— Хәмдүнә апа, гел җырлап кына яшәп булмый бит. Буш вакытта нәрсә белән шөгыльләнәсез?**

— Безнең йортның беренче катында кибет. Иртән шуның түбәсенә иллеләп күгәрчен җыела. Әтиәниемә хәер булыр дип, һәр көнне шуларны сыйлыйм. Берәр көн күренмәсәм, тәрәзәмә кагылып ашарга сорыйлар. Узган ел энем Илһам Шәриф бакча алды. Менә шунда казынырга яратам. Яз башыннан кишерен, кыярын утыртам. Чәчәкләр үстерәм. Розалар утыртырга исәбем. Өйдә дә гөлләр үстерү белән мавыгып киттем. Гомерем буе гөлләр үстерергә, өйдә попугай, песи асрарга хыялландым. Менә шул хыялларымны да тормышка ашырырга уйлыйм, Алла боерса.

**— Башкортстанда узган биш ел гомерегезне җәлләмисезме?**

— Җәллим. Күпме җырым җырланмый калды! Тамашачыдан аерылдым. Җырчы Хәмдүнә булудан туктадым. Шуңа күңелем әрни. Казанга кире кайткач та, күңелем тиз генә җырламады. Ниндидер бер кыл өзелгәндәй булды. Шундый көннәрнең берсендә Салават Фәтхетдинов ярдәм кулын сузды. «Хәмдүнә апа, өйдә утырма. Әйдә, Россия буенча җыр-

лап кайтабыз», — дип, юлга чакырды. Рәхмәт Салаватка. Шул гастрольдән соң элекке хәлемә кайта башладым.

Хәзер, Аллага шөкер. Эчке дөньям элеккеге Хәмдүнәгә әйләнде.

**— Иҗат бәйрәмегездә тамашачыны нинди җырлар белән куандырырга телисез?**

— Элек җырлаган иң яхшы җырларымны кабат сәхнәгә алып чыгарга исәп. Күп бит алар. «Кара күзем син», «Чияле тау», «Якты елга», «Җомга», «Сары чәчәк», «Картуф» һәм башкалар. Алар бүген дә актуаль. Әлбәттә, яңа җырлар да булачак. Фәрит Хатипов белән иҗади дуслыкта яшим. Ул — чын мәгънәсендә зур композитор. Җырлары озын гомерле аның. Фәрит белән «Җырым — юлдашым» дигән өр-яңа, романс тибындагы җыр әзерлибез. Сүзләрен Лена Шагыйрьҗан язды. Иҗат капчыгымда халкыбыз җырлары күп. Аларны эшкәртеп, кабат халыкка ташырасым бар. Казан тамашачысы белән, Ходай кушса, 29—30 октябрьдә филармониянең концертлар залында очрашырга исәп.

**— Бу ел сезнең өчен юбилей елы булып истә калачакмы?**

— Әлбәттә, бик күп җирләрдә гастрольләрдә булдым. Бу елда гына димим, якын араларда Мәскәү, Ханти-Манси, Ярославль, Ижевск, Уфа, Пермь, Екатеринбургта яшәүче татарлар белән очраштым. Халык мине онытмаган. Үз тавышым белән җырлыйм, фонограммага кушылып, авыз гына селкетмим. Утыз җиде ел шулай сәхнәдә. Тагын утыз җидене тартырга исәп. *(Көлә.)* Керосин бар, ут кына кирәк. Сәламәтлек булса, исән булсам, ныгытып җырларга теләк. Җыр хәзинәм җитәрлек.

**— Уңышлар Сезгә.**

*«Татарские новости» газетасы. 2004 ел*
*«Татарстан» журналы. 2004 ел*
*«Безнең гәҗит» газетасы. 2004 ел*

# «Бәхеткә түзеп кара...»



*Аның җырларында хатын-кыз язмышы. Дөресрәге, үз язмышы. Ул җырлар бик күп яралы йөрәкләргә дәва өләшә. Заманның ачы җилләренә каршы торырга дәрт өсти, дәрман бирә. Авыр чакта кайгыларга баш имәскә өнди. Сүземнең Татарстанның халык артисты Хәния Фәрхи-Бикташирова иҗаты турында икәнлеген аңлап өлгергәнсездер инде. Бүгенге сөйләшүдә мин Хәния белән аның еллар дәвамында иҗат репертуарын тулыландырып килгән җырлары аша әңгәмә корам.*

**— Ташлап киттең син мине...**
**Тол хатын диләр мине...**

— Ул вакытларны искә төшерсәм, йөрәгем хәзер дә жу итә... Яраткан эшем — сәхнәм бар иде. Гаиләм, пар канатым бар иде. Өч яшьлек кызыбыз Алиянең үсүенә һәр көнне сөенеп яшәп ятканда, ачы хыянәт белән очрашып, тормышым бер көн эчендә челпәрәмә килде. Бер мизгелдә — көтмәгәндә, уйламаганда мин ялгыз калдым. Юл чатында. Бу иремнең хыянәте түгел, бергә эшләгән, моңарчы дус булып йөргән кайбер хезмәттәшләремнең дә хыянәте иде. Табигатем белән мин шундый кеше (бәлки, бу яхшы сыйфат та түгелдер, ә икенче яктан яшәп китәргә көч тә бирә торгандыр): авыр чакларымда үземне аңламаган кешеләрне гафу итә алмыйм.

Өйдән берни алмыйча, кызым Алияне генә җитәкләдем дә Мәскәүгә чыгып киттем. Дөрес, яшь гаиләнең мактанырлык байлыгы да булмагандыр. Күземә ак-кара күренмәде ул чакта, миңа берни дә кирәк түгел иде. Мәрхүм Фирдәвес абый Вафинны бүген дә зур хөрмәт белән искә алам. Ул һәм Мәскәүдәге апам ярдәм кулын суздылар. Кызым Алия яшәргә көч бирде. Гастрольгә киткәндә, кайчак Алияне үзем белән алам, кайчакларда Мәскәүдә танышларда калдыра идем. Көзге, язгы пычрак юлдан кызымны иңбашыма утыртып, кулыма талонга алган ризык салынган чемоданымны күтәреп, Башкортстанга, туган авылыма кайткан, Алияне анда калдырган чаклар да күп булды. Алты ел гомер менә шулай үтте.

Алты ел ялгыз хатын, ялгыз ана булып яшәдем. Бу минем өчен тормышның бик зур сынавы иде. Иҗат, сәхнә кешесенә ялгызына бер дә җиңел түгел. Дөньяның никадәр авыр икәнлеген ялгыз хатын үзе генә аңлый.

**— Иркәң буласым килә,**
**Бикәң буласым килә.**
**Җилләреңә буйсынырлык**
**Җилкән буласым килә...**

— Ни генә булса да, тормыш дәвам итә. Җыр-

ларым миңа яшәргә көч бирде. Фәймә Айзатуллина дигән дустым бар минем. Шул бервакыт Нижгар якларына концертка алып чыгып китте. Анда мине бик яратып кабул иттеләр. «Син — Әлфия апабызның яшь чагы», — дип үсендереп, гомергә эстрадага бәйләп куйдылар. Минем яшисем килә башлады. Авырлыкларны җиңү өчен, бу тормышта һәркемгә дә, бигрәк тә иҗат кешесенә, иң беренче чиратта мәхәббәт, сөю-ярату, таяныч кирәк. Бер көнлек кенә түгел, сиңа олы хөрмәт белән караган, сине яраткан кеше кирәк. Андый кешем булды, әлбәттә. Мин — хисле кеше. Кемгәдер соклану, ерактан гына гашыйк булу да миңа яшәргә, эшләргә көч бирә.

«Бәйрәм» ансамбленең оешып килгән чагы. Концертлар оештырырга кирәк. Ярдәм сорап, җитәкчеләргә мөрәҗәгать итәсең. Ялгызлыгым монда да киртә булып килеп баса. Кайсы җитәкчегә ишек шакысам да, ул миңа иң элек хатын-кыз итеп карый. Ә миңа сөйләшү башында ук үземне ялгыз хатын, бер көнлек җырчы итеп түгел, бәлки шәхес итеп күрсәтә белергә кирәк. Ходайга зур рәхмәтлемен. Ул миңа шул чакларда үзем булып калырга ярдәм итте.

Ел саен Казанда Камал театры бинасында концертларым гөрләп үтә. Зал тутырып тамашачы килә. Репертуарымдагы җырларны халык, тиз арада отып алып, табыннарда җырлый башлый. «Үпкәләсәң, әйдә, үпкәлә» җыры шуларның берсе. Менә шул чорда ярдәм кулы сузган, аталарча киңәшләрен биргән театр директоры Шамил Зиннур улына рәхмәтлемен.

Бар да әйбәт кебек. Сәхнәдә мине ханбикә итеп тотучы тамашачым, кирәк чакта булышырга әзер торучы дусларым бар. Менә концерт бетә. Җырларымны тыңларга килгән тамашачылар парлашып-парлашып өйләренә таралалар. Ә мин берүзем кеше почмагына кайтып авам. Янымда Алиям дә булмаса, үзәкләрем бигрәк тә өзелә. Кулыма гармун алам, бармакларым талганчы уйныйм-уйныйм да сыңар мендәрем өстенә барып капланам.

**— Очраштык та уйнап кына,**
**Гашыйк булдым чынлап сиңа.**
**Хәзер көтәм күрешүне,**
**Сәгатьләр санап кына...**

— Үрсәләнеп уздырган көннәрем дә, төннәрем дә күп булды. Сәхнә тормышына гына ышаныш яшәп булмый. Җырчы Хәнияне бүген тамашачы ярата, әмма иртәгә аны танымаска да мөмкиннәр дип уйлап, үз алдыма тормышымны үзгәртергә дигән максат куйдым. Шундый көннәрнең берсендә Габделхәй белән таныштырдылар... (Бу турыда алдарак бирелгән әңгәмәдә әйтелде. — *Г.Ш.*) Тормышыбыз бик матур, Аллага шөкер. Алия белән алар беренче көннән үк бер-берсен якын иттеләр. Габделхәй ул бик бала җанлы. Баланы тәхеттә тота торган кеше. Аңа Алсу белән Алия арасында бернинди аерма юк. Моның өчен мин Габделхәйгә мең рәхмәтлемен. Бу аның киң күңелле, олы йөрәкле булуыннан киләдер. Алия дә Габделхәйгә әтием дип кенә тора.

**— Атлыйбыз икәү бергә,**
**Янымда тиңем бара.**
**Сагышларга кем дә түзә,**
**Бәхеткә түзеп кара...**

— Бар авырлыкны үз җилкәмдә күтәреп өйрәнгәнгә, башта гаилә тормышына кереп китүе сәеррәк булды. Мин үскәндә, безнең гаиләдә ирләр эшен ир кеше, хатын-кыз эшен хатын-кыз эшли иде. Ә Габделхәй ир-ат эшен дә эшли, миңа да булышырга өлгерә. Бу миңа башта гаҗәп тоелды, аннан рәхәтлеккә чумдым. Минем өчен әкияттәгедәй тормыш башланды. Үзем дә сизмәстән, кулымда булган бөтен дилбегәләремне аңа тапшырдым. Мин өйдә хуҗабикә. Яшь бала белән утырам. Кибеткә йөрү юк, кеше күрү юк, аралашу юк. Дөнья телевизор, радио һәм Габделхәй белән чикләнгән. Үзе бик рәхәт чаклар да иде ул. Шулай да... Бераздан ул минем моңайганны күрде, рухи яктан күңелемә нәрсәдер җитми башлаганны аңлады. Мин сәхнәдән, тамашачы һәм җырлардан башка яши алмый идем. Габделхәй минем белән һәрвакыт бергә булыр өчен эшен калдырды. Бу үзе бер батырлык иде.

Бергәләшеп яңа ансамбль төзедек. Фәрит Әхсәнов, Илгиз Закиров һәм гитарист егетләр белән эшкә керештек. Беренче концертыбыз Биектауда узды. Иҗат өлкәсендә бөтен дилбегәләр Габделхәй кулында. Бар да яхшы кебек. Сәхнәгә чык та җырла гына. Әмма берара мин кабат «тыпырчына» башладым. Миңа янә нәрсәдер җитми. Нәрсәдер түгел, дөресрәге, иҗатташ дусларым белән аралашу җитми иде. Сәхнә артында торган Габделхәйгә боларны аңлау бик үк җиңел булмады. Аның өздереп, кискен итеп әйтеп куя торган гадәте бар. Шуның аркасында күз яшьләрем дә аз таммады. Әмма иҗат казанында ныграк кайный башлагач, ул барысын да аңлады. Сабырлык һәм берберебезнең күңелен аңлау ярдәм итте безгә. Бәхеткә түзеп калу, бәхет йөген чәчми-түкми алып бару шулдыр ул.

**— Безгә дигән гомер бергә-бергә,**
**Берәм-берәм еллар коела.**
**Бер җылы сүз әйтә алмадым кебек,**
**Әйтә алмадым гомер буена...**

— Яхшы сүз беркайчан да артык булмый. Габделхәй тыштан артык кырыс булып күренсә дә, күңеле нечкә аның. Ул тупас итеп эндәшкәнне, кырын караганны яратмый. Көненә ничә тапкыр чыгып китеп, ничә тапкыр кайтып керсә дә, аны үбеп озатырга, елмаеп, үбеп каршы алырга кирәк. Үзе дә игътибарлы. Габделхәй безне иркәли белә ул. Рәхәт әйбердән беркайчан да туймыйсың бит, җылы сүзне дә күпме генә кабатласаң да артык булмыйдыр.

**— Күзләреңне алма, алма күзләремнән,**
**Кулларыңны алма, алма билемнән.**
**Гомер үтә бирсен, ә без синең белән**
**Китмик әле, китмик яшьлек иленнән...**

— Кеше эшләгән эшләре, кылган гамәлләре белән еллар узган саен матурая гына барырга тиеш. Күңеле белән картаймаса, картлык куркытырга тиеш түгел аны. Безнең халкыбызда ак әбиләр, ак бабайлар бар. Мин дә картлыгым нәкъ менә шуларныкы сыман булсын иде дим. Ә күңелем белән әле мин бары унсигездә.

**— Тел ярасы төзәлми шул,**
**Тән ярасыдай түгел.**
**Нигә шулай өзгәләнеп**
**Әрнисең икән, күңел?**

**Шомырт ак чәчәк атса да,**
**Җимеше кара була.**
**Гайбәт сүз йөрәкне телә,**
**Һич төзәлмәслек яра...**

— Без Габделхәй белән гел бергә. Бәлки шуңадыр, нахак сүз безнең арага үтеп керә алмый. Дөрес булмаган сүз искән җил кебек оча да китә.

Тамашачы яраткан җырчысын күкләргә күтәрерлек итеп ярата белә, шул ук вакытта мәрхәмәтсез дә ул. Бәхетсезлегенә сөенеп гаҗәпләндерә ул аны. Бернишләп тә булмый, адәм баласы шулай яратылган. Мин аларны гаепләмим.

**— Күңелемне күпме кара көннәр**
**Каралтырга теләп карады.**
**Көн таралды, күңел каралмады,**
**Бу дөньяда сөю бар әле...**

— Үземә начарлык эшләгән кешене беркайчан да гафу итмим. Минем өчен кирегә юл юк. Холкым шундый. Әмма күктә Ходай Тәгалә тарафыннан никах укылган иреңне гафу итәргә кирәк дип саныйм. Сөюнең көче шуның белән сыналадыр. Габделхәй ул — балаларымның яраткан әтиләре. Тормыш булгач, төрле чаклар була. Гел матур итеп, бизәкләргә генә төреп сөйләп утырсам, миңа берәү дә ышанмас. Бар да ал да гөл булса, яшәү кызык булмас иде. Чагыштырып карамыйча, яхшылыкның кадерен белмисең ул.

Каршылыкларны җиңеп, тормышны ярып алга барырга, әлбәттә, сөюебез ярдәм итә. Мәхәббәтебезнең җимеше Алсуыбыз бар. Бер-беребезне бәйләп тота торган иң зур көч ул. Кайвакыт Габделхәй, гастрольләр оештырырга дип, йә Казанга, йә Себергә, йә башка җиргә чыгып китә. Шул вакытта да без бер-беребезнең уйларын ара ераклыгына карамастан тоябыз.

**— Минем әле иң бәхетле чагым,**
**Яннарымда сөйгән яр әле.**
**Саф хисләргә урын бетте димә,**
**Бу дөньяда сөю бар әле.**

— Аллага шөкер, минем әле бик бәхетле чагым. Бу сүз эченә барысы да — хатын-кыз бәхете дә, ана, бала бәхете дә сыйган.

*«Сөембикә» журналы*
*2004 ел, апрель*

# «Мин әлегә ирекле...»



*Татар җыр сәнгатендә Резидә Шәрәфиеваның бүгенге көндә уз урыны бар. Аның белән кызыксыналар, аны яраталар. Җырчының һәр җырында мәхәббәт чагылыш таба. Безнең сөйләшүебез дә нәкъ менә шул изге хис — мәхәббәт турында.*

***Якыннан танышу өчен блицинтервью***

**— Резидәгә нәрсә ошый икән? Җәйме, кышмы?**

— Җәй.
**— Алмамы, грушамы?**
— Алма.
**— Җырмы, биюме?**
— Җыр.
**— Авылмы, шәһәрме?**
— Авыл.
**— Гитарамы, баянмы?**
— Баян.
**— Шигырьме, көйме?**
— Шигырь.
**— Көнме, төнме?**
— Көн.
**— Мунчамы, саунамы?**
— Мунча.
**— Киномы, театрмы?**
— Театр.

**— Казан белән Чаллы арасында йөреп туймадыңмы, Резидә?**

— Дөресен генә әйткәндә, туйдым. Юлда йөреп, үземне карарга да, яңа җырлар өйрәнергә дә вакыт җитми. Үзем машина йөртә белмим, бөтен тапканым Чаллы белән Казан арасында автобуста йөреп бетә. *(Көлә.)* Казан—Чаллы таксистлары мине таный инде.

**— Әгәр дә син Казанда яшәсәң яки Чаллыда гына иҗат итсәң, вакытың күп булыр иде. Ул чакта ниләр эшләр идең икән?**

— Бассейнда йөзәр идем, биергә өйрәнергә йөрер идем. Лайма Вайкуле кебек биисем килә. Менә шундый хыяллар белән яшим.

**— Сине Казан тамашачысы Казанныкы итеп күрергә тели. Аларның теләкләре кайчан тормышка ашачак соң?**

— Мин яңа 2005 елны Казанда, үз фатирымда каршыларммын дип өметләнәм.

**— Халыкта төрле сүзләр йөри. Кемдер, Резидә кияүгә чыккан икән, ди, кайсысыдыр, бәби алып кайткан икән, ди. Әйдә, укучыга серне ачыйк булмаса.**

— Бу әйбәт гайбәт. Соңгы вакытта бик күпләр мине кияүгә чыгуым, бәби алыш кайтуым белән котлыйлар. Үземә дә кызык. Димәк, тамашачы мине гаиләле итеп күрергә тели. Ходай Тәгалә насыйп итсә, бу чынга ашар. Бер җырымда әйтелгәнчә, җанга яр таба алганым юк. Русчалатып әйтсәк, если что, мин әлегә ирекле. *(Көлә.)* Миңа насыйп яр кайда йөридер?

**— Насыйп ярың нинди сыйфатларга ия булырга тиеш инде?**

— Иң беренчесе — тыйнак булсын. Мактанчыкларны җенем сөйми. Мин үзем Кәҗәмөгез йолдызлыгында туганмын, сүземдә тора торган кеше. Вәгъдә иткәнне үтим. Башкалардан да шуны таләп итәм.

Әтышкы кыяфәтен тасвирлый алмыйм. Аның эчке дөньясы миңа ошасын. Ир булгач, ул терәк булырга тиеш. Мин таяныр кеше булсын.

**— Резидә, синең җырларыңның күбесе мәхәббәт турында. Алар кемгә дә булса багышланамы?**

— Әйе, һәр җырымның тарихы бар. Бу көннәрдә «Табышым» дип аталган яңа җыр әзерлим. Аның авторлары — Гөлнара Сабирова белән Ринат Гобәйдуллин. Анда мондый юллар бар:

Үткәннәремә үкенмим,
Өзгәләми ялгышым.
Югалтканым берни түгел,
Син — гомерлек табышым.

Бу җырны башкарырга «табыш» кирәк. Әлегә андый кеше янда юк.

**— Резидә Шәрәфиева белән танышырга, дус булырга теләгән кеше күптер инде. Синең дусларың күпме?**

— Дусларым күп. Авыр вакытта ярдәм итәргә әзер торучылар да җитәрлек, Аллага шөкер. Мин дусларым белән ихлас. Аларга рәхәт икән — сөенәм, борчулары бар икән — уртаклашам. Миндә көнләшү дигән әйбер юк.

— **Резидә, син бүгенге көндә үзеңә нәрсә теләр идең?**

— Әлеге сорауга репертуарымдагы бер җыр сүзләре белән җавап бирәсем килә.

Үткән гомер үткән инде,
Алдагысын кем белсен?!
Бәхет, килсә, бүген килсен,
Соңга калып килмәсен.

— **Ә укучыларга теләкләрең нинди булыр?**

— Бәхетләре үзләре белән янәшә атласын.

— **Амин.**

*«Татарстан яшьләре» газетасы*
*2004 ел, ноябрь*

## *«Исәп озак җырларга...»*



*Татарстанның халык артисты Фердинанд Сәләхов белән юлда йөрүе рәхәт. Сәясәт, икътисад, мәдәният, милләт турында тирән хәбәрдар, гомумән, төрле темага сөйләшә алырлык киң эрудицияле җырчы ул. Озын юлга сәфәр чыкканда, төрле мәзәк хәлләр сөйләп көлдереп бара, бик сорасак, җырлап та ала. Юл авырлыгы, вакыт үткәне сизелми дә кала.*

*Тольяттидагы татар милли-мәдәни автономиясе туган көнен билгеләп үткәндә, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты чакыруы буенча Фердинанд та, анда барып, татар тамашачысы белән очрашты. Ул, замана шаукымына ияреп, эстрадага гына күчкән җырчы түгел. Фердинанд, инде онытылып барган халкыбыз җырларын*

*яңартып, беркайда яңгырамаганнарын да табып тамашачыга җиткерә. «Татар халык җырлары» дигән җыентык — музыкаль тәлинкә чыгарып, татар тыңлаучысына тәкъдим итте. Татарстаннан читтә гомер итүче татар кешесе озын, моңлы көйләргә бигрәк тә мохтаҗ. Тольяттида да залга җыелган тамашачы Фердинанд Сәләховның халкыбыз көйләрен баянга кушылып җырлавын, акапелла башкаруын тын да алмый тыңлап утырып алкышларга күмде. Күбесенең күзләрендә яшь бөртекләре күренде.*

*Казанга кире кайтышлый, Фердинанд Сәләховка үземне кызыксындырган сорауларны яудырдым.*

**— Фердинанд, бүгенге көндә татар җырын башкарып кына залга тамашачы җыярга мөмкинме?**

— Ник мөмкин булмасын, җыям бит әле. Менә 10—11 декабрь көннәрендә УНИКСта булачак концертымда да беркайчан да зур сәхнәләрдән яңгырамаган халкыбыз җырлары булачак. Репертуарымда композиторлардан Резеда Ахиярова, Рәшит Кәлимуллин, Фәрит Хатипов, Мәсгудә Шәмсетдинова, шагыйрь һәм шагыйраләрдән Асия Юнысова, Шәмсия Җиһангирова, Разил Вәлиев, Роберт Әхмәтҗанов шигырьләренә язылган җырлар күп. Яңалары да байтак. Менә шуларны тамашачыма җиткерергә исәп.

**— Соңгы елларда татар җыр сәнгатендә җырчылар күбәеп китте. Син аларның иҗатына игътибар бирәсеңме?**

— Әлбәттә, кызыксынып барам. Дөрес әйтәсең, җырчылар күп, Аллага шөкер, әмма сәхнәгә менәргә тиеш булмаганнар, очраклылар да шактый. Яшьләребез сәхнәгә чыгалар да бер-берсен кабатлыйлар. Шуңа күрә анда бертөрлелек хөкем сөрә. Ә яшьләр белән эшләүче, катлаулы сәхнә серләренә төшендерүче милли эстрада режиссерлары юк.

Сөләйман Йосыпов, Сәет Рәембаков кебек затлы тавышлар юк хәзер. Әлбәттә, яшьләр арасында талантлылары да бар. Илдар Хәкимов, Гүзәл Ура-

зова, Сиринә Исламова, Лилия Муллагалиеваларның моңнары бар. Аларның киләчәге өметле.

**— Менә бишенче ел инде «Татар җыры» фестивале уза. Синең әлеге фестивальгә карашың нинди?**

— Әлеге фестивальгә чакырганнары да, анда катнашканым да, залдан караганым да юк. Шуңа күрә берни әйтә алмыйм.

**— Фердинанд, син зәвык белән киенә торган җырчылар рәтендә...**

— Сәхнә — үзе үк зәвык сорый торган урын. Зәвык — сәхнә таләбе. Тамашачы да бит концертка иң затлы киемен киеп килергә тырыша. Сәхнәгә ертык джинсы, футболка киеп чыгып баскан җырчыларны аңламыйм. Сәхнә һәм сәләмә ыштан... Кайсыдыр илләрдә тишек ыштан модададыр. Әмма татар тирес түккәндә кигән ыштанын да ямап кигән.

**— Сиңа концерт костюмнарын кем тегә?**

— Миңа нәрсә килешә, нәрсә килешми икәнлеген үземнән дә яхшы белгән кеше юк. Шуңа күрә үзем тегәм.

Аннан ирләр өчен сәхнә костюмнары тегүче белгечләр дә юк бездә. Бер тектергән идем, яңадан төзәтеп тегәргә туры килде, һәм иң кызыгы шунда: костюм тегүче останың үзенә дә минем вариант күбрәк ошады.

**— Җырчы иҗатында гаиләсе нинди роль уйный?**

— Төп рольне. Янәшә атлаган кешең сине аңларга, сиңа ышанырга тиеш. Ә инде сиңа ул ышанычны акларга кирәк. Бу яктан мин бәхетле.

**— Белүемчә, улың Марат сәнгать юлын сайлаган.**

— Юк, ул түгел — мин сайладым. Ун яшендә бала һөнәр сайлый белми. Ул башта Казан хореография училищесын, соңыннан Казан дәүләт сәнгать университетын тәмамлады. Хәзер Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле биючесе.

**— Синең концертларда ул катнашачакмы?**

— Һичшиксез.

**— Ә икенче улың, Русланың?**

— Ул КАИ тәмамлады. Компьютерлар буенча белгеч. Өйләнде, гаиләсе бар.

**— Синең исемең татар исеме түгел бит, Фердинанд. Шуның аркасында уңайсызлыклар килеп чыкканы юкмы?**

— Әйе, минем исем татарга бөтенләй ят. Үскәндә, авылда миңа бер яшь тә җиде айга кече энем Хәмзә исеме белән дәшәләр. Ә өйдәгеләр Фернад дип кенә йөртәләр иде.

Ә документларга килсәк, минем исем төрлесендә төрлечә язылган. Пенсиягә чыгарга вакыт җитеп, кәгазь җыярга тотынсам... Куркып торам, һәрберсе өчен суд юлында йөрергә туры киләчәк. Гомер пенсия күрәсем юк. Шуңа күрә исәп озак җырларга...

**— Амин, шулай булсын.**

*«Татарстан яшьләре» газетасы*
*2004 ел, декабрь*

# «Биюче булырга насыйп итмәгән...»



*Тулы исеме — Мотыйгуллина Рузия Һидиятулла кызы.*

*Туган ягы — Әлки районының Югары Әлки авылы.*

*Туган елы — Юлбарыс.*

*Йолдызлыгы — Балык.*

*Беренче роле — Нәркәс (И.Йомагулов. «Нәркәс»).*

*Яраткан бәйрәме — туган көне.*

*Яраткан төсе — ак, кара.*

*Үзе катнашкан яраткан спектакле — «Өч аршын җир» (А. Гыйләҗев), «Зөләйха» (Г.Исхакый).*

*Яраткан шөгыле — бакчада эшләү, чәчәкләр үстерү.*

*Гаиләсе: ире Закиров Ринат Зиннур улы — Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе; кызы Чулпан — «Казан» бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе.*

*Ирешкән уңышлары — Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган артисты.*

*Г.Камал театрында «Ханума» (А.Цагарели) спектакленең премьерасы булган көнне тәнәфес вакытында ике ханымның гәпләшеп торуларына колак салдым.*

*— Бүген тагын бер кат Рузиянең уйнавына сокланып, үзенә гашыйк булып утырам.*

*— Ходай Тәгалә бер үк кешегә талантны да, чибәрлекне дә бирсә бирә икән...*

*Хөрмәтле укучым! Бу сөйләшүдән син сүзнең әлеге спектакльдә төп рольне уйнаучы артист Рузия Мотыйгуллина турында барганын аңлагансыңдыр.*

*Иҗат иткән образлары белән тамашачы күңелендә югалмас урын алган, татар театр сәнгате тарихына үз исемен язарга өлгергән затлы артист ул Рузия ханым. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә утыз елдан артык эшләү дәверендә ул, берничә дистә роль иҗат итеп, тамашачы хозурына тапшырган.*

*Ә бит Рузия кечкенәдән артист булырга түгел, биюче булырга хыяллана. Татар сәнгатенә мөкиббән киткән, бөтен барлыгы белән җыр-моңны йөрәгендә йөрткән Һидиятулла абый гаиләсендә иркә кыз булып үскән Рузия өчен бу табигый хәл. Кечкенәдән төшләрендә үзенең зур сәхнәләрдә биегәнен күреп уяна ул. Авыл клубында һинд фильмнары күрсәтелгәндә, аларны көненә икешәр кат карап, нәкъ шуларча биергә тырыша. Әнкәсенең урын җәймәләреннән һинд кызларыныкыдай күлмәк тегеп, ялтыравыклар ябыштырып, авылдашлары алдында очып-очып бии. Менә шулай зур сәхнәләрдә биергә*

*хыялланган Рузия теләген тормышка ашыру максатыннан Казанга юл ала. Шәһәргә килгәч, бары да аңлашыла, профессиональ сәхнәдә бию өчен кечкенәдән үк махсус мәктәптә укырга кирәк икән. Шулай да кыз югалып калмый, театр училищесына юл тота. Училищеда уку еллары, остазлар, театр дигән зур сәнгать дөньясы белән танышу, сәхнә серләрен үзләштерү, олы сәхнәгә атлау... әле кичә генә кебек. Баксаң, 30 елдан артык вакыт сизелми үтеп тә киткән. 1972 ел. Театр училищесының икенче курсында укыган Рузия Мотыйгуллинаны И.Йомагуловның Г.Камал театрында куелачак «Нәркәс» спектакленә төп рольгә — Нәркәс образын иҗат итәргә чакыралар. Остазы Марсель Сәлимҗановның хәер-фатихасы, киңәшләре белән кыз эшкә тотына. Тәҗрибәле остаз төп рольне әле сәхнә серләренә төшенеп тә өлгермәгән шәкертенә тапшырып ялгышмый. Чибәрлеге, осталыгы белән Рузия ул вакытта ук тамашачыны үзенә гашыйк итә. Үзе белән театр сәхнәсенә яңа сулыш та алып килә. Менә шуннан башлана яшь артистның сәхнә эшчәнлеге. Бер-бер артлы матур, тирән эчтәлекле, татар тамашачысы күңелендә мәхәббәт яулаган героиняларны күп уйный Рузия Мотыйгуллина. Аның «Ай тотылган төндә»ге Шәфәгы, «Өч аршын җир»дәге Шәмсегаяны, «Бирнәсез кыз»дагы Ларисасы, «Әлдермештән Әлмәндәр»дәге Йөзембикәсе, Гөлфирәсе, «Күрәзәче»дәге Шәмсиясе, «Банкрот»тагы Гөлҗиһаны, «Ябырылу»дагы Ольгасы, «Диләфрүзгә дүрт кияү»дәге Диләфрүзе һәм башка образлары — эчке рух белән уйналган иҗат җимешләре. Ә инде Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» әсәре буенча Празат Исәнбәт сәхнәләштергән спектакльдә төп рольне — Зөләйханы тудыруы Рузия ханымны тагын бер баскычка күтәрде. Бу образ аша ул татар халкының инсафлылыгын, горурлыгын сәхнәдә бөтен тулылыгы белән җиткерә алды.*

*Бүген дә Г. Камал исемендәге театр сәхнәсендә*

*зур уңыш белән бара торган «Ханума», «Яра» спектакльләрендә Татарстанның халык артисты Рузия Мотыйгуллина төп рольләрдә.*

*Март башында гомер бәйрәмен билгеләп үтүче ураткан артисты турында хезмәттәшләре мондый бәя бирәләр: «Рузия — горур кеше, ул беркемгә баш имәс, ялагайланмас. Вак-төяк белән шөгыльләнмәс, һәр сүзен уйлап сөйләр. Ул булган җирдә гайбәт булмас. Менә шундый безнең Рузиябез».*

*Инде Рузия Мотыйгуллинаның үз фикерләрен ишетик.*

**— Рузия ханым, Сез өч дистә елдан артык Г.Камал театры сәхнәсендә иҗат итәсез. Шул дәвердә кайсы бөек шәхесләребез белән партнерлар булып бергә уйнау бәхете насыйп булды?**

— Йөз еллык тарихы булган татар театр сәнгатенә бәяләп бетергесез зур өлеш керткән остазым Марсель Сәлимҗановның шәкерте булуым минем өчен үзе бер горурлык. Безнең сәхнә олпат, затлы артистларга бай ул. Иҗатымның башлангыч чорында Галия Нигъмәтуллина, Галимә Ибраһимова, Фатыйма Камалова, Фоат Халитов, Габдулла Шамуков, Шәүкәт Биктимеров кебек сәхнә осталары белән бергә эшләдем, иҗатларына сокланып яшәдем. Алар — мине сәхнә серләренә өйрәтүчеләр. Празат абый миңа «Табигать турында сүз барса, аның бөтен матурлыгын, чәчкәләрнең төсләрен күз алдында тотып тасвирла. Кешеләр турында да күзаллап сөйләргә өйрән» дигән киңәш бирде. «Өч аршын җир» спектаклендә «Мине карт имән төбенә күмегез» дип башланган монолог сөйлим. Шуны башкарганда, туган авылымның зиратын күз алдына китереп, андагы каеннарны күрәм. Шигъриятне яратырга, сәхнә теленә Габдулла Шамуковтан өйрәндем. Кайчандыр зыялыларыбыз биргән акыллы киңәшләр сәхнә тормышында бүген дә кирәкле.

**— Вакытлар узу белән, күп тамашалар ре-**

**пертуардан төшеп кала. Шул спектакльләрдә уйналган рольләр онытыламы?**

— Юк, онытылмый. Режиссер биргән киңәшләргә кадәр истә кала. Сүзләрен генә бераз кабатларга кирәк була. Ә образга бөтен эчке тойгыларыңны җыеп, тиз арада кереп китәсең. Аның бер авырлыгы да юк.

**— Рузия ханым, Сез — татар, рус, дөнья классиклары язган сәхнә әсәрләрендә катнашкан, төп героиняларны уйнаган артист. Бу әсәрләрне уйнауда аерма бармы?**

— Начар әсәр белән яхшы әсәр арасында гына аерма бар. Нинди спектакльдә генә уйнасаң да, иң элек героеңның характерын эзлисең, табасың, өйрәнәсең. «Ханума» — грузин теленнән тәрҗемә. Аны грузин режиссеры Георгий Цхвирава сәхнәләштерде. Ул — безне, без, артистлар, аны хөрмәт итеп эшләдек. Грузин юморын татар тамашачысына җиткерә алдык шикелле.

**— Рузия ханым, кечкенәдән биюче булырга хыяллангансыз. Ул теләк бүген сүрелдеме инде?**

— Беләсезме, миңа гомерем буе бер төш керә. Имеш, мин очып-очып зур сәхнәдә бии́м. Хәзер дә биергә бик яратам. Гәүдәмнең пластикасы да бар. Шпагатка рәхәтләнеп утыра алам. Сәхнәләрдә куелган биюләрне бөтен йөрәгем белән карыйм. Шулай язгандыр. Ходай биюче булырга насыйп итмәгән. Язмышымны театр сәнгате белән бәйләгәнгә дә мин үкенмим, Аллага шөкер дип яшим.

**— Сезнең теләкне кызыгыз Чулпан Закирова тормышка ашыра дисәк, ялгышмабыз. Башта КДУның юридик факультетын, аннан соң Мәскәүдә ГИТИС тәмамлап, ул бүген дөнья илләре сәхнәләрендә бии. Рузия ханым, Чулпан җитәкләгән «Казан» бию ансамблендә берәр бию куеп карарга теләгегез юкмы?**

— Андый теләгем юк инде. Шулай да актерлык осталыгы, йөз, мимика буенча дәресләр алып барыр идем.

**— Гаилә, театр, гастрольләр, шәһәр тормышы... Сез бит авыл баласы. Туган яклар сагындырамы, еш кайтасызмы?**

— Әйе, мин — Әлки кызы. Юл булмау сәбәпле, безнең яктан Казанга килеп урнашучылар гомер буе туган авылларына кайтырга тилмереп яшәде. Әле дә хәтерлим. Укырга кергән елым. Авылга кайтасым килә. Әниләрне бик сагындым. Паром юк. Шунда мин, ир-атлар белән көймәгә утырып, бозлы елганы кичтем. Ул вакытта сагынуым көчле булгандыр инде, курку да булмаган. Шул чакларны уйласам, тәннәрем бүген дә чемердәп куя. Бүгенге көндә Татарстан Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев, елга аркылы күпер төзетеп, безне юллы итте. Мин аңа рәхмәт укып яшим. Ул Казан белән Кама аръягы районнарын якынайтты. Хәзер теләгән вакытта рәхәтләнеп кайтырга була.

Мин туган авылыма кайтканда, иң беренче эш итеп, зиратка тукталам. Элек зираттан курка идем. Хәзер ул — минем өчен иң кадерле җир, чөнки монда минем якыннарым, кадерле кешеләрем — әтием, әнием, бертуган энем күмелгән. Каберләренә зәңгәр чыршы утырттым. Олыгая барган саен, Ходай Тәгалә акыл кертә бит ул. Хәзер минем бөтен теләгем — әти-әниемә, туганыма үзем дога кылу. Әби-бабайларым, атам-анам динне хөрмәт итә торган кешеләр иде. Алардан мирас итеп алып, мин ул юлны дәвам итәргә тиеш дип саныйм.

Туган ягыма мин бала чактагы матурлыкны эзләп, яшьлегемдәге авылымны сагынып кайтам. Без җиләк җыйган тау битләре, кырлар, чокырлар шул ук. Анда апам, туганнарым яши. Ләкин авыл картая. Буш калган йортларның артуын күреп, күңелсезләнеп киләм.

**— Сез бәхетле хатынмы?**

— Аллага шөкер! Дөньям түгәрәк. Таяныч булырлык гомер иткән ирем, кадерле балам, хөрмәт иткән дусларым, яраткан эшем бар. Менә шул бә-

хет түгелмени?! Безнең әңгәмәне укучыларга да мин бәхетле тормыш, бәхетле язмыш телим.

**— Рузия ханым, шушы көннәрдә гомер бәйрәмегезне билгеләп үтәсез. Меңләгән газета укучыларыбыз исеменнән Сезне юбилеегыз белән котлыйбыз. Гел шулай туры сүзле, чибәр, яраткан артистыбыз булып калыгыз.**

*«Татарстан яшьләре» газетасы. 2005 ел, март*
*«Татарские новости» газетасы. 2005 ел, март*

Узган гасырның илленче, алтмышынчы, җитмешенче еллары. Дөньяның төрле кыйтгаларында таралып гомер итүче татар халкы милли җыр-моңга ихтыяҗ тоеп яши. Казаннан биш елга бер килгән җырчыларның чыгышлары гына татарның җыр-моңга сусаган күңелен сугара аламы соң?! Юк. Үзеңнеке булу кирәк. Менә шуңа күрәдер инде Самарада яшәүче берничә милләттәшебез — Илгиз Колючев, Камил Шамкаев, Шамил Саттаров, Мидхәт Галимуллиннар — милли эстрада ансамбле оештыру уе белән янып яши башлый. Ул вакытта партия, комсомол оешмалары, хакимият моңа каршы чыга. Әмма көчле рухны җиңеп булмый.

Язның матур бер көнендә, моннан нәкъ 35 ел элек чал Идел ярында урнашкан Самара каласында «Ялкынлы яшьлек» дигән татар җыр, бию, шигърият ансамбле дөньяга аваз сала. Тәүге концерт Елховка районының Тушли авылында була. Яшь талантлар башкарган «Мәк чәчәге», «Күбәләгем», «Әниемә хат», «Шомыртым» һәм башка җырлар, ана телендә яңгыраган шигырьләр тамашачыны йокыдан уятып җибәрә. Үзешчән артистларны аягүрә басып алкышлыйлар. Ансамбльнең даны тиз арада бөтен өлкәгә тарала. «Металлурглар» мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе — рус кешесе — зал, уен кораллары бирә, репетицияләр үткәрергә мөмкинлекләр тудыра. «Ялкынлы яшьлек»нең үз адресы барлыкка килә. Менә 35 ел инде аның үзгәргәне юк.

Тәүге адымнан соң шактый вакыт узган. Шушы дәвердә Россиянең кайсы почмакларында гына чыгыш ясамыйлар алар, хәтта, Казакъстанда яшәүче татарлар белән дә очрашып, милли җыр-моңнарыбызны, биюләребезне тәкъдим итәләр. 1977 елда ансамбльгә халык ансамбле исеме бирелә. 1987 елда «Ялкынлы яшьлек» Бөтенсоюз смотры конкурсы лауреаты була. 1992 елда, беренче Бөтендөнья татар конгрессында чыгыш ясаганда, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев «Татар музыкасының сәхнә

сәнгатен халыкка җиткерүче иҗат коллективлары элеккеге СССРның бик күп шәһәрләрендә бар. Аларның күбесе чын мәгънәсендә профессиональ биеклеккә күтәрелделәр. Самарадан «Ялкынлы яшьлек», Мәскәүдән «Хыял», Уфадан «Тальян», Оренбургтан «Чипмә»... — әнә шундыйлар» дип билгеләп узган иде. Уңыш «Ялкынлы яшьлек»кә, әлбәттә, җиңел генә бирелми. Моңа ансамбльнең җитәкчесе Илгиз абый Колючевның тынгысыз көннәре, йокысыз төннәре, агарган чәчләре салынган. Атнага өч тапкыр шәһәрнең бер башыннан икенчесенә, эштән соң, 40 чакрым юл узып, репетициягә йөри ул. Беркайчан да зарланмый, авырыксынмый. Югыйсә төп эше дә җаваплы, күп көч сорый торган. Ул СССР авиация сәнәгатенә караган конструкторлар үзәгендә эшли. Фәнни-практик эш белән шөгыльләнә. Техник фәннәр кандидаты була. Докторлык диссертациясен якларгамы яисә ансамбльдә калыргамы дигән сорау тугач, Илгиз абый, һич икеләнмичә, ансамбльне сайлый. Иҗатташ дусларыннан, милли сәнгатебездән аерыласы килми аның. Һәм ул ялгышмый. Аның иҗат гомере бушка узмый. Илдә милли күтәрелеш чоры башлангач, «Ялкынлы яшьлек» тирәсендә җыелган милләтпәрвәрләр Самарада «Туган тел» иҗтимагый-мәдәни үзәген оештыралар. «Бердәмлек» газетасы нәшер ителә башлый. Татар яшьләр берлеге төзелә. «Яктылык» татар мәктәбенә нигез салына.

Илгиз абый Колючев турында күптән ишетеп белсәм дә, аның үзе белән якыннан 1999 елда Ульяновскида «Чипмә» телевизион тапшыруының 5 еллык юбилеена баргач кына таныштым. Менә шул вакыттан бирле аралашып, хәбәрләшеп торабыз. Очрашкан саен, мин аның җитезлегенә, булдыклылыгына, милләт дип җан атып йөрүенә сокланып, күз тимәсен дип карыйм.

Булганнан бар да була, ди халык. Әлеге әйтем нәкъ менә Илгиз Колючев кебек шәхесләр турындадыр. Оренбург өлкәсенең Сорочинск төбәгендәге урман-кырларга бай җирдә, Бозаулык елгасы буенда урнашкан Белогорка дигән татар авылында Ис-

мәгыйль абый белән Тәтәюн апа гаиләсендә өченче бала булып дөньяга аваз сала ул. Илгиз кечкенәдән техника белән мавыга, җырга-шигърияткә һәвәс була. Нәни бармакларын гармун телләрендә биетеп, авыл халкын сөендерә. Малайның шундый талантын күргән күршесе Сәхипҗамал апа: «Тәтәюн, улың инженер йә артист булыр синең», — ди. «И Сәхипҗамал, дөнья читендәге татар авылында үскән малайга кая инде шундый зур кеше булу. Бәхете булсын да чын кеше булсын», — ди әнисе. Әлеге сөйләшү, мөгаен, Ходай Тәгаләнең амин дигән вакытына туры килгәндер.

Туган авылында ана телендә җиде сыйныф белем алган улының белемгә омтылуын күреп, Тәтәюн апа Илгизне укуын дәвам итәргә район үзәге Сорочинскига алып килә. Рус телендә язган беренче диктанты гел хаталардан гына тора. Илгиз, дәфтәрен кулына алгач, мин укып әллә ни булдыра алмам, колхозда атлар карармын дип, авылына кире кайтып китә. Улындагы сәләтне күргән ана икенче көнне аны кабат мәктәпкә илтә. Менә шуннан җиң сызганып укырга тотына Илгиз. Таланты булган кешегә мондый авырлык кына берни булмый. Үҗәтлеге, тырышлыгы да булган малай бер ел эчендә ике сыйныф программасын үзләштерә. Мәктәпне көмеш медальгә тәмамлый. Самарадагы политехник институтка укырга керә, аны кызыл дипломга бетерә һәм шушы шәһәрдә төпләнеп кала.

Авылда туган туфрак исен татып үскән егетнең милли хискә, татар моңына сусаган җанын шәһәрнең асфальт юллары, биек йортлары берничек тә баса алмый. Шуңадыр инде ул барлык каршылыкларны җиңеп алга атлый һәм үз дигәненә ирешә. Менә 35 ел инде «Ялкынлы яшьлек» ансамбленең сәнгать җитәкчесе Самарада яшәүче татарларга үз милли моңыбызны ишеттереп, күңелләренә шатлык бирен яши. Аларның репертуарында, халык җырлары белән бергә, шагыйрьләрдән М.Җәлил, Һ.Такташ, Ш.Галиев, Р.Харис, Р.Миңнуллин, Р.Фәйзуллин, композиторлардан С.Сәйдәшев, Р. Яхин, Ф.Әхмәтов, С.Садыйкова, Р.Еникеев әсәрләре дә урын ал-

ган. Вокал-хореографик жанрда да уңышлы эшлиләр. Шушы еллар дәверендә ансамбльнең меңнән артык һәвәскәр артисты өлкә күләмендә популярлык казанган. Биредә канат ныгыткан Рөстәм Вәлиев — бүген Татарстанның халык артисты, Наилә Баһаветдинова — профессиональ диктор.

Самараның Россияне иңләп-буйлап гизгән, татар җырын, шигъриятен, милли биюләрне халкыбызга җиткерүгә үз көчен керткән «Ялкынлы яшьлек» ансамбле үзенең 35 яшьлеге һәм Казаныбызның 1000 еллыгы уңаеннан башкалабызда Галиәсгар Камал театры бинасында 14 май көнне чыгыш ясарга җыена. Бу аларның бездә беренче тапкыр чыгыш ясаулары түгел. Мәркәзебездә яшәүчеләр һәм кунаклар ансамбльнең иҗат җимеше белән тагын бер кат таныша алачак.

Татарстаннан читтә 35 ел дәвамында татар ансамбле яши икән, монда гади татар авылында туып үскән егетнең — техник фәннәр кандидаты, Татарстан һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Самара өлкәсенең Мәшһүр татары исемен йөрткән Илгиз Исмәгыйль улы Колючевның тырышлыгы, булдыклылыгы, татарны яратуы салынган. Менә шундый милләттәшебез ул безнең.

*«Татарстан яшьләре» газетасы*
*2005 ел, май*

# «Халык «Зөләйха»ны көтә...»



*Татарстан Республикасы эчке эшләр министры Әсхәт Сәфәров Татарстанның халык артисты Рамил Төхфәтуллинга милиция тормышын чагылдырган фильм эшләргә тәкъдим итә. Ә Рамил — хыялый кеше. Ник алынмаска бу эшкә, дип уйлый ул. Хыялның — бик теләсәң — тормышка аша торган матур гадәте бар. Шулай итеп, эш башлана. Иң элек студия төзиләр. Әлеге студияне оештырырга матди яктан «Татгазинвест» хуҗалары Р.С.Ханбиков һәм К.Ф.Абдуллин ярдәм итә. Бу 2000 ел була. Студиягә исем сайлаганда, төрле тәкъдимнәр*

*була. Рамилнең якын дуслары аны, үз итеп, «Рамай» дип йөртәләр. Күбесенең киңәше белән ул шул исемгә тукталa. Яңгырашы да матур, фарсы теленнән* ***рамазан ае, урак өсте, кызу чак*** *дип тәрҗемә ителә.*

*2005 елның 26 апрелендә республикада шәхси капиталлардан торган кино сәнгатен үстерү фонды — «Татарстан cinema» оеша. Аның президенты итеп Татарстанның халык артисты Рамил Төхфәтуллин сайлана. «Рамай» студиясе хәзер шуның составында.*

*«Рамай» студиясенең беренче эше наркотикларга каршы төшерелгән «Упкын» фильмы була. Ул 2002 елда Эчке эшләр министрлыгының 200 еллыгына багышланган бәйгедә «Иң яхшы әдәби әсәр» номинациясендә беренче урынны яулый. Икенче фильм — Гаяз Исхакый әсәре буенча куелган «Зөләйха» трагедиясе.*

*«Зөләйха»ны Гаяз Исхакый 1911 елда яза. Бу әсәрнең нигезендә татарларны көчләп чукындыруга каршы ачы нәфрәт ята. Әсәр аша без тарихтагы реаль вакыйгаларны, ничә йөз еллар изелеп яшәп тә, телен, динен, гореф-гадәтләрен, милли йөзен саклап кала алган татар халкының аяныч хәлен һәм бер үк вакытта рухи батырлыгын бер җепкә тезеп күрә алабыз. Әсәрдә татар халкының аяныч, ачы язмышы Зөләйха образы аша сурәтләнә.*

*Рамил Төхфәтуллин нәкъ менә шул әсәр буенча фильм төшерү эшенә алына. Алар сценарийны язучы Юныс Сафиуллин белән бергә иҗат итәләр. Зөләйха образын Татарстанның атказанган артисты Илсөя Төхфәтуллина башкара. «Зөләйха — җаваплы, катлаулы роль. Материалны укып чыкканнан соң, хыялланып эшкә тотындым. Зөләйха образын тамашачыга җиткерә алдым дип уйлыйм. Ул — минем иң көчле рольләремнең берсе. Бу образны башкаруыма шатмын», — ди Илсөя ханым.*

*Татар халкының үткәнен тагын бер кат фильм аша күзалларга мөмкинлек тудырган Рамил Төхфәтуллинга мин берничә сорау белән мөрәҗәгать иттем.*



**— Рамил, «Зөләйха» әсәре буенча фильм төшерү сиңа нигә кирәк булды?**

— Әлеге сорауны мин үземә дә бик еш бирәм һәм җавап табарга тырышам. Мөгаен, ул миңа өстән иңдерелгәндер. Бу турыда студент елларыннан бирле хыялландым. «Зөләйха»ны экранлаштыру эчке дөньямның максаты булды. Әсәрдә безнең фаҗигале тарихыбыз сурәтләнә. Монда татарның гасырлар буе җыелып килгән, бүген дә чишелеш тапмаган проблемалары, дин, тел мәсьәләсе күтәрелә. Әйе, тел һәм дин. Татарлык шуннан гыйбарәт. Рус кешесе татар телен өйрәнергә мөмкин, ләкин ул телне өйрәнеп кенә татар була алмый. Ислам динен кабул итеп кенә дә татар булып булмый. Алар икесе бергә кушылганда гына, милләт саклана. Шушы фильм

аша татар тамашачысына әлеге фикерне җиткерәсем килде минем.

Гаяз Исхакый үзе дә бу әсәр буенча фильм төшерергә хыялланган. Узган гасырның егерменче еллары булган ул. Төркем дә туплаган. Фильм депортация аркасында гына эшләнми калган. Мин Г.Исхакыйның шул хыялын да тормышка ашырырга теләдем. Татарлыкны, телне, динне югалтмау бүген дә актуаль.

**— Артистларны нинди күзлектән чыгып тупладың?**

— Сценарийны язганда ук төп рольләрне башкаручы артистларны күзаллап яздым. Мәсәлән, хатыным булганга түгел, милли йөзле хатын-кыз һәм артист буларак, Илсөядән башка мин «Зөләйха»ны күз алдына да китермәдем. Фильмда катнашучылар — Г.Камал исемендәге театр сәхнәсендә кайчандыр «Зөләйха» спектаклендә уйнаган артистлар. Качалов театрыннан да чакырдык.

**— Рольләр тәкъдим ителгәч, баш тартучы булмадымы?**

— Юк. Барысы да минем бу эшкә җитди алынуымны күрделәр. Бернинди фальшька да урын калдырмадым. Барысы да дәртләнеп эшкә тотындылар. Кино сәнгате татар артисты өчен тансык бит ул.

**— Рамил, фильмга керәшен татарларының карашы ничек булды?**

— «Зөләйха» документаль әсәр түгел, сәнгать әсәре. Монда тарихыбызның бик кечкенә проценты гына чагылыш таба. Фильмда керәшеннәрне Камал театры артистлары Николай Дунаев һәм Вера Минкина уйнады. Әйтергә кирәк, керәшен татарлары проблемасына игътибар ителү ягыннан фильм аларга ошаган. Мин анда шундый сюжет керттем: беркем дә ислам диненә, гомумән, халык бер-берсенә каршы түгел. Монда сәясәтчеләр идарә итә. Башкалар кулларына җеп бәйләгән курчаклар — марионеткалар гына.

**— Фильм күпме вакыт эчендә төшерелде?**

— Тәмам әзер булганчы бер ел да өч ай вакыт кирәк булды.

**— Рамил, фильм режиссеры гына булып калмыйча, рольдә дә уйнадың. Сәхнә һәм экран. Аерма сизеләме?**

— Мин 19 ел сәхнәдә. Шактый тәҗрибә тупланды. Классикларны да иҗат итәргә туры килде. Инде үземне башка амплуада сынап карыйсым килде.

Режиссер — мөстәкыйль кәсеп. Кино белән театр режиссеры да аерыла. Кино үзенә сәнгать һәм техниканы туплаган. Мин — кино сәнгатендә режиссер. Монда үз фикеремне автор аша чагылдыра алам. Җиңел хезмәт түгел, әмма кызыклы эш.

**— Фильмны карагач, үз эшеңнән канәгать калдыңмы?**

— Тәнкыйть белән караган урыннар бар, әлбәттә. Гомумән алганда, канәгать, Аллага шөкер.

**— Рамил, фильм — күп финанс чыгымнары сорый торган сәнгать, сезгә кемнәр ярдәм итте?**

— Иң беренче мин Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевка рәхмәтле. «Зөләйха» аның фатихасын алып һәм матди ярдәме белән төшерелде. Равил Гайнетдин дә ярдәм кулын сузды. Теләче, Питрәч, Аксубай, Әлки районнары хакимиятләре дә безгә теләктәшлек күрсәтте.

**— Хәзер нинди уйлар, хыяллар белән яшисең?**

— Кино төшерү буенча эшемне дәвам итәм. Туфан абый Миңнуллин белән эссе жанрында милли идеяләр белән сугарылган яңа проект әзерлибез. Хәзергә исеме — «Җитлегү». Бу исем үзгәрергә дә мөмкин. Ул «Татарстан cinema»ның беренче эше булачак. Бүгенге шау-шулы, коточкыч ритмдагы тормышыбызны чагылдырган, матур буяулар белән бизәлгән сюжетка корылмаган поэтик формадагы эш.

**— «Зөләйха»ны дин әһелләре ничек кабул итте?**

— Гаҗәеп. Алар бик рәхмәтле. «Бу — синең өчен савап. Аның әҗере кайтачак», — диделәр. Фильмны дингә, татар халкына мәдхия итеп кабул иттеләр. Дин әһелләре, «Зөләйха»ны таратыр-

га теләп, кассеталарын сорыйлар. Кассеталарны яздырырга исә куркыныч, урлыйлар. Икенче көнне үк пиратлар чыгара башлый. Ә безнең теләк бу фильмны бөтен Татарстанда, гомумән, татарлар яши торган өлкәләрдәге кинотеатрларда күрсәтү. Татарстан буенча бу эш, Алла боерса, август аенда башланачак. Район үзәкләрендә яшәүчеләр ай дәвамында фильм белән танышачаклар. Халык «Зөләйха»-ны көтә.

*«Татарстан яшьләре» газетасы*
*2005 ел, июль*

# Тиң ярым, җаныма син кирәк



*Халык артист тормышы белән һәрвакыт кызыксына. Бүген Резидәнең иҗатында да, тормышында да яңалыклар шактый. Әйдәгез, аларны җырчының үз авызыннан ишетик.*

**— Резидә, тормышыңдагы яңалыкны газета укучыларга да җиткерсәк...**

— Дөрестән дә, минем тормыш соңгы вакытта гел үзгәрешләрдән генә тора. Ходай бер бирсә бирә икән ул. Мактанырга яратмыйм, шулай да синең соравыңа җавапны мактанмый биреп булмый кебек. Хезмәтемне бәяләп, Татарстанның атказанган артисты исемен бирделәр. Сөенеч өстенә сөенеч —«Казан» милли мәдәният үзәге миңа ике бүлмәле фатир алырга ярдәм итте. Моның өчен мин аның директоры Ринат Закировка рәхмәтле. Әлегә күчеп өлгер-

мәдем, ремонт эшләре бара. Менә шулай Аллага шөкер дип яшәп яткан көнем.

**— Иҗатыңда да яңалыклар бар бит.**

— Мин бер урында тик торырга яратмыйм. Һәрвакыт яңа җырлар, яңа авторлар эзлим. Соңгы вакытта Ринат Мөслимов, Гөлнара Сабирова, Галиәхмәт Шаһи шигырьләренә Фирзәр Мортазин, Зөфәр Хәйретдинов, Габдразак Миңгалиев, Гайфулла, Наил Шәймәрдәнов көй язган җырларны җырлыйм. Шуларны туплап, яңа гына «Син кирәк» дигән аудио-компакт диск чыгардым.

**— Әлеге җырлар тупланмасына «Син кирәк» дип исем кушу юкка түгелдер...**

— Ул җырның көен Наил Шәймәрдәнов язды. Анда мондый сүзләр бар:

Талгын җил иссә дә чайкалам, мин — тирәк,
Бөгелеп төшүдән сакларга син кирәк.
Тормышта гел балкып яшәргә син кирәк...

Бу җырны мин яраткан кешемә багышлап җырлыйм.

**— Узган елгы әңгәмәдә: «Мин әлегә иректә», — дигән идең.**

— Вакыт агышы һәрнәрсәне көйли икән. Мин дә насыйп ярымны очраттым. Бер-беребез белән көтмәгәндә очраштык. Күрештек, таныштык, гашыйк булыштык. Озакка сузмыйча, никах та укыттык. Бу җыр минем иремә багышлана.

**— Бу яңалык — синең өчен җан атып йөрүче ир-егетләр өчен көтелмәгән хәл. Кем соң ул сине үзенә гашыйк итеп, никах җепләре белән бәйләп куйган бәхетле кеше?**

— Мин шәхси тормышым турында сөйләргә яратмыйм. Кешедә бераз гына булса да сер булырга тиеш. Шуңа күрә никахны да шау-шуларсыз, тыныч кына уздырып җибәрдек. Тормышымдагы бу вакыйга үзем өчен, гаиләм өчен кадерле. Минем иҗатым, тормышым белән кызыксынган укучыларга шуны гына әйтә алам: ирем иҗат кешесе түгел, ләкин җыр сәнгате белән кызыксына. Үзе дә матур җырлый. Ул — эшкуар.

**— Җырчы Резидә Шәрәфиеваның фамилиясе үзгәрәчәкме соң?**

— Без шулай килештек: мин үз фамилиямдә калачакмын.

**— Резидә! Сине яратучы барлык газета укучылар исеменнән иҗатыңда да, гаилә тормышыңда да уңышлар телибез! Бәхетле бул, син аңа лаек.**

*«Татарстан яшьләре» газетасы*
*2005 ел, июль*

# «Татарның яшәү дәрте көчле...»



Урал тауны ера-ера,
Юлын салган елгалар.
Бу кодрәт, бу куәтне
Татарданмы алганнар!

*Риза Шәфи*

*Әңгәмәдәш — Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе, Татарстанның Дәүләт Советы депутаты Ринат Зиннур улы Закиров.*

**— 1000 ел җиһан өчен диңгездәге бер тамчы су кебек. Ә тарих өчен ул ничәмә-ничә буыннар-**

**ның яшәешен — уй-хыялларын, теләк-максатларын, өметләрен барлый, бер җепкә бәйли торган дәвер. Бөек Болгарның дәвамы булган башкалабызга да шушы көннәрдә 1000 ел тула. Ринат Зиннурович, дөнья күләмендә танылу алган шәһри Казаныбыз милләттәшләребез тормышында нинди урын алып тора? Әйдәгез, сөйләшүне шуннан башлыйк әле.**

— Татар кешесе, кая гына яшәсә дә, күңеле белән Казанга омтыла. Аның уңышларына сөенеп яши. Аларга Казан — рухи, мәдәни, тарихи мәркәз. Татарларны берләштерүче үзәк. Тамырлары белән Татарстан җиреннән булып та, язмыш җилләре ата-баба туфрагыннан бик еракка алып китеп, Казан каласын бер күрергә зар-интизар булып яшәүче милләттәшләребез бик күп. Гомерләре читтә узган татар өчен Казан — Мәккә. Алар туган туфракка тартылалар. Бирегә килеп, башкалабыз тормышын үз күзләре белән күрәселәре килә. Шул уңайдан Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты 2 ел дәвамында Чувашия, Башкортстан, Екатеринбург, Тубыл, Адыгей, Пермь өлкәсе, Санкт-Петербург, Төмән, Самара, Мәскәү, Литва, Латвия, Төркия, Чиләбе, Тольятти һәм башка җирләрдән килгән кунакларны Казаныбызның 1000 еллыгы уңаеннан экскурсияләргә йөртте: театрларга, музей, мәчетләргә, татар гимназияләренә алып барды. Конгресста кабул итте. Безнең чакыру буенча кунакка килүчеләр арасында мәктәп укучылары, яшьләр, урта буын вәкилләре, өлкәннәр дә бар. Иң мөһиме: олылар да, кечеләр дә милли мәркәзебез Казаннан онытылмас хатирәләр белән рухи яктан баеп, канатланып кайтып киттеләр. Бу турыда безгә килгән дистәләгән рәхмәт хатлары сөйли. Менә шуларның берсе.

*«Бу сәяхәт миңа татар телен, милли гореф-гадәтләрне, мәдәниятне тирәнтен белергә кирәклекне аңлатты. Аннан башка бер генә татар кешесе дә татар җәмгыятенең тулы хокуклы әгъзасы була алмый. Мин, Казанга килгәч, шуны күреп сөендем: милләт проблемаларын чишү турында кайгыртучылар бар һәм күп икән. Музейларда, мәчетләр-*

*дә булып, һәйкәлләрне күреп, мин тагын шуны аңладым: тарихны белергә һәм хәтерләргә кирәк — ансыз өметле киләчәкне төзеп булмый...»*

Ә бит бу хатның авторы — мәктәптә укучы бала. Менә нинди нәтиҗәләр, өлгергән фикерләр тудыра ул Казанга ясаган бер сәяхәт!

**— Язмыш татарны дөнья буйлап тараткан. Татарстанга, Казанга килгән татарлар конгрессның Башкарма комитетына керми китмиләр. Милләтне берләштерүдә конгрессның роле нидән гыйбарәт?**

— Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының төп максаты — милләтне берләштерү. Ә моның нигезендә милли идеология ята. Ул тел, мәгариф, мәдәният, дин һәм милли яшәешкә караган башка проблемалар җыелмасыннан тора. Конгресс алдында торган төп бурычлар: татар халкын, аның иҗтимагый берләшмәләрен туплау; Татарстан Республикасының социаль-икътисади, милли-мәдәни, сәяси һәм рухи үсешенә ярдәм итү. Менә без шуларны күз алдында тотып эшлибез дә.

**— Татарлыкны саклау, булганны барлап киләчәккә җиткерү өчен милли кадрлар кирәк. Безнең халыкта ышанычлы, булдыклы, милләтпәрвәр егет-кызлар җитәрлекме?**

— Җитәрлек дип әйтсәм, арттыру булыр, юк дисәм, дөреслеккә туры килмәс. Милли кадрларны сайлап алу һәм аларның башкарган эшләрен башкаларга да күрсәтү — безнең конгрессның төп бурычларыннан берсе.

Милли лидер белемле булырга, масштаблы фикер йөртә белергә, халкыбызны яратырга, аның тарихыннан, гореф-гадәтләреннән, йолаларыннан, мәдәниятеннән хәбәрдар һәм дипломат булырга тиеш. Бу бер-ике ай эчендә генә эшләнә торган эш түгел. Шуңа да бу мәсьәлә актуаль булып кала бирә.

Милли җитәкчеләр үсеп чыкмый торып, Россия регионнарында татар милләтенең эшләре алга китмәячәк. Милли лидерлар булмау аркасында эшләре «килде-китте» генә барган регионнар безнең күз алдыбызда.

Шулай да милли лидер дәрәҗәсенә күтәрелгән кайбер шәхесләребез турында әйтми мөмкин түгел. Бәрәкәтле эшләребез ныклап тамыр җәйгән урыннарда көчле шәхесләр үзеннән-үзе калкып чыга. Бүгенге көндә татар дөньясында милләт өчен игелекле эшләре белән дан казанган шәхесләрдән мин Кязим Дебердиев (Пенза), Фәнис Гатауллин (Ханти-Манси), Фәрит Ляпин (Иваново), Җәмил Вәлиуллин (Тольятти), Шамил Бикмаев (Саранск), Рамил Вафин (Йошкар-Ола), Фәрит Гыйбатдинов (Чувашия), Мөдәррис Әбакиров (Новосибирск), Ирек Шәрипов (Ижевск), Рәсим Акчурин (Мәскәү), Гөлсинә Үлмәскулова (Кыргызстан) исемнәрен атар идем.

**— Ринат Зиннурович, Россиядәге бүгенге милли вазгыятькә Сезнең караш ничек?**

— Россиядә милли сәясәт, халыклар тигезлеге игълан ителсә дә, гамәлдә ул юк дәрәҗәдә. Бар булганы имитациягә, күз буяуга кайтып кала. Ә игълан ителмәгән ассимиляция сәясәте чынбарлыкта милләт балаларын елан куяннарны йоткан кебек йотып бара. Россиянең күп төбәкләрендә халыкларның телләре, мәгарифе, мәдәнияте турындагы федераль кануннар үтәлми. Бу хакта Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты исеменә килгән күпсанлы хатлар сөйли. Моны без, татарлар укмашып яшәгән төбәкләргә барып, үз күзләребез белән дә күреп кайтабыз. Россия Балтыйк буе илләрендә яшәүче ватандашларыбызның телен, мәдәниятен саклап калырга, хәлен яхшыртырга тырыша. Ә үз өендә яшәүчеләргә милли сәясәттә игътибар җитми. Бу күпләрдә канәгатьсезлек хисе уятырга мөмкин бит. Хөкүмәт җитәкчеләре менә шул турыда да уйлансыннар иде.

**— Татарстан белән чиктәш элеккеге автономияле республикаларда татарлар күпләп яши. Шуларның кайсысында милләттәшләребез үзара татурак, хакимият белән дусрак яши?**

— Милли республикалар арасында башкаларга үрнәк итеп мин Удмуртия республикасын атар идем. Андагы татарлар турында рәхәтләнеп авыз тутырып сөйләргә була. Милләттәшләребез бу республика-

да халык саны буенча өченче урында тора. Алар хакимият тарафыннан җылы караш тоеп яшиләр. Биредә дистә елга якын инде татар классик гимназиясе эшли. Балалар бакчаларындагы татар төркемнәрендә нәниләр тәрбия ала. Югары уку йортында татар теле бүлеге бар. Дүрт дистәгә якын иҗади коллективлар, ансамбльләр халыкка хезмәт итә. Татар телендә радио, телевизион тапшырулар эфирга чыга. 15 ел инде «Яңарыш» газетасы нәшер ителә. Язучыларга да бай Удмуртия җире. Араларында Татарстан Язучылары берлегенә кергәннәре дә бар. Киләчәктә үзләрендә Татарстан Язучылар берлегенең филиалын булдырырга телиләр. Соңгы елларда гына да татар шагыйрьләренең 26 китабы дөнья күргән. Татар милли-мәдәни автономиясе эшли. Әле яңа гына Удмуртия Республикасы Президенты Александр Волков белән бергәләп татар эшкуарлары һәм эре предприятие җитәкчеләре, Дәүләт Советы депутатлары, министр урынбасарлары белән дә очрашып кайттым. Әлеге очрашуның максаты Удмуртия татарлары милли-мәдәни автономиясе каршында Попечительләр советын оештыру булды. «Татарлар бар эштә дә үрнәк булырлык. Без үзебез дә Татарстан Республикасыннан үрнәк алып яшибез. Минтимер Шәрипович — минем остазым», — ди Александр Александрович. Әлбәттә, милли хәрәкәтнең югары үсешкә ирешүе, инде әйткәнемчә, лидерлардан тора. Бу очракта мин Удмуртиядәге татарлар хәрәкәтен кузгатып җибәргән, милли хәрәкәткә күп өлеш керткән, лаеклы ялда булса да, бүген дә сафтагы Мәсхүт Гаратуевның, аннан эстафета алып, татарларны берләштерүче Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты әгъзасы Ирек Шәриповның исемен атар идем. Анда яшәгән милләттәшләребезнең рухи кыйбласы киң, барыр юллары озын булсын. Аларга тагын да уңышлар гына телисе килә.

Калган милли республикаларда мондый ук дәрәҗәдә оешканлык, күтәрелеш әлегә юк. Башкортстанда милләттәшләребез кызганыч хәлдә. Урындагы хакимият тарафыннан аларның мәнфәгатьләре бөтенләй игътибарга алынмый. Күрше Чувашия, Ма-

ри Эл, Мордовиядә беркадәр алга китеш бар. Яңа күтәрелеш чорында алар бераз ныгыдылар. Әмма аларда әле эшлисе эшләр эшләгәннәреннән күбрәк.

**— Чит илләрдәге татарлар белән аралашу нинди рухта бара?**

— Соңгы елларда ерак һәм якын чит илләр белән эшләү юнәлеше тамырдан үзгәрә башлады. Халыкара эшләребездә Татарстан Президенты каршындагы Тышкы элемтәләр департаменты һәм республикабызның вәкиллекләре актив ярдәм итеп киләләр. Бер генә мисал: узган ел татар яшьләре форумын уздырганда, департамент тырышлыгы белән без делегатларның юл һәм виза чыгымнарын Россия Тышкы эшләр министрлыгы исәбеннән каплый алдык. Конгрессның Башкарма комитеты Россия ватандашларының Халыкара берлеге белән дә эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырды. Бу безгә федераль структуралар белән аралашуны җиңеләйтергә, диаспора белән бәйләнешләрне киңәйтергә, кайбер программаларга акчалата ярдәм алырга мөмкинлек бирә.

Соңгы ике ел эчендә чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең оешмалары белән элемтәләребез көннән-көн ныгый һәм киңәя бара. 2002 елда Башкарма комитет утызлап татар оешмасы белән элемтәдә торган булса, бүген аларның саны йөз дә бишкә җитте. Электрон хатлар аша аралашу зур күләмдә һәм актив бара. Америка, Канада, Германия илләре белән көн саен диярлек аралашып торабыз. Берлинда яшәүче ватандашыбыз, Татар-башкорт мәдәни үзәгенең рәис урынбасары Венера Вагыйзова-Герасимованы мин күпләргә үрнәк итеп куяр идем. Ул тарихи Ватанына даими мәгълүмат җибәреп кенә калмый, үзе дә күп чаралар оештыра, татар тарихына кагылышлы китапларны алман теленнән русчага тәрҗемә итә. Шундый ук тынгысыз җаннардан Гөлсара ханым Исмаиловаңы (Канада), Җүнәйт әфәнде Чапан оглыны, Рокыя ханым Сафаны (АКШ) һ.б. атап булыр иде.

БДБ илләрендәге вазгыять катлаулырак. Анда яшәгән миллионга якын милләттәшебез еш кына та-

тар сүзен, җырын, моңын ишетергә тилмереп гомер итә. Татарстанның матбугаты, телевидениесе, радиосы кайбер илләргә барып ирешми. Аларның хәлен ничек булса да җиңеләйтү турында Башкарма комитет кына түгел, республикабыз җитәкчеләре дә һәрдаим кайгыртып килә. Казанның 1000 еллыгы уңаеннан конгресс чакыруы буенча соңгы вакытта гына Латвия, Литва, Төркиядән бер төркем татарларыбыз килеп, республикабыз, халкыбыз тормышы белән якыннанрак танышып киттеләр. Менә тиздән Кытайда туып үскән утызлап милләттәшебезне — яшь егет-кызларны каршы алырга әзерләнәбез. Алар, мәркәзебезгә килеп, ана телен өйрәнәчәкләр, югары белем алачаклар. Бөек Җиңүнең 60 еллыгын каршылаган көннәрдә Балтыйк буе илләреннән, Казакъстан, Үзбәкстан кебек Бәйсез дәүләтләр берлегеннән бер төркем сугыш ветераннарын — аксакалларыбызны кабул иттек. Ерак һәм якын чит илләр белән элемтәләребез ныгый бара.

**— Ринат Зиннурович, өч елга якын Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе булып эшләгән чорыгызда милли мәгариф өлкәсендә алга китеш сизеләме?**

— Мәгърифәтне, мәдәният, туган тел, гореф-гадәтләребезне саклау — болар БТК Башкарма комитетында һәрдаим игътибар үзәгендә тора торган мәсьәләләр. Башкарган гамәлләрне күздән кичерсәк, моның чынлап та шулай икәнлегенә инанасың. Россия төбәкләрендә яшәгән татарлар өчен милли мәктәпләр, сыйныфлар, тел курслары, якшәмбе мәктәпләре ачу, милли тәрбия бирү — безнең төп бурычыбыз, олы юлыбыз. Нәкъ менә шушы мөһим гамәлләргә карап, милли оешмаларның, шул исәптән конгрессның да эшчәнлегенә бәя бирергә мөмкин. Әмма мәктәпләр ачу эше бүген энә белән кое казуга тиң. Ике ел буе көрәшә-көрәшә, Ульяновск өлкәсенең Димитровград шәһәрендә бер мәктәп ачуга ирештек. Чиләбе, Екатеринбург шәһәрләрендә дә боз кузгалды кебек. Чиләбе хакимияте татар мәктәбе ачарга ризалыгын бирде. Мәктәп ачу һичшиксез кирәк һәм мөһим эш. Ансыз милләтнең үзаңын да,

телен дә саклап булмый. Әмма милләтне саклап калу мәсьәләсен мәктәпкә генә кайтарып калдырырга ярамас. Монда ата-аналар фикерен үзгәртү дә бик мөһим, һәр ата-ана, ничек кенә милләт җанлы булмасын, баласының киләчәге турында уйлана, кайгырта. Татар мәктәбен тәмамлаган бала, русча укыган яшьтәшләре белән чагыштырганда, әле хәзергә оттыра, чөнки татар мәгариф системасының бер буыны — югары мәктәбе юк. Моңа хәтле без ата-аналарны, мәгариф җитәкчеләрен үгетләп килдек. Татар телендә югары белем алу мөмкинлеге һавадагы торна рәвешендә булганда, һәркем кулында песнәк булуын, ягъни баласының рус университетларында укуын кулайрак күрә. Киләчәккә минем өметем зур, Татарстан Фән һәм мәгариф министрлыгы белән берлектә Россиядә халык саны буенча икенче урынны биләгән татарларның Татарстан югары уку йортларында ана телендә укыту мөмкинлеген арттырырбыз дип уйлыйм. Бу эштә, әлбәттә, быел Казанда ачылачак татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты да мөһим роль уйнар дип ышанам.

**— Инде килеп, ислам диненең халкыбыз тарихында тоткан урынына күз салсак...**

— Татар милләтенең язмышы ислам дине белән турыдан-туры бәйле. Дин безнең күп гасырлар дәвамында дәүләтле халык булып яшәвебездә зур роль уйнады, җәмгыятьтә әхлакый нормалар тәрбияләде, гомумән, татарны татар итеп саклап калуда үзенең зур өлешен кертте. Татарлар үзләренең дәүләтчелекләрен югалту фаҗигасен кичергәндә дә, ислам дине милләт сагында торучы бердәнбер фактор булган. Халкыбыз дәүләтчелеген югалтып юкка чыгу куркынычы алдында калгач та, ата-бабаларыбызның дине бу фаҗигане булдырмау юлында иң нык терәк булган. Гасырлар буе үз дәүләте белән яшәгән халык, язмышының иң авыр чорында ислам диненә сыенган, аннан яклау тапкан. XVI—XVIII гасырларда ислам татар халкы өчен иң зур, дөресрәге, бердәнбер таянычка әверелгән. Аллаһы Тәгаләгә инану, халыкка көч биреп, аны берләштергән һәм христианлашып юкка чыгудан саклап калган.

Бераз тернәкләнеп аякка баскач та, татар халкы ислам дине традицияләреннән читкә тайпылмаган. Һәр адымын бисмилла әйтеп атлап, башкарган эшләрендә дингә хилафлык китермәгән. Христиан дәүләте уртасында яшәп, үзен юкка чыгудан саклаган татар милләте ислам диненең интеллектуаль һәм потенциаль мөмкинлекләреннән файдаланып кына калмыйча, бөтен мөселман дөньясына үрнәк була алырлык яшәү рәвешен формалаштырган. Ата-бабаларыбыз зирәк, тормышка аек акыл белән караучы мөселман булып кала алганнар. Тормыш нинди генә авыр шартларга куйса да, аннан чыгу юлларын диннән йөз чөереп түгел, аңа таянып эзләгәннәр.

Совет хакимияте елларында милләтне, социалистик идеология кысаларына кертеп, диннән аерырга тырышсалар да, ислам безнең тормышыбыздан бөтенләй юкка чыкмады. Гореф-гадәт, йола рәвешендә генә булса да сакланып калды. Ләкин ислам яшәеш рәвешенең нигезе булудан туктады. Татарларга хас булмаган катнаш никахлар, эчкечелек, әхлаксызлык кебек күренешләр гадәткә керде. Татарлар интернациональ совет халкы «гаиләсенең» тулы хокуклы әгъзасына әйләнделәр.

Үзгәртеп кору еллары тормышыбызга күп яңалыклар алып килде. Динебез дә әкренләп җәмгыятькә әйләнеп кайта бара. Бүгенге көндә Татарстанда бер меңнән артык, ә Россиянең татарлар яшәгән төбәкләрендә ике меңгә якын мәчет ачылу, Россиядә утызлап Диния нәзарәте оештырылу, утыздан артык мәдрәсә эшләү, әлбәттә, моның ачык мисалы. Ләкин бүген җәмгыятькә әйләнеп кайткан ислам дине милләт язмышы өчен кайгырта, аның проблемаларын хәл итүдә актив катнаша, гасырлар буе яшәп килгән йолаларыбызны торгыза дип әйтә алабызмы? Кызганычка каршы, юк. Әлбәттә, аның объектив сәбәпләре дә бар. Әмма бүген эшләнмәгән эшләрне, үзебезнең өстә торган бурычларны объектив сәбәпләргә сылтау гадәткә керде. Россиядә җил тегермәне кебек төрле якка боргаланып торган сәясәт тә бүген милләт язмышы өчен дини факторның мөһимлеген тагын бер кат раслый. Милләтнең киләчәге —

аның бердәмлегендә. БТК эшчәнлегенең төп юнәлеше — нәкъ менә шул бердәмлекне ныгыту, бу өлкәдә мөмкин булган барлык ресурслардан файдалану. Моның өчен Россиянең төрле төбәкләрендәге, якын һәм ерак чит илләрдәге оешмалар, җәмгыятьләр белән эшне дөрес оештыру бик мөһим. Без, әлбәттә, төрле төбәкләрдә дини оешмалар белән дә эш алып барабыз. Ләкин бүген безне иң борчыганы — Россиядәге дини оешмалар арасында бердәмлек булмау. Бу бик күп проблемалар тудыра: шәхси амбицияләр өстенлек иткән җирдә милләт язмышы беренче планда була алмый. Дини оешмаларга берләшү өчен нәрсә комачаулый? Мин моның объектив сәбәпләрен күрмим. Берләшүне кемнеңдер кемгәдер буйсынуы дип кенә карарга ярамый. Аның бит төрле формалары булырга мөмкин. Ләкин, ни кызганыч, бу хакта татар дин әһелләре тарафыннан конструктив адымнарны ясарга җыенган кеше әлегә күренми.

**— Соңгы елларда Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиевның хәер-фатихасы, Татарстан хөкүмәте ярдәме белән Сабантуй Россия төбәкләрендә генә түгел, дөнья илләре буйлап колач җәя. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты бу бәйрәмнәрдә координацияләүче ролен үти. Үзегезгә дә күп җирләрдә милли бәйрәмебездә катнашырга туры килә. Бу бәйрәмнәрдә халкыбызның йолалары, Сабантуйның барлык атрибутлары да саклanaмы?**

— Июнь-июль айлары — Сабантуйлар гөрләп бара торган матур чор. Милли бәйрәмебез дөньякүләм киңлекләргә чыкты. Быел алар Россиянең 59 төбәгендә һәм 11 чит илнең 30 шәһәрендә күтәренке рухта узды. Шулай итеп, татарның милли бәйрәме Америка, Австралия, Азия, Аурупа кыйтгалары буйлап атлый.

Әлбәттә, аларның сыйфатлары да елдан-ел үзгәрә, яхшыра бара. Әнә Тольятти шәһәрендәге Сабантуйны гына алыйк — быел анда 45 мең кеше катнашты. Ә бит биредә яшәгән татар халкының саны 40 мең тирәсе. Димәк, яше-карты, дус-ишләре —

барысы да милли мәйданга килгән дип була. Бирегәге бәйрәм Сабантуйның барлык йолаларына туры китерелеп, аракысыз, аек акыл белән узды. Әлбәттә, Сабантуйларны уздыру зур оештыру осталыгы таләп итә. Хәзер милли бәйгеләребезне оештыру һәм уздыру Президент Аппараты, хөкүмәтебез тарафыннан БТКның Башкарма комитеты белән берлектә алып барыла. Төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез Сабантуйларны иген кырлары язгы яңгырларны көтеп алган кебек каршылыйлар. Шуннан соң аларның рухлары күтәрелеп киткәндәй була.

Төрле төбәкләрдә Сабантуйлар уздыру күтәрелеп китсен өчен, халкыбызның милләтпәрвәр ул-кызларына үткән гасырның туксанынчы елларында армый-талмый эшләргә туры килде. Алар милләтебезне саклау, татарның рухын берләштерү өчен тырыштылар. Бу шулай ук Татарстан Президентының татар халкын саклар өчен алып барган сәясәт җимеше дә. Татарстанның үз йөзен булдыру, татарны бар җиһанга таныту өчен эшләнгән эшләренең нәтиҗәсе дә. Сабантуй ул халыкның рухи дөньясын чагылдыра, үткәнен бүгенгесе белән бәйли. Ул — татар кешесенең яшәеш, берләшү, киләчәккә омтылу символы.

Без әлеге бәйрәмдә атрибутлар саклансын дип тырышабыз. Әмма күп җирләрдә, мәсәлән, ат чабышын үткәрә алмыйлар. Моның өчен атлары юк. Татар көрәшеннән башка Сабантуй уза алмый. Көрәш мәйданы — бәйрәмнең күрке. Көрәшне җиренә җиткереп оештыру өчен осталар, көрәшчеләр булырга тиеш. Сөлге тота белмәгән, йолалардан мәхрүм булган, бары тик авырлык җыйган, буй үстергән кешедән генә әллә ни өмет итеп булмый. Көрәшнең үз остасы булырга тиеш. Татар көрәшчеләрен тәрбияләү, үстерү максатыннан Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты быел Казанда Сабантуй оештыручылар семинарында төрле регионнардан килгән вәкилләр белән берлектә Россия татар көрәше Федерациясен төзү турында конференция уздырды. Хәзер шуны теркәү эшләре бара. Бу Федерациянең максаты — төбәкләрдә милли көрәш-

челәр тәрбияләү. Менә шул эшебезнең беренче карлыгачы буларак, эшкуар милләттәшебез Хәмзә Газизовның тырышлыгы белән Оренбург өлкәсенең Богырыслан шәһәрендә татар көрәшчеләрен әзерли торган «Батыр» спорт клубы ачылды. Мондый гамәлләр эшмәкәрләрне бизәп кенә калмый, татар милләтен үстерүгә керткән өлеше булып та тора.

**— Ринат Зиннурович, татар милләте нинди ул дип, аны тасвирлап бирүегезне сорасам...**

— Татар нинди ул дигәндә, шуны әйтәсем килә: татарның яшәү дәрте көчле. Без — тапкыр, укымышлы, җор күңелле, җор телле, гаилә яратучан, туганлык хисе көчле булган халык. Татар кешесе эшчән, юмарт, кунакчыл, сәнгатькә гашыйк. Шуларның барысын җыеп әйткәндә, милләтебезнең иммунитеты көчле. Безнең җитешмәгән якларыбыз да бар. Горурлык, бердәмлек сыйфатлары, гомумән, масштаблылык җитешми. Ләкин бу җитешсезлегебез халкыбызның кодрәтен дә киметми, рухын да төшерми.

**— Казанның 1000 еллык бәйрәме якынлаша. Конгресс тарафыннан күпме милләттәшебез кунакка чакырылачак?**

— Казан каласы — татар дөньясының мәркәзе. Бу олуг бәйрәмгә — 1000 еллыкка — конгресс тарафыннан 1000 кунак чакырылды. Милләтебезнең иң кадерле, абруйлы, эшлекле кешеләре бу олы мәҗлестән читтә калмаслар дип уйлыйм. Кемнәрдер безгә рәсми делегацияләр әгъзасы булып килер. Шул ук вакытта халык дипломатиясе мөмкинлекләрен дә онытмыйк, кардәшләр. Казанлылар — кунакчыл халык. Милләттәшләребезнең бер өлешен танышлары, дуслары, туганнары кабул итәр дип ышанам.

Төрле кыйтгаларда сибелеп яшәүче халкыбызны, милли мохитне саклауда, аңа яшәү көче, рухи этәреш бирүдә Татарстанның роле бәяләп бетергесез. Республикабызның Президенты Минтимер Шәймиевны барлык татарның җитәкчесе дип саныйлар. Президентыбызны татар халкының яклаучысы, лидеры итеп тану, шәхес буларак олылау безне бермәбер көчлерәк итә.

1000 елдан артык тарихы булган милләтебез бу тарихи бәйрәмне бердәмлектә каршы алыр, киләчәктә дә өмет белән яшәр дип ышанам. Татар халкының гомере озын булачагына минем шигем юк.

— **Амин, шулай булсын.**

*«Татарские новости» газетасы. 2005 ел, август*
*«Яңарыш» газетасы (Удмуртия). 2005 ел, август*

# Сәхнәдә — «Казан» ансамбле



Сәхнәдә — яшьлек дәрте. Төсләр балкышы. Чибәр, сылу егетләр-кызлар, бию ритмнарын алмаштырып, тамашага җыелган халыкның игътибарын сәгатьләр буена биләп тора. Хәер, үз-үзләрен тотышларының табигыйлеге һәм гадилеге, хәрәкәт белән белдерелгән хисләр байлыгы, концерт номерларының динамикага корылышы — болар һәммәсе сәхнә белән залны мизгел эчендә бер дулкынга көйләп куя. Ул дулкын өйләргә

кайткач та тынмый әле. Күңелдә кабат-кабат күтәрелеп-уяныш, яңадан тамаша халәтенә кайтара. «Казан» милли-мәдәни үзәгендә эшләүче шәһәр филармониясенә караган «Казан» бию ансамбленең һәр концерты әнә шулай дәвамлы бәйрәмгә әверелә.

Ансамбль яшь әле. Ә профессиональ бию төркеме туплау җиңел эш түгел. Бу хакта «Казан» милли-мәдәни үзәге директоры Ринат Закиров озак еллар хыялланса да, әлеге теләк бары 1997 елда гына республика Президенты Минтимер Шәймиев фатихасы белән тормышка аша, төгәлрәк әйткәндә, шул елны Казан шәһәре башлыгы Камил Исхаков муниципаль профессиональ бию ансамбле оештыру турындагы фәрманга кул куя. Менә шуннан башлана инде бию коллективын туплау. Үзебезнең Казан, Чаллы белән генә канәгатьләнеп калмыйча, сәләтле-белемле егет-кызларны Уфа, Ижевск, Йошкар-Ола, Чабаксар шәһәрләрендәге хореография училищеларына да барып сайлап алалар. Шул рәвешле әкренләп коллектив туплана, репетицияләр башлана, репертуар булдырыла. «Казан»ның нигез ташларын салуда аның сәнгать җитәкчесе Чулпан Закирова башлап йөри. Чулпан ундүрт яшеннән профессиональ сәхнәдә. Кечкенәдән сәнгатькә тартылган кыз Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамласа да, яраткан шөгыленнән аерылмый. Шушы шөгыль башкала дәрәҗәсендә эшләүче коллектив белән җитәкчелек эшенә алып чыга аны, ГИТИСның хореография режиссерлары бүлегендә белем ныгытырга «мәҗбүр итә».

Утыз биш кешедән торган «Казан» бию ансамбле үзенең беренче концертын 2001 елның март аенда тәкъдим итә. Беренче биюләрне балетмейстерлар Илдар Хәмидуллин, Фәнис Исмәгыйлев куя. Халык көнкүрешеннән алынган, күңел җылысы белән сугарылган, еш кына кызыклы вакыйгаларга корылган, юморга бай биюләр тирән хислелеге, самимилеге белән Казан тамашачысын беренче очрашуда ук үзенә җәлеп итә. Кызлар биегәндә, сәхнәдән нә-

фислек һәм затлылык, сафлык һәм тыйнаклык, наз бөркелеп тора. Ир-егетләр чыкса, ут чәчеп торган дәрт, ярсу җитезлек, эчке энергия ыргыла. «Болгар яугирләре», «Чирмешән кичләре», «Зәңгәр томан» кебек биюләрдә халкыбыз рухы чагыла. Зур уңыш белән узган беренче сынау концертыннан бирле яшь ансамбль гел гастрольдә, гел хәрәкәттә. Кыска гына дәвер эчендә иҗат юллары бию коллективын кайларга гына алып бармады! Алар Татарстан, Россия шәһәрләре белән генә чикләнмичә, Кытай, Франция, Тайван, Мальта, Испания, Австралия шәһәрләре сәхнәләрендә дә Татарстан Республикасы исеменнән чыгыш ясадылар. «Чит илләрдә татар фольклоры белән кызыксыналар, биюләребезне, милли костюмнарыбызны яратып кабул итәләр. Без дә, үзебез йөргән илләрдә яшәүче халыкларның бию үрнәкләрен үзләштереп, тәҗрибә туплап кайтабыз. Бию аша да дөньяны танырга, илләр белән танышырга була», — ди Чулпан Закирова.

Бүгенге көндә «Казан» бию ансамбле — аягында нык басып торучы, бай иҗат репертуары, танылган биючеләре, кием тегү цехлары, үз тамашачысы булган коллектив. Биюченең сәхнә гомере — егерме ел. Шуңа күрә яшим дип яшәгән профессиональ коллектив үз мәктәбен булдырырга, алмаш әзерләргә тиеш. «Казан» бию ансамбле каршында менә өч ел инде балалар хореография мәктәп-студиясе эшли. Биредә җиде яшьтән унике яшькәчә булган йөз укучы бию серләренә төшенә. Мәктәп-студиядә белем алучылар шулай ук рәсем, музыка сәнгатен, сынлы сәнгатьне, балет тарихын өйрәнәләр. Дүрт ел укыганнан соң, аларга махсус таныклык тапшырыла. Бу мәктәптә укучы нәниләр, быел Г.Камал театры сәхнәсендә беренче иҗат җимешләрен тамашачыга тәкъдим итеп, алкышларга коендылар инде.

Ә «Казан» бию ансамбле бер урында гына таптанмый, гел яңалык эзли. Казан шәһәренең меңьеллык бәйрәменә махсус әзерләнделәр: дөньяның төрле почмакларыннан мәркәзебезгә җыелган кунакларга «Казан сөлгесе» дигән хореографик та-

маша күпне сөйләр, күпне аңлатыр. Әйе, сөйләр. Бию теле уртак тел бит. Халкыбызның үткәнен, бүгенгесен, киләчәген чагылдырып иҗат итүче, башкалабыз исемен йөртүче бу ансамбль «Казан» сүзен дөнья илләренең бик күп сәхнәләрендә яңгыратыр әле.

*«Сөембикә» журналы*
*2005 ел, август*

# «Maison grise» — якты йорт



*Әлфия Әтәч елында туган.*

*Йолдызлыгы — Кучкар.*

*Тормыш өлгесе — әтисе.*

*Аның өчен үрнәк хатын-кыз — Валентина Матвиенко.*

*Яраткан ризыгы — әнисе тутырган тавык, әбисе пешергән бәлеш.*

*Яраткан хушбуе — «Шанель».*

*Дөньяда иң кадерле җире — әти-әнисе йорты.*

Кеше хыял белән яши. Кемнеңдер хыялы тормышка аша, ә кемгәдер ул буй җитмәс биеклек булып кала бирә. Әлфия бәләкәйдән кече якта бөтерелергә ярата. Алты яшендә беренче тапкыр коймак пешереп әти-әнисен, сеңелләрен сыйлаганын әллә үзе хәтерли, әллә өйдәгеләрнең шаккатып сөйләгәннәреннән күңелендә калдырган, ә менә өлкәннәрнең «Үскәч кем буласың килә?» дигән соравына «Ресторан хуҗасы булам» дип җавап бирүе хак. Әлеге сүзләр, мөгаен, Ходайның «амин» дигән сәгатенә туры килгәндер. Бүген Әлфия Шәйхетдинова — Казан шәһәренең үзәгендә урнашкан затлы «Maison grise» ресторанының хуҗабикәсе. Аның кебек ханым-туташларны бизнеследи диләр.

Хыяллану бер нәрсә, ә бит ул хыялны чынга ашыру өчен шактый тир түгәргә кирәк. Киләчәккә карап фикер йөрткән әти-әнисе 14 яшьлек Әлфияне, инглиз телен камил өйрәнсен дип, Англиягә укырга җибәрәләр. Кызын туган йорттан еракка озатканда, әтисе, киңәшләрен аерым кәгазьгә язып, Әлфиянең кулына тоттыра. «Чит ил бит, бик авыр вакытларым булды, туганнарымны сагындым, шундый чакларда мин әтиемнең киңәшләрен укый идем»,— ди ул. Киңәшләр инде күңелгә бикләнгән һәм алар бүген дә ышанычлы юлдаш.

Район үзәгендә туып үскән, милли тәрбия алган, гореф-гадәтләрне яхшы белгән татар кызы Европада! Бергә укыган сабакташлары арасында Испаниядән, Италия, Әфганстан, Франциядән килгән яшьләр дә була. Татарстан турында ишетеп тә белмәгәннәргә Татарстан дигән ил, татар дигән горур милләт, аның батыр, кыю уллары-кызлары барлыгын, үзенең шул халыкның бер баласы икәнлеген аңлату өчен хәйран тырышырга туры килә Әлфиягә.

Европада башка тормыш, башкача яшәеш. «Бу илгә килгәч, безне гаиләләргә урнаштырдылар. Минем хуҗаларның кызлары, иреннән аерылып кайтып, бер ай әти-әниләре йортында яшәде. Иренә кире киткәндә, әнисе аның кулына бер ай эчендә кызына то-

тылган чыгымнар теркәлгән исәп-хисап кәгазен тоттырды. Анда утка, суга, урын-җиргә, кер юганга киткән чыгымнарның барысы да күрсәтелгән иде. Менә шунда мин беренче тапкыр инглиз гаиләсендәге тәрбияне, тәртипне күрдем. Бу әйберләр безгә ят иде». Менә шулай алты ел Европада яшәп, кыз дөньяны башка яктан ача. «Әле бу юлы Англиядән кайтканда, аэропортта пассажирларны карап утырдым да, күзәтүләрем киләчәккә сабак булсын дип, күргәннәремне күңелемә салып куйдым. Көтү залы тулы бала, сабыйлар рәхәтләнеп йөгерәләр, идәнгә ятып та ауныйлар, үзләрен кызыксындырган һәрнәрсәне тотып карыйлар, ясалма шугалактан шуалар. Әти-әни баласына игътибар да итми шикелле — егылып имгәнмәсеннәр генә. Россиядән килгәннәр дә шунда ук бит инде. Дүрт-биш яшьләрдәге ике малайлы гаилә. Безнең мескеннәргә (дим инде) сорамыйча адым да атларга ярамый. Алар да бала югыйсә. Шугалакка менеп кенә басканнар иде, әти кеше малаен сөйрәп төшерде дә янына китереп бастырды. Әле суккалап та алды. Чагыштырып карасаң, Европада балага кечкенәдән барлык мөмкинлекләр тудырылган. Дөрес, алар тәрбиясендә дә кимчелекләр җитәрлек. Әмма инглизләрдән барыбер күп нәрсәгә өйрәнергә, күп әйбердән гыйбрәт алырга була. Англиядә укып кире Казанга кайтканда, мин бөтенләй башка кеше идем инде. Бу илдә яшәп алу мине ныгытты, тормышта үземне табарга ярдәм итте», — ди Әлфия.

Туган җиргә кайткач, аның өчен яңа тормыш башлана. Ул Казан дәүләт технология университетында укуын дәвам итә һәм Мәскәүдә халыкара профессиональ топ-менеджерлар әзерләү программасы буенча белемен күтәрә. Шуннан яңадан чит илгә китеп укырга җыена. Нәкъ менә шул чакны үз эшен оештыру, ресторан ачу мөмкинлеге туа. Халык теленә «соры йорт» дип кереп калган бинаны (Павлюхин урамында) беренче күрүендә үк, биредә француз ризыклары белән сыйлый торган ресторан булырга тиеш дип уйлый Әлфия, һәм исемен дә нәкъ менә «Maison grise», французчадан татар-

чага тәрҗемә иткәндә «соры йорт» дип куша. Кыз, элеккеге ниятләрен онытып, җиң сызганып эшкә керешә. Бер тотынган икән, Әлфия туташ инде кире чигенә торганнардан түгел. Һәр эшне уйлап, җиренә җиткереп башкарырга ярата ул. Зәвыкны, зыялылыкны акчага сатып алып булмый. Алган гыйлем дә булганны гына баета. Укымышлы, затлы нәсел баласы булуы өстенә фантазия, уйлап табу, булганлык, осталык сыйфатлары да, эшкә җигелеп, Әлфия хыялындагы әкият дөньясына ике ел буе бара, «соры йорт»та ике ел буе эш кайный. Бу вакытта кызның ныклы таянычы — әтисе, төп киңәшчесе әнисе була. Аларның булышлыклары, үзенең тырышлыгы белән 2005 елның мартында Казан шәһәрендә затлы француз ресторанына ишекләрен ача. Монда ул — хуҗабикә. Әлеге йортны үзгәртеп кору да — аның идеясе. Бинаның бизәлеше, француз шәрабы кебек куе кызыл диварлар, җиһазлар, «йолдызлы күк», яшькелт-алтынсу төстәге тәрәзә пәрдәләре, баскычтан менүче кунакларны каршы алып торучы «тере» манекеннар — барысы да ул күзаллаганча. Официант киемнәренең модельеры да ул үзе.

Революциягә кадәр Россиядә беренче класслы француз рестораннары булган. Аларда диңгез аръягыннан килгән пешекчеләр эшләгән. Бу йортларга безнең морза-дворяннарыбыз, сәүдәгәрләребез, зыялы язучылар, рәссамнар, музыкантларыбыз йөргән. Әлфиянең Казанда беренчеләрдән булып француз ресторанына ачуы да үткәннәрне яңарту максатыннан эшләнә.

Әлеге ресторанга аяк атлау белән, үзеңне Франциягә эләккән кебек хис итәсең. Биредә һәр почмак әлеге ил хакында сөйли. Җиңелчә генә музыка сине әллә кайларга алып китә. Ә менюга күз салсаң... Монда устрицадан да, бака итеннән, әкәм-төкәмнән, диңгез моллюскларыннан да авыз итәргә мөмкин. Барлык ашамлыклар да сыйфатлы. «Француз тәгамнәрен атнага ике тапкыр самолет белән алып кайтабыз», — ди хуҗабикә. Пешекчесе — Франция Президенты Жак Ширакка ризык әзерләгән егет.

Ресторанның икенче катында эчемлекнең түмен татып карау, сыйфатын билгеләү залы. Биредә Эйфель башнясын хәтерләткән бар янында җаен, рәтен, тәмен белгәннәр озаклап рәхәт чигеп утыра ала. Шулай ук «Maison grise»да дөньяның төрле почмакларында җитештерелгән егерме мең шешә эксклюзив шәраб тупланган винотека һәм Россиядәге иң зур шәраб базы да бар.

Әлфия — менә шундый ресторанның җитәкчесе! Эштә ул таләпчән дә, кырыс та, җитез дә. Бу заманда бизнес дөньясында кайнау, ир-егетләр белән беррәттән бару, планнар уртаклашу, үз эшеңне ачу хатын-кызга җиңел түгелдер. «Монда хәйләкәр дә, акыллы да, мөлаем да булырга кирәк», — ди ул. Казанда ресторатор хатын-кызлар бармак белән генә санарлык. Әлфия — шуларның берсе.

Ул — замана кызы. Аның эш сәгате иртән башланып, төнге уникеләрдә генә тәмамлана. Яшь кешенең, хатын-кызның шәхси тормышы да бар бит әле. Ял да итәсе, өйдә дә үзеңчә генә яшәп карыйсы, яратасы, яраттырасы килә. «Башым бертуктаусыз эш турында уйлый, һәммәсе өчен борчылам, ә йөрәгемдәге урын мәхәббәткә», — ди ул.

Пөхтәлек, чисталык яраткан кызның өендә дә тәртип. Дуслары өчен ул тапкыр, киң күңелле, шаян, эчкерсез. Ул — кешелекле хатын-кыз. Эштән бушаган арада, Әлфия җыр тыңларга, кухняда пешеренергә ярата. Аның пешергән ризыкларын ашасаң, телеңне йотасың. «Аш-су әзерләү серләренә мине дәү әнием өйрәтте», — ди Әлфия.

«Кешене акча боза. Баеган саен саранлана баралар» диючеләрне еш ишетергә мөмкин. Ләкин бу сүзләр безнең героебызга кагылмый. Дусларына, туганнарына ул беренчеләрдән булып ярдәм кулы сузучы да, киңәшләрен бирүче дә. Аның өчен иң зур бәхет — туганнарының, якыннарының янәшәдә булуы.

Тормыш дәвам итә. Әлфиянең әле барысы да ал-

да. «Мин үз алдыма куйган максатыма дөрес һәм гадел юл белән ирешергә телим. Миңа гына түгел, башкаларга да әйбәт булсын», — ди ул. Мондый татар кызлары булганда, халкыбызның затлы, зыялы киләчәгенә өмет зур.

*«Сөембикә» журналы*
*2006 ел, гыйнвар*

# «Җыр — минем язмышым...»



Химиклар мәдәният сараенда зур концерт. Сәхнәдә Фердинанд Сәләхов. Җитез адымнар, ыспай хәрәкәтләр, төз гәүдә, затлы кием. Әйтерсең ул — серле әкият дөньясыннан сәхнә түренә күтәрелгән падишаһ. Халкыбызның «Сандугач», «Аһ, Ырынбур кала», «Безнең урам», «Аһ, җаным Бибисара» кебек җырларын бер-бер артлы башкарып, Фердинанд тамашачыны үзе белән бергә моңландыра, сыкрандыра, елата, биетә, сөендерә. Рәхмәтле тамашачы аны алкышларга, чәчәк бәйләмнәренә күмә. Җырчының иҗат дәверендә мондый концертлар меңәрләгән булгандыр. Әмма монысы җырчының иҗатын-

да хикмәтле концерт булды дисәм, һич кенә дә арттыру булмас. Халкыбызның мәшһүр җырчысы Илһам ага Шакиров, үзе сәхнәгә күтәрелеп, шәкертеннән имтихан алды ул чакны. «Башкорт халык җыры «Таштугай»ны беләсеңме?» — дип сорады да, фортепиано янына утырып уйнап та җибәрде. Фердинанд Сәләхов та сынатмады. Тамашачысы, остазы каршында талантын тагын бер кат исбатлады. Кайсы башкаручыга легендар җырчының уйнаганы бар?! Бу — җырчы өчен зур бәя иде.

Ходай Тәгалә Фердинандтан буй-сынны да, төс-кыяфәтне дә, моңны да жәлләмәгән. Җырчы белән аралашкан кешеләр аның гади, ачык йөзле, ярдәмчел булуы өстенә менә дигән әңгәмәдәш икәнлеген дә яхшы беләләр. Сүз капчыгы юморга бай, теле йөгерек, фикере эзлекле. Сөйли башласа, әллә нинди фәлсәфи, көтелмәгән нәтиҗәләр ясап куя. Үтә зур сабырлык, аек акыл белән яшәргә омтылучы кеше ул. Үҗәтлеге дә юк түгел. Менә шул сыйфаты аңа тормышында очраган авырлыкларны, югалту-кайгыларны җиңәргә, җыр дөньясында үз кыйбласын табарга, төрле кыйтгаларда яшәүче татарның яраткан җырчысына әверелергә ярдәм иткәндер, мөгаен.

Фердинанд Сәләхов табигатьнең гүзәл почмагында — Акбикә күле, Үләмә елгасы буенда урнашкан Апас районы Чүри-Бураш авылында дөньяга килә. Тууы гел бишле саннары һәм урталык белән бәйле. Ул гасыр уртасында — 1955 елда, көн уртасында — 15 сәгатьтә, ай уртасында — 15 сентябрьдә туа. Улының җырчы булыш китүенә әнисе Зәйнәп апа әллә ни гаҗәпләнми. Нәселдә бар эш. Әти-әнисе икесе дә матур итеп җырлыйлар. Әнкәсе әле бүген дә озын көйләрне рәхәтләнеп башкара. Алай гына да түгел, Зәйнәп апаның бертуган абыйсы Раһип Җиһаншин да заманында җырчы була. Аны Мәскәү консерваториясендә укыганда хәрби хезмәткә алалар, аннан Бөек Ватан сугышы башлана, үлем хәбәре килә... Ләкин бу нәселдә татар җырына оеткы бетмәгән, моңга дәрт сүнмәгән икән әле. Дәвамчысы Фердинанд була. Ул олы сәх-

нәгә зур юллар урап, соңарып килә. «Минем табигатем шундый. Һәрнәрсәгә соңга калып өлгерәм. Кичәге эшне бүген эшлим мин. Кайбер җиргә ашыгам, кайбер җиргә соңга калам. Мин мәктәпкә дә соңга калып кердем, армиягә дә соңарып киттем, сәхнәгә дә соңлабрак чыктым. Ярый әле тышкы кыяфәтем белән яшь күренәм», — ди Фердинанд Сәләхов.

Җырларга бик яратса да, кая инде ул авыл малаена җырлап йөрү! Ундүрт яшендә әтисез кала ул. Дүрт бала белән тол калган, ирен югалту кайгысыннан түшәккә егылган Зәйнәп апа үзенә таяныч итеп улы Фердинандны күрә. Тормышның беренче авырлыгын менә шул чакта татый яшүсмер. Каралты-кураны чистарту, төзекләндерү, гектардан артык бүлеп бирелгән чөгендер җирен эшкәртү һәм башка авыр эшләр төшә аның җилкәсенә. Төшкә кадәр энекәшләренең ата-аналар җыелышына барса, төшке аштан соң икенче сменага Апас урта мәктәбенә ашыга. Менә шулай итеп дөньяны танырга өйрәнә ул. Гаилә учагын да саклап кала, хезмәт мәктәбен дә үтә.

Мәктәп, авыл, район сәхнәләрендә җырлап-биеп үскән егетне дуслары да, яшьтәшләре дә киләчәктә артист итеп күрергә телиләр. Ләкин ул үзе башкача уйлый: табиб булырга тели. Әмма күңел җырларга ашкына. Казан медицина институтында укыган чорда анатомичкада шөгыльләнү Фердинанд өчен һәрчак күңелсез тәмамлана. Моң белән сугарылган күңел адәм баласының дөнья куйган мәле белән килешергә теләми, бу халәтне кабул итә алмый. Ул төзелешкә китә.

Дөньяда кеше үз күңеленә якын теләктәшләр эзли. Тормыш юлы Фердинанд Сәләховны да җырчы Миңгол Галиев белән очраштыра. Ул вакытта Миңгол ага «Татарстанның 10 еллыгы» исемендәге мәдәният сараенда хор җитәкли, ә Фердинанд шул хорга йөри. Аның моңына, затлы тавышына соклангaн мөгаллим егеткә консерваториягә керергә тәкъдим итә. 1977 ел Ф.Сәләхов өчен истәлекле ел була. Армиядән кайткач, ул Казан дәүләт консерва-

ториясе студенты булу бәхетенә ирешә. Остазы профессор Зөләйха Хисмәтуллина булачак җырчыны җыр сәнгатенең нечкәлекләренә өйрәтә, тавыш мөмкинлекләрен киңәйтә. Канатланып, иҗат дәрте белән яныш йөргәндә, язмыш аны тагын бер кат сынау алдына куя. Ул кинәт авырый башлый. Табиблар тамагында яман шеш табып, операция ясауның мәгънәсе юк дип тетрәндерәләр аны. Яшь-яшь, яшим дип ашкынган кешегә моны ишетү коточкыч авыр хәл була. Менә шул вакыт остазы Зөләйха Хисмәтуллина аңа кабат фәрештә кулын суза. Өметсез дип, егеткә Казанда операция ясаудан баш тарталар. Зөләйха ханым аны шул вакытта ук инде яхшы белгеч буларак танылган табибә Флора Таһирова янына алып бара. «Җырчы буларак та, кеше буларак та коткарып калучым ул минем Зөләйха Хисмәтуллина. Исән булса, кулларымда күтәреп йөртер идем. Үзем дә аны ярдәменнән ташламадым. Хәзер балалары белән тыгыз элемтәдәмен», — ди Фердинанд. «Бирешмә, барысы да яхшы булачак», — дип, фидакарь табибә гади бер студентны Мәскәүгә, яман шеш авыруларына операция ясый торган артистлар шифаханәсенә алып китә. «Ышанам, операция уңышлы чыгачак»,— дип, Мәскәү табибларына икеләнергә урын калдырмый. Флора Таһир кызы дәрәҗәле, тәҗрибәле белгеч булганга, аның фикерен-гозерен читкә какмыйлар. Операция ясыйлар һәм ул уңышлы уза. Зөләйха Хисмәтуллина һәм Флора Таһирова ярдәмендә көн саен күнегүләр ясый-ясый, Фердинанд әкренләп сөйләшергә, кабат җырларга өйрәнә. Укуын дәвам иттереп, диплом алу бәхетенә ирешә.

Менә шул вакыттан бирле ул сәхнәдән аерылгысыз. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшли. Аннары аны Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенә эшкә чакыралар. Биредә инде җырчыга мөмкинлекләр арта, офыклар киңәя. Филармониядә эшләү дәверендә кайларда гына булмый, нинди сәхнәләрдә генә чыгыш ясамый ул! Бер елны гастрольдә 119 концерт бирә. Аны һәр җирдә көтеп, сагы-

ныш каршы алалар. Концерттан соң «Рәхмәт яусын сиңа, балакаем!» дигән сүзләр белән өлкән яшьтәге апа-абыйлар, күз яшьләрен сөртә-сөртә, аркасыннан сөяләр. Ерак гастрольләрдә башка милләт вәкилләренең дә янына килеп, кулын кысып, рәхмәтләр яусын дип киткән чаклары күп була. Яхшы, профессиональ дәрәҗәдә башкарылган халык җырына кем генә сокланмас шул?! Берчакны Казакъстанның Алма-Ата шәһәрендә танылган татар рәссамнары Камил Мулдашев һәм Бәхтияр Табиевның эшләреннән күргәзмә оештыралар. Бу затлы кичәгә зыялы, күренекле шәхесләр чакырыла. Алар арасында Татарстанның халык артисты Фердинанд Сәләхов та була. Анда халкыбызның «Җанкай-җанаш», «Эскадрон», «Сандугач» җырларын башкаргач, Казакъстан Президенты Нурсолтан Назарбаев аннан «Галиябану»ны җырлавын сорый. Бу җирлектә үзен ихтирам иткән һәр казакъ белә икән әлеге җырны. Халкыбызның гасырлар аша сакланып килгән җырын рәхәтләнеп башкара Фердинанд. Президент аңа кушылып җырлый. Мондый кызыклы мизгелләр күп була җырчының иҗат дәверендә.

Фердинанд Сәләхов — чын мәгънәсендә югары лирик тенорга ия халык җырчысы. Татар композиторларының эстрада җырларын да, җыр-сөйләм жанрына караган бәет, мөнәҗәтләрне дә оста башкара ул. Бик сирәк җырчылар гына башкара алган «Эскадрон», «Кара юрга», «Ялгыз каен», «Ай, җаный-җанашым» һәм башка бик күп моңлы, тирән мәгънәле җырларны башкара ул. Халык исә йотлыгып, онытылып тыңлый. Фердинанд — җыр остасы, әлеге сәнгатьнең югары баскычында кыю басып торучы талант иясе. «Тормышны яңадан башларга туры килсә, син кабат узган юлыңны сайлар идеңме?» дигән соравыма ул болай дип җавап бирде: «Җыр — минем язмышым да, тормышым, куанычым да. Җырчы — халыкның сафлыгын, милләтен саклап калу өчен көрәшүче кеше ул. Мин үземне шулай хис итәм. Минем тыңлаучым, мине күтәрүче, мине зурлаучы, моң чишмәсе итеп кабул итүче халкым бар. Җырларым тутыга барган күңелләрне айкый, тынгысыз җан-

нарга тынычлык өсти. Менә шул бәхет түгелме җырчы өчен?!»

Киләчәктә дә бүгенгедәй олы йөрәкле, мәрхәмәтле дус, иптәш, халкыңның яраткан җырчысы булып яшәргә язсын сиңа, Фердинанд!

*«Татарстан» журналы*
*2006 ел, гыйнвар*

# *«Зө-ләй-лә»нең хыяллары*



*Ләйсән Мәхмүтова, Зөлфия Вәлиева, Ләйсән Закироваларны берләштергән «Зө-ләй-лә» кызлар ансамбле менә җиде ел инде татар эстрада сәхнәсендә. Әлеге кызлар, җыр сәнгатенә яшьлек, матурлык, яңалык алып килеп, тиз арада тамашачы күңелендә үз урыннарын алдылар. Яңа гына Г.Камал театры сәхнәсендә узган «Хыялый Зө-ләй-лә» дигән концерт программасында кызлар тагын бер кат үзләренең осталыкларын бәян иттеләр. Әлеге әңгәмә Ләйсән Мәхмүтова һәм Зөлфия Вәлиева белән шул концерттан соң алып барылды.*

**— Кызлар, әйтегез әле, сезне бу ансамбльдә бер-берегез белән нинди җепләр бәйли? Сезне нәрсә берләштерә?**

— **Л.** Татар җырына мәхәббәт һәм характерларыбызның туры килүедер, мөгаен.

— **З.** Өчебез дә кешенең күңелен күрергә ратабыз. Җырларыбыз, тамашачы күңеленә үтеп кереп, аны сөендерергә дә, уйландырырга да, елмаерга да мәҗбүр итә, концерттан кайтып киткәндә, йөзлә-

рендә елмаю күрәбез икән, безгә шул рәхәтлек бирә. Бәлки, шул сыйфатлар да безгә бергә иҗат итәргә мөмкинлек бирәдер.

**— Минемчә, сезне берләштергән тагын бер сыйфат театр артистлары булуыгыздадыр. Зөлфия — бүген дә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты. Ләйсән, син театр сәхнәсеннән киттең. Үкенмисеңме?**

— **Л.** Үкенәм дип әйтә алмыйм, эстрада сәхнәсендә дә иҗат өчен урын җитәрлек. Мин артистлык һөнәрен бүтән стильдә булсам да дәвам итәм бит.

— **З.** Ләйсән бөтенесен дә әйтеп бетерми шикелле. Минемчә, ул театр сәхнәсен сагына. Театрда Ләйсәннең үз урыны, үз амплуасындагы рольләре бар иде. Мин Ләйсән кайчан булса да театрга кире кайтыр дигән өметемне өзмим.

**— «Зө-ләй-лә» озын гомерле булыр дип уйлыйсызмы?**

— **З.** Озын гомерле бит инде безнең ансамбль. Өч кыз җиде ел бергә эшлибез, иҗат итәбез. «Зө-ләй-лә»нең таралуын күз алдына да китереп булмый. Рәхәтләнеп җырлыйсы килә әле. Киләчәккә планнарыбыз да бар, максатларыбыз да җитәрлек.

— **Л.** Бер чыгыш ясау өчен генә җыелган кызлар идек бит без. Өч ел җырладык, биш ел җырладык, җиде ел җырлыйбыз. Без һаман сәхнәдә, Аллага шөкер. Элек «Татар җыры»нда һәрберебез катнашып, берәр «Алтын барс» ала алсак, таралсак та ярый дип шаярта идек. Әлегә безнең кулда ике генә «барс». Шуңа күрә эшлисе дә эшлисе әле. Өченче «барс»ны кулга алмыйча, башка эш турында уйларга вакытыбыз да, теләгебез дә юк.

**— «Зө-ләй-лә»гә исемне кем кушты?**

— **З.** Без исемне озак уйладык. «Өчпочмак», «чәкчәк» исемнәрен тәкъдим итүчеләр дә булды. Шулай бервакыт исемнәребезнең беренче иҗекләрен кушып укып караган идек, Зөләйлә исеме килеп чыкты, һәм ансамбльгә шул исемне бирдек.

**— Җиде ел дәвамында шактый бай репертуар тупладыгыз. Репертуарны сез ничек сайлыйсыз?**

— **Л.** Һәрберебез үзебезгә ошаган җырны тәкъдим итәбез. Уртага салып сөйләшәбез. Беребезгә ошаган җыр икенчебезгә, өченчебезгә дә ошаган булып чыга. Шулай итеп, яңа җыр туа, репертуар байый.

— **З.** Безнең барыбызның да әти-әниләре җырмоңга гашыйк кешеләр. Бәләкәй вакытта, әле дә хәтеремдә, безнең өйдә Әлфия Афзалова, Илһам Шакиров һәм башка җырчыларыбыз башкаруындагы җырлар һәрвакыт яңгырый иде. Күңелләребездә сакланган менә шул җырларны яңартып, тамашачыга җиткерәсебез килә безнең. Репертуарыбызда андый җырлар шактый. Ретро җырларны тамашачы да бик җылы кабул итә.

**— Ләйсән, син үзең дә җырлар яза идең. Соңгы вакытта җырларың ишетелми шикелле.**

— **З.** Ничек ишетелмәсен?! Быел гына, Ләйсәннең «Җан ярам» дигән җырын башкарып, «Алтын барс» алдык. Беренче «Алтын барс» алган «Томаннар» җыры да Ләйсәннеке иде. Бик яратып җырлыйбыз без аның җырларын.

— **Л.** Минем җырларымны башка артистлар да җырлый. Авторлары әйтелмәгәнгә генә белмибез.

**— Артист халкы һәрвакыт юлда. Сезнең чит илләрдә яшәүче татарлар каршында чыгыш ясаганыгыз бармы?**

— **Л.** Әйе. Хөкүмәт делегациясе составында Франциядә булдык. Узган ел Төркиядә Сабантуйда милләттәшләребез каршында чыгыш ясадык.

— **З.** Ә Россия регионнарында без аяк басмаган җир калмагандыр, мөгаен. Архангельск, Түбән Новгород, Санкт-Петербург һәм башка шәһәрләрдә булган концертлар хәтердә матур хатирә булып калган.

— **Л.** Мактанып әйтү булмасын, кая гына барсак та, тамашачылар бик матур каршы алалар, алкышларын, чәчәк бәйләмнәрен жәлләмиләр. Яратып, тагын килегез дип озатып калалар. Бик еш йөрергә әлегә мөмкинлек кенә юк. Балаларыбыз кечкенәрәк.

**— Хыялый «Зө-ләй-лә» кызларының хыяллары нидән гыйбарәт?**

— **З.** Минем иң зур хыялым — улым Кәримне сау-сәламәт, акыллы, бәхетле бала итеп үстерү. «Зө-ләй-лә»нең иҗатта иң югары ноктага күтәрелүен телим. Без әле эшли генә башладык.

— **Л.** Иҗатыбыз елдан-ел үссен, баесын. Халкыбыз, гаиләләребез, илебез имин булсын. Бергәләшеп, кулга-кул тотынып яшәргә, иҗат итәргә язсын.

**— Амин.**

*«Татарстан яшьләре» газетасы*
*2006 ел, март*

# ЭЧТӘЛЕК

**Әңгәмәләшү — кешелекнең зур байлыгы**
*Нәзифә Кәримова* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
«Серләремне каеннарга сөйли идем...» . . . . . . . . 5
«Мин һаман авыл кызы...» . . . . . . . . . . . . . . . 9
«Үземне әтнәле дип саныйм...» . . . . . . . . . . . . 12
Әтнә патриоты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
«Бер-беребезнең кадерен белеп яшәргә язсын...» . 21
«Тавышым — үзе байлык...» . . . . . . . . . . . . . . 26
Мәхәббәтнең сере нәрсәдә? . . . . . . . . . . . . . . 30
«Фамилиям — Шәмиева...» . . . . . . . . . . . . . . . 38
«Җырларга дип кайттым...» . . . . . . . . . . . . . . 44
Ни өчендер безнең язмыш шундый... . . . . . . . . . . 48
«Җырчы шәхес булырга тиеш...» . . . . . . . . . . . 56
«Аның таланты чиксез океан кебек иде...» . . . . . . 66
«Мин — реалист кеше…» . . . . . . . . . . . . . . . 74
«Җыр белән вәгазьне бутамыйк...» . . . . . . . . . . 78
Бәла аяк астында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Бәхетнең чиге юк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
«Казанда мин үземне таптым...» . . . . . . . . . . . . 92
«Һәр тыңлаучының сулышын тоям...» . . . . . . . . . 95
«Парлы ялгыз булдым...» . . . . . . . . . . . . . . . 102
«Бәхеткә түзеп кара...» . . . . . . . . . . . . . . . . 106
«Мин әлегә ирекле...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
«Исәп озак җырларга...» . . . . . . . . . . . . . . . . 117
«Биюче булырга насыйп итмәгән...» . . . . . . . . . . 121
Һаман да яшь күңел . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
«Халык «Зөләйха»ны көтә...» . . . . . . . . . . . . . 132
Тиң ярым, җаныма син кирәк . . . . . . . . . . . . . 138
«Татарның яшәү дәрте көчле...» . . . . . . . . . . . . 141
Сәхнәдә — «Казан» ансамбле . . . . . . . . . . . . . 154
«Maison grise» — якты йорт . . . . . . . . . . . . . . 158
«Җыр — минем язмышым...» . . . . . . . . . . . . . . 164
«Зө-ләй-лә»нең хыяллары . . . . . . . . . . . . . . . 170

Литературно-художественное издание

**Шайхиева** Гульназ Фирдинатовна

**ОКЕАН ДУШИ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

*На татарском языке*

Әдәби-нәфис басма

**Шәйхиева** Гөлназ Фирдинатовна

**КҮҢЕЛ — ДӘРЬЯ**

Мөхәррире *Т.Р.Шакирова*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Т.В.Гредюшко*
Корректоры *Р.Н.Шакирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 10.06.2006.
Форматы 84×90 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Times» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 7,7.
Шартлы буяу-оттиск 8,05. Нәшер-хисап табагы 6,86.
Тиражы 3000 д. Заказ З-426.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru.**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.